Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 13 (1378) 8 апрель 2022 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

6

Чаллыда И.Юзеев исемендәге әдәби премия тапшыру тантанасы Башкортстандагы татарлар турында уйлануларга этәрде...

8

Сталин репрессияләре тәгәрмәче астына эләгеп, төрмә хастаханәсендә вафат булган Галимҗан Ибраһимовның кабере билгелеме?



12

Рәссам-педагог Мәхмүт Ваһапов Казанда төрле сәнгатькярләрне берләштергән кумәк күргәзмәләр залы булмауга борчыла.

Ил-җирләргә имин хәят теләп, Дога кылыйк әле бер булып!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россиядә үзләренең беренче фильмын төшерә торган югары белемле режиссерлар тулысынча дәүләт финанславына өмет итә ала, бу хакта законны РФ Президенты Владимир Путин имзалады.

- Шагыйрь һәм балалар язучысы Ленар Шәехнең «Галинең песие» китабы Балалар китабы буенча халыкара советның шәрәфле исемлегенә (элек Ганс Христиан Андерсен исемен йөртә иде) кертелде.

- Татнетны үстерү фондының башкарма директоры Раил Гатауллин татарча социаль челтәр барлыкка киләчәген хәбәр итте.

- Уфаның М. Кәрим исемендәге Милли яшьләр театры Советлар Союзы Герое Муса Гәрәевнең 100 еллыгына багышланган спектакль куярга җыена.

- Россиякүләм Культурадляшкольников.рф интернет-порталы балалар һәм яшьләр өчен мәдәният турындагы барлык бушлай цифрлы ресурсларны берләштерде.

- Казан дәүләт мәдәният институтында Н.Юлтыева исемендәге халыкара хореография фестиваль-конкурсы узды.

- Мәскәүнең «Дар» мәдәни үзәгендә татар халкының мәдәниятенә багышланган китап һәм фотосурәтләр күргәзмәсе ачылды.

- Татарстанда «Бердәм Россия» партиясенең «Кече Ватан мәдәнияте» проектында катнаша торган театрлар Донецк һәм Луганск республикаларына ярдәм итү өчен хәйрия спектакльләре күрсәтә башлады.

- Коми Республикасының Усинск шәһәре «Болгар» татар милли-мәдәни автономиясе зур концерт-тамаша белән үзенең 30 еллыгын үткәрә.

- Казандагы "Кырлай" паркы урынында Җәмигъ мәчетен төзү идеясен яклап, change.org сайтында имза җыю өчен петиция ачылган.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Фән ВӘЛИӘХМӘТОВ, җырчы, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты:

«Тальянны популярлаштырыр өчен, башта камил рәвештә саф татар телендә сөйләргә өйрәнергә кирәк. Моңлы җырлар җырлый беләсе. Шунда гына, гармунда уйнап, үзебезнең халык моңнарын күңелеңдәгесе белән бергә баетып, сәхнәгә, халыкка чыгарга кирәк. Андыйлар әле офыкта, минем карамакта, ни кызганыч, күренми. Бар алар, үтеп китүчеләр генә…»

СЫНАМЫШЛАР

8 апрельдә нинди көн булса, 8 октябрьдә дә шундый һава көтелә ● Искечә 1 апрельдә (хәзер 14 апрельдә) боз катса, унбиш көнлек юлга чана белән чыгарга ярый ● 14 апрельдә язгы ташу башланса, печән яхшы була ● Язын эретмичә озак тундырып торса, җәен корылык көтелә ● Каен суы күп акса, җәй яңгырлы була ● Сыерчыклар килгәч, чын яз башлана ● Елгаларда боз тиз эреп бетсә, ел уңышка бай була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 56 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 35 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **13 сәгать 39 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **15 апрельдә 14 сәгать 10 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

9 апрель – Татарстанның атказанган артисты Айрат Рифкать улы Арсланова 55 яшь (1967).

10 апрель – график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Б.Урманче ис. премиясе лауреаты Риат Заһретдин улы Мөхәметдиновка 70 яшь (1952);

– шагыйрә, журналист Йолдыз Әдип кызы Шәрәпова-Җамалетдиновага 60 яшь (1962).

12 апрель – җырчы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган артисты Наилә Әсгать кызы Фатехова 60 яшь (1962).

14 апрель – язучы Фәрит Гыйльметдин улы Гыйльминең (Гыйльметдинов) тууына 75 ел (1947–1993);

– шагыйрә Лилия Яссир кызы Садриевага 60 яшь (1962).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Апрельнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(9-16 апрель)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 февральдән 29 апрельгә кадәр** бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт арасында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген рамазан аеның 7 нче көне

ЖАН АВАЗЫ

Айдар ГАРИПОВ

Без дә студент идек...

Безнең студентлык чоры узган гасырның 70-80нче елларына туры килде. Хәзер ул чорны каралтып күрсәтәләр; икътисади торгынлык, азык-төлек кытлыгы, тормыш дәрәҗәсенең түбән булуы белән бәйлиләр. Әйе, муллыкта яшәмәдек, ләкин салкыннан туңмадык, ачлыктан интекмәдек. Авыл бәрәңгесеннән өзмәдек. Ул чорның маргарины да бүгенге ак майдан тәмлерәк иде кебек. Без Пионерлар урамындагы дүртенче тулай торакта яшәдек. Аена 40 сум стипендия түләделәр. Бүлмә өчен күпме алганнарын да хәтерләмим. Телевизор, суыткыч ише уңайлыклар бар иде барын, әмма асылда суыткыч ролен форточканың тышкы ягына эленгән азык-төлек сеткасы үтәде.

Ә менә китаплар күп иде. Уку барышында, йөзләрчә рус һәм чит ил классикларының, татар әдипләренең әсәрләре белән танышырга туры килде. Аларның барысында да диярлек беренче урынга әхлак-тәрбия мәсьәләләре күтәрелә иде. Укытучыларыбыз да, белем бирү белән бергә, шушы юнәлештә эшләде. Шуңа күрә ул елларның рухи халәте күпкә баерак, мәгънәлерәк, кешеләре дә шәфкатьле һәм ярдәмчел булгандыр.

Ул чорда татар теленә, әдәбиятына караш йөзләрчә игътибарлырак булган икән. Нәкъ шул елларда Казан педагогика институтының тарих-филология факультетында рус-татар бүлеге ачыла. Ул мәктәпләр өчен татар һәм рус теле укытучылары әзерли. Ел саен бүлеккә 75-90 студент кабул ителә. 1977 елда оешкан 107, 108, 109 нчы уку төркемнәрендә дә 75 студент белем алды. Безнең Казан педагогика институты татар теле укытучылары әзерләү буенча бөтен Идел буе өчен иң мөһим һәм хәлиткеч уку йорты булды. Безнең белән бергә Пензадан, Нижгар, Төмән, Чуашстан, Самара өлкәсе, Башкортстаннан газиз Ана телебезгә гашыйк укучылар җыелган иде. Бу еллар Казан дәүләт педагогика институты тарихына да алтын хәрефләр белән язылган. Тарихи уку йорты, эшчәнлек нәтиҗәләре буенча беренче урынга чыгып, 1976 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. 1977-1978 уку елларында ул СССРдагы 250 пединститут арасында иң яхшысы дип табыла һәм хөкүмәтнең күчмә Кызыл Байрагына лаек була.

Институтның I-II курс студентлары тулысынча тору урыны белән тәэмин ителде. III-IV курсларда инде укуда тырышлыгыңнан тыш, җәмгыятьтәге файдалы хезмәткә катнашуга, ДНД рейдларына йөрүгә дә игътибар бирелде. Аннары шәһәркүләм өмәләрдә катнашу да исәпкә алынды. Әйтик, группабыз белән Г.Камал исемендәге яңа театр бинасы төзелешендә катнашырга туры килде безгә...

Иң мөһиме, әлбәттә, белем алу. Бүген дә милләтебез горурлыгы булган фән докторлары – Мирфатыйх Зәкиев, Фоат Галимуллин, Фәрит Хатыйпов, Әнвәр Шәрипов, Рүзәл Юсупов, Рифат Сверигин... кебек мөгаллимнәр укытты бит безне. Кафедра җитәкчелеге күренекле язучылар, артистлар, шагыйрьләр белән күптөрле очрашулар үткәрде. Гомәр Бәширов, Илдар Юзеев, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Нәби Дәүлиләрнең студентлар белән очрашуга теләп йөрде. Түгәрәк өстәл артында "Казан утлары" журналында басылып чыккан яңа әсәрләр, әле кибетләрдә күренә генә башлаган китаплар буенча фикер алышулар үтә иде. Күп очракта мондый кичәләр артистлар, җырчылар катнашында узды.

Институтның актлар залында Сара Садыйкова белән очрашу әле дә күз алдында. Татар халкының бөек шәхесе яшел калфак һәм апак күлмәктән, елмаеп, сәхнәгә чыгып баскач, зал көчле кул чабуларга күмелде. Татар һәм рус студентлары Сара ханымның фортепьянода уйнавына кушылып, автор иҗат иткән көйләрне татарча башкарды.

Шушы елларда Хәсән Сарьянның "Бер ананың биш улы" әсәре "Казан утлары"нда дөнья күрде. Моңа кадәр таныш булмаган язучының повесте безне гашыйк итте. Яшьтән этисез калган гаилә язмышы, биш малай – биш бертуганның үзара мөнәсәбәте, дуслыгы – гади һәм тормышчан итеп сурәтләнгән. Автор белән очрашу җылы тәэсир калдырды. Әсәрнең язылу тарихы, геройларның прототиплары турында, бик теләп, үз фикерләре белән бүлешкән иде Хәсән абый ул вакытта. Ни кызганыч, китап авторының гомере кыска булып чыкты. Берничә айдан, китабының басылып чыкканын да күрмичә, 47 яшендә арабыздан китте.

Студент тормышы – кызыклы да, тыңгысыз да бит ул. I курсны тәмамлагач, безне Кукмара районына фольклор экспедициясенә җибәрделәр. Әнвәр Шәрипов җитәкчелегендә Күкшел, Мәчкәрә, Тәмәй һ.б. авылларда булып, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар җыйдык, татар халкының рухи байлыгы безне үзенә гомерлеккә гашыйк итте. Хушлашкан көнебезгә, хуҗаларга рәхмәт йөзеннән, зур концерт та куйдык. Хезмәтебезгә нәтиҗә ясарга, безне Казанга алып кайтырга дип, тарих факультетының декан ярдәмчесе Фоат ага Галимуллин да килгән иде. Якташлары концерт барышында аңа да сүз бирде, танылган радио дикторы буларак, бер шигырь укуын да үтенде. Фоат абый ялындырып тормады, матур йомшак тавышы белән Ф.Кәримнең "Кыңгыраулы яшел гармун" шигырен укыды.

Бакча эчендә госпиталь,
Ишекләре язулы.
Госпитальдә кемнәр генә
Белми икән Фазылны?!
Сугышка кадәр эшләгән
Донбасс шахталарында,
Эшләгән, исеме төшмәгән
Мактау такталарыннан...

Без өстәмә бу дәрес барышында аңлап өлгердек: шигырьнең көче һәм җанга тәэсире сөйләү осталыгыннан тора икән. Ә укытучыбыз, шуны аңлагандай, әле җырлап та җибәрде:

Ал кадыйм түшләреңә,
Гөл кадыйм түшләреңә.
Былбыл булып, гөлгә кунып,
Керәсең төшләремә.

Халык Фоат абыйның чыгышын көчле алкышларга күмде, безгә укытучыбызның яңа сыйфатлары ачылды. 1978 елда Фәнис Яруллинның "Сулыш" исемле китабы дөнья күргән иде. Аның белән әдип фатирында күрешүне дә Фоат абый оештырды.

Шат күңел, ачык йөз белән каршы алды алар 23 студентны. Фәнис абый ап-ак күлмәктән, мендәргә сөялеп утырган да, елмаеп, безгә карап тора. Бербер артлы аның шигырьләрен укыйбыз, яттан да сөйлибез. Шаяртып кына, табибләр куйган диагнозын да искә төшереп алды ул.

– Алар куйган срокны күптән уздым инде, хәзер ун елымны артык яшим, – дип елмая. Күңеле күтәренке, шигырьләрен укыганга балаларча шатлана. Аерылышыр алдыннан, барыбызга да автографлы китапларын бүләк итте. Шунда гына игътибар иттем: кул куюы да аңа җиңел генә бирелми икән... Әйе, нык рухлы, көчле шәхес иде Фәнис абый!..

Студент тормышы лекцияләр белән зачет-имтиханнар алышынып торган елга кебек бит ул: үз агымы белән ага бирә. Лекцияләр, практик дәресләр, ә аннары сизми дә каласың, сессия вакыты да килеп җитә. Атналар буе "дилдалайлык"та йөрү сессия вакытында йокы белми ятлауларга әнди. Төнге уникеләргә кадәр, кызлар белән бергәләп, темалар кабатлыйбыз, кайсыбыз алда билгеләнгән теманы ныграк ятлап алган, җавапны шул тезә. Нәтиҗәдә, курс арты курс алга таба бара.

Билгеле, туган йортларыбызга каникулларга кайткан чагында да безне "сәхрә" көтми. Барыбыз да авыл җиреннән бит, өйгә кайтуга ук салам-печән әзерләү, хуҗалыкны алып бару – безнең өстә. Авылны ташлап булмый. Төп эшебез белем алу булса да, күңелебез авылда, тамырларыбыз җиргә тоташкан. Җаныбызда крестьян психологиясе яши. Бервакыт, ашханәгә барганда, Алан егете Фәрит, куе печән баскан скверны күреп: "Вәт бозау арканларга шәп урын", – дип юкка гына ярып салмады...

(Дәвамы 5 нче биттә).

Мәдәни җомга
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

ИЛАҺИ ВӘ ҖӘМГЫЯВИ ИХТЫЯҖ

XXI гасыр кешелек тарихына, үзенең канлы елъязмаларыннан тыш, мөгаен, тирән рухи вә сәяси-икътисади кризис һәм цивилизацияләр көрәше чоры булып та кереп калыр. Ислам метафизикасы күзлегеннән караганда, бүгенге мәхшәрне «ахырзаман галәмәте» дип тә бәяләргә булыр иде. Белгечләр әйтүенчә, кешелек үзенең эволюцион хәрәкәтендә (китү-кайту циклында), борылыш чорын тәмамлап, ахырзаман эрасына күчеш кичерә. Җир аңыннан Күкнекенә борылуны тәэмин итү өчен мөшриклек диннәре иңдерелгән булса, кайту юлының Аллаһ хозурына кадәргесен инде бары тик хак динебез ислам гына ачыклый, аның соңгы маягын күрсәтеп, кешегә иң югары омтылыш ирегє бирә. Хәлбуки, аерым мәзһәбләргә бүлгәләнгән динебезне төрле уйдырма һәм мөшриклектән арындыру зарурлыгы да бәхәссез. Бу исә ислам яңарышына бүген илаһи ихтыяҗ барлыгын күрсәтә. Ә хак динебезне Рәсүлебез чоры сафлыгына кайтаруны Раббыбыз татарга йөкләгән, дидек (бу хакта сүз әүвәлге язмаларыбызда дәлилле булды кебек). Хактан да, борынгы төрки бабаларыбыз кайчандыр, тәңречелектән исламга күчеп, дини алгарыш кичергән һәм Аллаһка якынаюда яңа баскычка күтәрелгән кебек, татар иҗтимагый аңында хәзер дә охшаш интеллектуаль ихтыяҗ вә омтылыш (ислам диненең тәүхиди-иҗтиһади асылын аңлау һәм башкаларга да аңлату теләге) күзәтелә. Икенче яктан, кешелек дөньясын бүген биләп алган күпкырлы тирән кризис һәм аннан арыну теләге дини яңарышка (димәк, ислам яңарышына да) җәмгыяви ихтыяҗ глобаль дәрәҗәдә дә зур булуын күрсәтә.

Әлбәттә инде, ислам яңарышы бары тик ислам дөньясыннан гына башланып китә ала. Ә ул бүген шактый киң җәелгән һәм, икенчедән, төрле мәзһәбләргә бүленгән, дидек. Соңгыларын мөшриклектән арындыру һәм уртак фикергә китерү гади генә гамәл түгел. Моның өчен Коръәннең илаһи асылын (Аллаһ сүзен!) Хак Тәгаләнең адәми затка биргән иң зур бүләге – акыл дәрәҗәсендә дә аңлау мөһим. Ә бу адымның изге рамазан аенда ясалуы дин кардәшләребездән зур җаваплылык таләп итә, чөнки ул илаһи мәгънәгә һәм тарихи әһәмияткә дә ия. Мәгълүм булганча, Рәсүлебез чорында исламда мәзһәбләргә бүленеш булмаган. Ул соңрак, хәлифәләр заманында кертелгән дини кануннардан соң хак динебез адәми вә сәяси максатларда да кулланыла башлагач, асылда, дини йолалар дәрәҗәсендә генә барлыкка килгән һәм бүген дә шул ук максатларга хезмәт итә. Димәк, мәзһәби күптөрлелектән арыну – сөннәт гамәл. Аңлашыла ки, моңа ирешүнең бердәнбер юлы – исламның тәүхиди-иҗтиһади асылын акылыбыз белән аңлау һәм гамәл дә кылу.

Мәгълүм булганча, Рәсүлебездән соң ислам дөньясы нык киңәйгән һәм хәзер аның төньягы булып Казан һәм Татарстан санала. Эзотерика (эчке, яшерен гыйлемлек) буенча белгечләр исә моның ислам яңарышы өчен аерым мәгънәгә ия булуы турында да әйтә. Урталык җирләре дөньяның тарихи күчәре саналуын да исәпкә алсак, бу ике факторның бергә туры килүе зур тарихи әһәмияткә ия яңарышның кайдан башланырга тиешлегенә дә ишарәли: ислам яңарышы Урталык җирләреннән генә (Татарстаннан) башланып китә ала. Хактыр ки, Идел буенда ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын билгеләгән көннәрдә ислам дөньясындагы мондый тарихи борылыш инде символик мәгънә дә ала. Ә Урталык җирләрендә ислам яңарышы символы булып изге Болгарда калыккан Ак мәчет хезмәт итә. Әлбәттә, илаһи исламның тәүхиди-иҗтиһади асылын аңлау вә аңлатуда төп җаваплылык дин галимнәренә һәм руханиларга, шулай ук гыйбадәтханәләр вә дини уку йортларына (мәчет-мәдрәсәләрдән алып, Болгар ислам академиясенә кадәр) төшә. Ә моның өчен инде тиешле карарның Голәмалар шурасы дәрәҗәсендә дә кабул ителүе бик мөһим. Чөнки андый зарурлык бүгенге кискен геосәяси вәзгыять һәм глобаль колачлы рухи кризис белән генә түгел, дини яңарышка илаһи вә җәмгыяви ихтыяҗ артуы белән дә билгеләнә.

Әлеге мөһим факторлар татарга йөкләнгән тәкъдири миссиянең дә үтәлешен чын мәгънәсендә котылгысыз итә. Димәк, илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүдә үрнәк һәм әйдәп баручы көч булу өчен аңа җәмгыяви вә иҗтимагый эшчәнлекнең югарырак һәм заман таләпләренә тулырак җавап бирә торган ысулларына күчеп тә гамәл кылырга туры киләчәк.

Фоат УРАЗАЙ.

ЯЗЫЛЫР ӨЧЕН ИҢ КУЛАЙ ВАКЫТ!

Дуслар! 14 апрельгә кадәр ***«Мәдәни җомга»*** *газетасына ташлама белән язылып була. Әбүнәче декадасы көннәрендә язылу бәясе* ***603 сум 30 тиен****.*

«Мәдәни җомга» *газетасына Татарстанда язылу индексы –* ***П2355.***

Вакытында язылган ота!

Унынчы күмәк ифтар

30 апрельдә Татарстан мөселманнары Казанда ел да көтеп алына торган мәҗлескә – X Республикакүләм ифтарга җыелачак. Быел ул Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлап уздырылачак. Республикакүләм ифтар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, «Ак барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристик комплексы тарафыннан оештырыла.

Шунысы үзенчәлекле, юбилей санлы – X Республикакүләм ифтар 10 мең кешене кабул итәчәк. Әлеге чара, былтыргы кебек үк, «Казан ЭКСПО» халыкара күргәзмәләр үзәгендә үткәреләчәк. Республикакүләм ифтарда катнашучыларны гадәттәгечә бай мәдәни программа көтә.

Мәҗлес кунакларын каршы алу, җәмәгать белән намаз укуны оештыру, ризыкларны өләшү һәм ифтар тәмамланганнан соң җыештыру эшләрен башкару өчен 16 яшьтән алып һәм аннан өлкәнрәк булган 500 волонтер җәлеп ителәчәк. Әлеге зур саваплы хезмәтне башкаручы командага кушылу өчен (843) 237-86-18 телефон номерына шалтыратырга кирәк.

Эльмира СИРАҖИ.

Яшь режиссерларга ярдәм

«Время кино» питчингында (иганәче, инвестор табу өчен, үз фильмыңны тәкъдим итү) катнашачак төбәк проектларының исемлеге чыкты. Авторлар үз проектларын 9 апрель көнне Казанда яклый алачак.

Оештыручылар әйтүенчә, питчингка 25 төбәктән 66 гариза үткән. Шуларның 34 тулы метражлы нәфис фильм, 18е кыска метражлы, 14е – документаль. Проектлар Барнаул, Владивосток, Владикавказ, Горно-Алтайск, Грозный, Екатеринбург, Чита, Якутск һ.б. шәһәрләрдән кабул ителгән.

Гаризалар өч критерий буенча каралган. Беренчедән, гариза бирүченең яше 35тән узмасын. Икенчедән, проект региональ булсын. Өченчедән, ул гамәлгә ашырыла башлаган булырга тиеш.

Һәр номинация лауреаты «Алтын тәлинкә» кинопремиясе проекты кысаларында акчалата призга ия була. Питчинг Россиянең мәдәни инициативалар фонды ярдәме белән оештырылган.

Питчингның приз фонды – 700 000 сум. Тулы метражлы нәфис фильм өчен 350 мең сум, кыска метражлы нәфис фильм өчен 150 мең сум, документаль кино өчен 200 мең сум бирелә. Әлеге акчалар киноны төшереп бетерергә, монтажга, һ.б. өчен кулланыла ала.

Питчинг беренчел сайлап алу исемлегенә тулы метражлы нәфис фильмнар категориясендә Казаннан И. Рәхимбайның «Микулай», Ю. Захарова белән Е. Морозованың «Мишка» фильмнары кергән.

Әзһәр ага хатирәләре

Казанның Нариманов урамындагы элекке «Милләт типографиясе» бинасында Бөтендөнья татар конгрессының Аксакаллар шурасы оештырган «мәдәни ифтар» үтте.

Аның программасына ифтар мәҗлесе белән бергә Россия һәм Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакировның «Халкыбызның кадерле шәхесләре» китабы турында фикер алышу кертелгән иде. Шуны исәпкә алып, бу мәҗлескә татар конгрессы аксакаллары, күренекле галимнәр, мәдәният-сәнгать һәм дин эшлеклеләре чакырылган. Ифтарны гамәлгә куючы – конгрессның Аксакаллар шурасы рәисе, Милләт йортының хәзерге хуҗасы Рәүф Хәсәнов.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров Әзһәр Шакировның татар театрында, милли хәрәкәттә тоткан урыны, иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында әйтеп, мәдәни чараның төп мәгънәсен аңлатты.

Китап авторы театр сәнгатенең, күренекле әдипләрнең талантлы һәм бөек эшләре турында фикерләрен халыкка җиткерү теләге белән үз хатирәләрен иҗат итүе турында сөйләде.

Журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиев, китапка кергән хатирәләргә, аңгәмәләргә югары бәя биреп, аларның милли тормышка, сәнгатьне халыкка җиткерүгә тәэсире зур булуын дәлилләде.

Кичәгә килгән затлы милләтпәрвәрләр, милли аксакаллар татар халкының мәгърифәткә, мәдәнияткә омтылуы темасының Әзһәр Шакиров иҗатында һәм китапларында чагылуына игътибар юнәлтте. Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәтов һәм музыка остасы Фуат Әбүбәкиров Әзһәр Шакировның яраткан җырларын башкардылар.

Манарага туристлар зыян сала

«Казан Кирмәне» музей-тыюлыгының баш архитекторы Рөстәм Зәбиров туристларның Сөембикә манарасындагы кирпечләр арасына акча һәм теләкләр язылган кәгазь төргәкләре тыгуларын әйтте.

«Манараның аскы өлешендә сизелерлек дәрәҗәдә үзгәрешләр бар. Израильдәге – «Елау дивары» объектындагы кебек, халык кирпеч белән кирпеч арасындагы измәне чокып, арасына акча, теләкләр язылган кәгазьләр тутыра. Бу бинаның җимерелүенә китерә. Мин моны вандаллык дип тә атар идем», — диде ул.

Архитектор әйтүенчә, капкалар куйгач, туристлар манараның эчке ягына керүдән туктаган.«Әмма ул капка манараның тышкы ягы чыгып тора торган почмакларын капламый, шуңа киләчәктә манара тирәсен тулаем тотып алаосы иде. Мәсәлән, киртәләр куярга мөмкин. Ярыклар барлыкка килгән урыннарны болай гына сылап куеп булмый, ул конструкциянең тышкы кыяфәтен үзгәртәчәк», – ди ул. Р. Зәбиров бинаның нигезен ныгытуны дәвам итәргә кирәклеген белдерә.2015 елда эшләнгән реставрацияләү проекты да әлегәчә гамәлгә ашырылмаган.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

1 нче биттә – Питрәч районы Чыты авылында Мәүлә Колый исеме бирелгән мәчеттә намаздан соң дога кылу. **Салават Камалетдинов** фотосы. «Татар-информ».

Шуша – төрки башкала

Әзәрбайҗанның тарихи шәһәре Шуша 2023 елның төрки дөнья мәдәният башкаласы дип игълан ителде. Карар ТӨРКСОЙ халыкара төрки мәдәният оешмасы даими шурасының Бурса (Төркия) шәһәрендә узган гадәттән тыш утырышында ачыкланды.

«Шуша – безнең мәдәният үзәге. Кызганычка, ул авыр көннәр кичерде, анда әзәрбайҗан халкының мәдәни мирасын рәхимсез рәвештә юк итәргә тырыштылар, ләкин максатларына ирешә алмадылар. Шуша – әзәрбайҗан халкының җиңү символы», – дип чыгыш ясады Әзәрбайҗан мәдәният министры Анар Кәримов.

Элек Панахабад дип аталган Шуша шәһәренә 1752 елда нигез салынган, ул Карабах ханлыгының саклану ныгытмасы буларак барлыкка килгән. Гасырлар дәвамында Көньяк Кавказның сәяси һәм мәдәни үзәкләренең берсе булып торган, күпсанлы тарихи әсәрләре белән дан казанган, анда бик күп күренекле галимнәр, композиторлар һәм музыкантлар дөньяга килгән, музыка сәнгате шаһәсәрләре туган, шунлыктан ул «Әзәрбайҗан музыкасы бишеге» дип тә атала.

ТӨРКСОЙ халыкара төрки мәдәният оешмасы даими шурасының гадәттән тыш утырышы Бурса шәһәренең төрки дөнья мәдәният башкаласын ачу тантанасы программасы кысаларында үтте. Аны ТӨРКСОЙ даими шурасының вакытлыча координаторы, Төркия мәдәният һәм туризм министры Мәһмәт Нури Эрсой җитәкләде. Җыенда Әзәрбайҗан, Гагаузия, Казахстан, Кыргызстан, Төньяк Кипр, Төркмәнстан, Төркия, Үзбәкстан кебек җөмһүриятләрнең мәдәният министрлары яки вәкилләре, төрле илләрнең илчеләре катнашкан.

Билгеле булганча, 2022 елда төрки дөньяның башкаласы итеп Төркиянең Бурса шәһәре сайланган иде. Бу хакта карар 2021 елның сентябрь аенда кабул ителде. 31 март көнне Бурсаның төрки дөнья мәдәнияте башкаласы булуы уңаеннан зур тантана оештырылды. Анда ел дәвамында төрле мәдәни чаралар, очрашулар дәвам итәчәк.

ТӨРКСОЙ халыкара төрки мәдәният оешмасын Кыргызстан премьер-министр киңәшчесе, элеккеге мәдәният, мәгълүмат һәм туризм министры, халык язучысы Солтан Раев (фотода) җитәкләячәк. С.Раев даими шураның гадәттән тыш утырышында 2022-2025 еллары өчен генераль секретарь итеп бер тавыштан сайланды.

«Төрки халыкларга мөһаҗирлек хас, ул традицияләребезнең үсүенә, камилләшүенә китергән һәм һәртөрле үсешнең яңа циклын булдырган. Безнең ата-бабаларыбыз борын-борыннан Енисейдан алып Анатолиягә кадәр төрки дөньясының мәдәни цивилизациясен тараткан, аның формалашуына өлеш керткән. Бүгенге дөнья картасында көчле төрки дөнья бар икән, моның өчен без бабаларыбызга бурычлы. Безнең максатыбыз – төрки дөньясының рухи көчен киләчәккә җиткерү, аны үстерү, мәдәни интеграцияне ныгыту, төркиләр мәдәниятне, төрки бердәмлеген дөньяга тарату. Шәхсән мин бу эшләрне үзебезнең изге миссиябез дип саныйм», – дип чыгыш ясады Солтан Раев.

ТӨРКСОЙ оешмасын 14 ел җитәкләгән элеккеге генераль секретарь Дүсән Касеинов үзен әлеге вазифага Солтан Раев тәкъдим иткәнен белдереп, аның алдан күрә белүчәнлеге һәм бай тәҗрибәсе ТӨРКСОЙ эшчәнлегенә уңышлар китерәчәгенә тулысынча ышануын әйтте.

Туган ягында яд иттеләр

Балык Бистәсе районында язучы Әхәт Гаффар истәлегенә узган II «Гаффар дәвамчылары» иҗат бәйгесенә йомгак ясалды. Бәйгене язучының кызлары Сөмбел һәм Ләйлә Гаффаровалар белән берлектә районның мәгариф бүлеге, Татарстан Язучылар берлеге оештырды. Концерт номерлары белән үрелеп барылган бәйрәм кичәсендә язучы турында истәлекләр белән бүлешteләр, аның балалар өчен язылган әкиятләрен тамаша кылдылар.

Әдәбият галиме Тәлгат Галиуллин Әхәт Гаффарның әсәрләрен дә, иҗади активлыгын да югары бәяләде. 80-90 нчы елларда чын мәгънәсендә Әхәт Гаффар чоры иде, диде ул. «Әҗәл» хикәясеннән башлап бер-бер артлы повесть-романнары, драма әсәрләре, публицистик язмалары чыкты. Үзенә күрә феномен булды. Әсәрләре, бер яктан, гади генә күренә, икенче яктан, символларга, метафораларга, кинаяле сөйләмгә корылган. 80-90 нчы елларда иҗади активлыгы ягыннан аның янәшәсенә куярлык башка язучыны атый алмыйм», – диде галим.

Район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Айгөл Вафина Әхәт Гаффарның гади, эчкерсез булуын, туган ягына һәрвакытта да талпынып кайтуын ассызыклады.

«Әхәт абый яшьләргә, якташ язучыларга игътибарлы булды. Минем дә шигырьләрне алып китеп, республика газета-журналларына кереш сүзләр язып чыгара иде», – дип истәлекләре белән бүлеште шагыйрь Вәзыйх Фатыйхов.

Әдәби бәйгенең төп инициаторы, оештыручыларның берсе Сөмбел Гаффарова әтисенең туган ягында әлеге бәйгене дәвам итә алуларына сөенечен белдерде.

Бәйрәм чарасы ахырында каләм тибрәтүче мәктәп укучыларына – II «Гаффар дәвамчылары» бәйгесе җиңүчеләренә дипломнар, акчалата бүләкләр һәм әдәби китаплар тапшырылды.

Алинә БИКМУЛЛИНА.

● Уэльста яшәүче бик горур кельт халкы, «Бер генә инглиз дә әйтә алмасын өчен», 1870 елда авылларын Llanfairpwllgwyngyllgogerychwyrndrobwllllantysiliogogogoch дип атаган, ул хәзергә кадәр сакланган. Авылда яшәүче 3400 кеше исә атаманы бик җиңел әйтеп бирә, ул «Изге Тайсилио чиркәве һәм кызыл мәгарә янындагы тиз агымлы елга ярындагы ак чикләвек агачлыгы чытырманында Изге Мария чиркәве» дип тәрҗемә ителә.

● Испаниядә һәр икенче ир-ат – Хосе, һәр икенче хатын-кыз Мария исемле.

● Америкада иң популяр фамилия – Смит (аннары – Джонсон һәм Уильямс), Россиядә – Смирнов (икенче урында – Иванов, аннары Кузнецов һәм Попов).

● Кытайда иң популяр фамилия – Ли (аны 90 миллионнан артык кеше йөртә), аннары – Ван һәм Чжан.

Җәмигъ мәчетенә беренче адым

1 апрельдә Җәмигъ мәчетенең архитектура концепциясен эшләүгә халыкара конкурс игълан ителде. Гыйбадәтханәнең архитектур проект эскизларына конкурс өч ай дәвам итәчәк. «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында Татарстан Премьер-министр урынбасары, Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе Шамил Гафаров әйтүенчә, мәчетнең кайчан кулланышка тапшырылуы билгесез. «Кыска вакыт эчендә мәчетне төзеп бетерүгә бөтен көч куелачак. Ул Казан гына түгел, бөтен Татарстан территориясендә фундаменталь объектларның берсе булачак», – диде ул «Татар-информ» агентлыгы брифингында.

Җәмигъ мәчетен төзү Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча федераль чаралар планына кертелгән. «Моны ислам кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүдә мөһим вакыйгаларның берсе дип саныйм», – диде Шамил Гафаров.

Бүген мәчет комплексының проект-смета документациясен әзерләү буенча техник бирем эшләнә.

«15 көн эчендә катнашу теләге турында гаризалар кабул итәбез. 8 июльдә Корбан бәйрәме алдыннан нәтиҗәләрен чыгарачакбыз. Беренче этапта иҗади коллективлар сайлап алына, аннары 2,5 ай эчендә эскиз проектлар эшләнә. Икенче этапта сайлап алынган алты коллектив арасыннан жюри җиңүчене билгеләячәк», – диде Ш.Гафаров.

Конкурсның жюри составына танылган архитекторлар, фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре, мөселман дин әһелләре, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары керәчәк.

Өч призлы урын каралган. Финалистка 2,5 млн сум, икенче урынга 1 млн сум бирелә, өченче финалист 500 мең сум алачак. Бәйгедә Россия һәм Татарстан гына түгел, төрле илләрдән архитекторлар катнаша ала.

Казанда Җәмигъ мәчете төзелеше турында мәгълүмат белән «Игелек-Доброта» рухи-әхлакый үсешкә теләктәшлек республика фонды сайтында танышып бару мөмкин булачак.

«Сайтта фондның эшчәнлеге, төзелеш барышы, иганә ярдәме турында бөтен мәгълүмат урнаштырылып барачак, – дип хәбәр итте фондның башкаручы директоры Илнур Рәхимов. – Беренче вакытта яңалыклар лентасында эскиз проектлары конкурсына кагылышлы мәгълүмат булачак, конкурс эше тәгәлләнгәч, фонд эше һәм төзелешкә бәйле яңалыклар куелачак».

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин фикеренчә, мәчет заманча һәм татарча булырга тиеш. Проект ясый торган кеше моны аңларга тиеш, чөнки җюрида күпчелек татарлар булачак, диде ул.

Җәмигъ мәчетен Кырлай паркы урынында төзү карар ителгән. Аллаһ йорты кимендә 10 мең кеше сыйдырышлы зурлыкта булачак. Мәчеткә нигез ташы 20 майда салына, көзен төзелеш эшләре башланачак.

Мөгаллимнәргә файдалы семинар

«Сәйдәш» мәдәни үзәгендә педагоглар өчен балалар бакчаларында татар телен укытуның заманча нәтиҗәле методлары турында икенче укыту семинары узды. Анда 500 ләп белгеч катнашты. Чарада Казан Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова һәм Казан Мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары Альберт Әхмәтов чыгыш ясадылар.

Семинарда Казанның биш әйдәп баручы педагогы татар телен укытуда заманча алымнар куллану тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Әйтик, Айсылу Лотфуллина күрсәтмә модельләштерү технологиясе ярдәмендә рус телле балаларны татар теленә өйрәтү мөмкинлеге, Руфия Алиәкбәрова мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне – татар телен укытканда интерактив тактаны куллану турында сөйләде. Фәния Хәсәнова тавыш ассоциацияләре ысулын рус һәм татар телләрендә авазадаш сүзләр җыю юлы белән бергә файдалану үзенчәлекләрен аңлатты. Эльмира Абдуллина Сингапурның Zoom In белем бирү структураларының берсе белән таныштырды. Гөлнара Гатауллина балалар белән үткәрергә мөмкин булган «Тылсымлы кулчатырлар» дигән осталык дәресе уздыры.

Без дә студент идек...

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Шатлыклары, борчулары белән тәүге курслар да артта калды. Без дә шомардык бугай, имтиханнарга керү алдыннан калтырап торулар бетте. Кемдер төнге каравылчы булып балалар бакчасына, кемдер заводка урнашты.

Йөк төяү-бушатулардан да йөзне чөермәдек. Бервакыт, вагон-холодильникка туңдырма төяргә баргач, алты-җиде татлы ризык ялап, тамакларыбызга салкын тидереп кайткан идек. Вагонеткаларны эткәндә, тәгәрмәчләре чокырга туры килгәч, аларны чыгара алмый интеккән сабаклар да истә...

Аннары бүлмәдәге дүрт егет тә газ аппаратлары заводына төнге сменага эшкә урнаштык. Студент буларак, гел төнге сменада эшләргә рөхсәт иттеләр. Хезмәт авыр түгел. Билгеле бер формада калайлар киселеп куелган. Шуны, махсус платформага салып, пресс белән бастырасың. Минут эчендә заготовка газ миченең арткы яки алгы өлешенә әйләнә, кайнар цехта буятасы гына кала. Сменага ике йөз форма ясарга кирәк. Планны тулысынча тутырмасак та, 70-80%ка үтәгәнбездер. Иртәнге дүртләрдә кайтып кына мендәргә борын төрттек...

Казанның тире эшкәртү комбинатында да эшләп алдык әле. Ул вакытта республиканың һәр колхозында 600-700 баштан да кимрәк сарык асралмый, шәхси хуҗалыкларда да мал күп иде. Татарстан туннар өчен чимал әзерләүдә СССР күләмендә алдынгы урыннарда барды.

Амбардай иркен, биек түшәмле фабрика бинасы. Эчендә сарык тиреләре эскертләп өелеп ята. Махсус чаннарда тиренә җебетеп, барабаннарга тарттырып эшкәртәләр. Йонын бер тигезлектә калдырып кыркалар. Чимал дистәләрчә операция аша уза. Электромоторлар гөрелди. Кышын, тыштан салкын һава кереп, бөтен җирне пар болыты каплап ала. Резин итекләр киеп, тачкаларда дистәләрчә тирене тегендә-монда күчерергә, буяу цехына, киптерү цехына алып барырга кирәк. Шуңа күрә безнең белгечлекне пропускларга “относчик-подносчик” дип язганнардыр да инде. Фабрика ял көне дә туктамый. Исе-хушы борынны ярып керсә дә, көненә ун сум түлиләр. Бу инде зур акча. Мондый хезмәт хакын югары квалификацияле токарьлар яки әйдәп баручы инженерлар гына ала. Фабрикада эшләүчеләрнең күбесе – авылдан килеп урнашкан, авыр хезмәттән курыкмаган, шәһәрдә төпләнеп калырга теләгән егетләр һәм кызлар. Күп кенә эш кул хезмәте белән башкарылса да, мех комбинаты эшкәрткән тиреләр бик сыйфатлы. Алардан тегелгән туннар, үзебездә генә калмыйча, Мәскәүгә, хәтта чит илләргә дә озатыла иде...

IV-V курска җиткәндә, күпчелек студентлар шәһәр тормышына ияләнеп тә бетте. Кур-

Г.Тукай клубында сезон ачылу кичәсе. 9 октябрь 1981 ел.

сумлык “Электроника”, “Весна” кебек кулга тотып йөри торган магнитофоннар пәйда булды. Җыелысы булмаса да, әле кибетләрдә сирәк очрый торган, студентлар өчен бик тә модалы ясалма туннар күренә башлады. Үзем дә, ул вакытта студентның төп атрибуты булган, дипломатны, вак-төяк базарыннан, егерме биш сум акчамны җәлләмичә, сатып алганым хәтердә...

Фәнис Яруллинда кунакта.

Институтта да, тулай торакта да җитәкчелек ягыннан артык басымны сизмәдек. Кызлар белән бер бинада яшәгәч, тәртип бозулар сирәк була иде. Укытучыларыбыз да, ай саен булмаса да, рейдлар ясап тора, яшәү шартлары белән кызыксына. Яшьләр, кибетләрдә сатылмаса да, каяндыр Высоцкий җырларын яздырып алып кайта. Бәйрәмнәрдә уку залында дискотекалар оеша, төрле кичәләр уза. Җәйләрен уен-биюләр урамдагы “пятачок”ка күчә. Тирә-якка татар-рус бию көйләре яңгырый. Ул вакытта иң кәттә техникалардан саналган

егетләргә дә танцыга җыйнала. Урамдагы уеннарның сугыш яки җәнҗал белән тәмамланганын бөтенләй хәтерләмим.

Студентларга төрле ташламалар каралган. Автобус, трамвай-троллейбусларда билет ярты гына бәя алына. ДОСААФ белән институт арасында килешү төзелгән. Машина йөртү таныклыгы алу өчен түләү 120 сум булса, студентка - 60, мото-

циклга 50 урынына 25 сум иде. Мотоциклга “права”ны күбебез шушында укып алдык.

Без укыган елларда Толстой урамында студентлар ашханәсе (“Межвузовская” дип йөртелә иде) ачылды. Иң уңайлысы – комлекслы аш. Менюга беренче һәм икенче ашлар, ипи һәм чәй кергән. Бәясе 30-35 тиен. Очсыз да, чират та тиз бара. Соңрак бу тәртипне башка ашханәләр дә кертә башлады...

Шулай итеп, көндәлдә онытылмас хатирәләр калдырып, үзенең борчу- мәшәкатьләре белән биш ел үтеп тә китте. Кулыбызга дипломнар эләктергәч, Казан

лый, Пионерлар урамындагы тулай торакка юл алдык.

Кил әле, Иделнең
җиләс җиле,
Юлларга чәчәкләр сип әле.
Ак булып, саф булып
истә калсын
Казанның кадерле кичләре.
Иделгә сузылган айлы юлдан
Тын гына, моң гына җыр ага.
Сагынырбыз, дуслар,
бу кичләрне
Чәчләргә чал кергән
чорда да...

Йә Ходай, болар барысы да кичә генә булган кебек иде, ә санап карасаң, 40 ел үтеп киткән. Кабатлап булмас, гомер буе сагынырлык яшьлек! Бүгенге җәмгыять агышына күз ачып карасаң, җаныңны ачытырдай хакыйкать тә чиксез. Йә, менә без һичбер эштән чирканып тормыйча, йөген дә бушаттык, зәмһәрир салкын кичләрдә ДНД бригадасы булып, Казан тынычлыгын саклап йөрдек. Ә хәзерге яшьләрнең, безнең шикелле авыллардан килеп, турыдан-туры университетларга керү һәм, иң мөһиме, һичбер блатсыз көенчә һәм бер тиен дә акча түләмичә уку, белем алу мөмкинлеге бармы? Тагын да яманы – ел саен йөзәрләгән студентны үзенә каршылап, йөзәрләгән егет һәм кызларны бәхетле итеп, зур тормышка, газиз телебез хакына көрәшкә чыгаручы ИНСТИТУТ кайда? Һәм олы бер милләтнең яшәү умырткасы, белем казаны, мактанычы булган Ана телебезне укытуны нигә туктаттылар? Телсез дә, белемсез дә калган татар милләтенең киләчәге бармы?

Без бәхетле илнең бәхетле бер буыны булып яшәдек. Ә балаларыбыз, оныкларыбыз нишләр?..

Атнаның сәяси мизгелләре

КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ

Гаммәви мәгълүмат кырында купкан рәсми хәбәрләр күрәше, Киев янындагы Буча каласында урын алган вакыйгаларга бәйле рәвештә, халыкара аренада һәм хәтта БМО дәрәҗәсендә дә зур бәхәсләр китереп чыгарды. Ачыклап үтик, Киев Россия гаскәрләрен Буча каласын калдырып киткәнче тыныч халыкка каршы күпләп ерткычлыклар кылуда гаепләде. Мәскәү исә моны катгый төстә кире какты, аның видеоязмалардагы дәлилләрен Украина радикаллары тарафыннан кылынган провокация буларак бәяләде һәм, моны фаш итү ниятендә, кичекмәстән БМО КШның гадәттән тыш утырышын үткәрү тәкъдиме белән чыкты. Утырышта Киев һәм Мәскәү Бучадагы хәлләргә карата һәркайсы үз версиясен бәян иткән. Анда Украина лидеры В.Зеленский да чыгыш ясаган. Үз илендә тынычлык урнаштыру өчен ул БМО КШга, йә Россияне вето хокукыннан мәхрүм итәргә, йә оешманы, үз форматын үзгәртеп, тынычлык хакына реаль эшли башларга, йә (әгәр инде башка мөмкинлек тапмаса) үз-үзен таратырга киңәш иткән.

Әмма Буча вакыйгасы эзсез үтмәде. АКШ хәзер Россиянең Кеше хокуклары буенча БМО шурасыннан чыгарылуына ирешмәкче. Башка чаралар да күрелә. Күп кенә илләр һәм халыкара оешмалар (АКШ, Бөекбритания, Канада, Франция, Япония, ЕС һ.б.) Россиягә каршы яңа санкцияләр кертә. Мәскәү үзе дә санкцияләр кулланганда итә: ЕС җитәкчелегенә һәм Европа депутатларына ул Россиягә керүне тыйган. Ә Төркия һәм Грузия Россиягә каршы санкцияләрдә катнашмый. Соңгы вакытта Россия дипломатларын илдән сөрүләр дә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәгә җитте (алар дистәләр белән исәпләнә: Алмания – 40, Испания – 25, Словакия – 35, Франция – 30 һ.б.). Кытай бу мәсьәләләрдә аерым позициядә кала: ул үзен Украинадагы низагта катнашучы як түгел, дип саный. АКШның кайсы якны булса да сайларга кыставын ул “минем якны сайла” дигәнне аңлата, дип саный. Шул ук вакытта Украинадагы низагны Кытай сөйләшүләр аша хәл итү яклы. Ә Россия-Украина сөйләшүләре әлегә видеоконференция режимында дәвам итә. С.Лавров, Истанбул очрашуыннан соң, Киев Мәскәү тәкъдимнәрен зур реальлек белән бәяли, диде. Ул президент куйган максатларны килешүдә беркетү юнәлешендә эшләүләрен дә әйтте. Ике арадагы килешүгә якынаюлары турында В.Зеленский да сөйләде. Ул Украинаның иминлек гарантлары итеп БМО КШ илләрен, шулай ук Алмания, Бөекбритания, Израиль, Канада, Кытай, Польша һәм Төркияне күрә.

Фоат УРАЗАЙ.

Кичәләр дә уйга сала икән...

Март аеның соңгы көннәрендә Чаллы каласына мәркәздән зур гына әдәби десант килеп төште. Чаллыда 21 ел буе нәшер ителгән “Мәйдан” журналының күркәм йоласы бар: ул редакция булдырган Илдар Юзеев исемендәге әдәби премияне бер яктан – Татарстан, икенче яктан – Башкортстанда яшәп иҗат итүче берешәр әдәбиятчыга һәр ел саен бүләк итеп бара. Башкортстан ягында нәкъ шушы ук рәвешчә ике республика вәкилләренә дә бүләк ителүче Фатыйх Кәрим исемендәге премия дә бар-барын, әмма ике тугандаш милләт арасын төзәтү, аеруча җанисәп саен кискенләшә барган киеренкелекне, хәтта дошманлашуны туктату өчен әле өстәмә чаралар күрсәң дә артык булмас сыман.

Татарстан белән Башкортстан арасында дуслык күпере төзү юнәлешендә Чаллы каласында элегрәк тә күркәм эшләр аз башкарылмады. Моны аеруча Казан белән Уфада, рәсми хакимиятләр көенә “ләббәйкә” әйтеп торучы вак-төяк чинушалар гына күрмәмешкә сабышты. Чөнки, имеш, ике республикада да мәдәният өлкәсендә кылынган һәрбер гамәл фәкать алар имзасы, алар башлангычы белән башкарыла, Тукайчарак әйтсәң, алар сызгырмыйча яфрак та селкенми бит. Ә асылда Чаллы каласында гомер итүче җырчы Равил Галиев инде дистә еллар элек үк, Татарстан белән Башкортстан җырчыларын бер төркемгә туплап, Ык елгасының ике ягында “Дуслык күпере” дип аталган җыр фестивале уздыра. Ул шушы төркем белән әүвәл Татарстанның Азнакай, Ютазы, Бөгелмә, Әлмәт, Чаллы кебек үзәк халыкларын Башкортстанда гомер итүче Радик Динмөхәммәтов кебек җырчылары, музыкантлары белән таныштырып чыга. Аннары инде төркем Ык аръягына күчә дә Башкортстанның Октябрьск, Туймазы, Дүртөйле, Нефтекама... сәхнәләрендә, ә соңгы аккорд итеп Уфа каласында “Безне гасырлар бәйләгән, без гомергә бергә!” шигаре астында гастрольләрне тәмамлый. Янә бер мәртәбә кабатларга мәҗбүр: Равил Галиев һәм аның аркадашлары көч салган әлеге тырышлыкны Казан белән Уфа түрәләре генә күрми!..

“Мәйдан” журналы да, нәшер ителә башлауның беренче аеннан ук Башкортстанда, Удмуртия, Оренбург өлкәсендә иҗат итеп, үз әсәрләрен үзләре гомер иткән кече Ватан матбугатында дөньяга чыгара алмыйча газап чигүче милләттәшләребезгә, аеруча яшь талантларга үз мәйданын бирүне, әдәби ярдәм кулы сузуны максат иткән иде. Аллага шөкер, журнал Удмуртия һәм Башкортстанда яшәүче татар әдипләренә багышланган махсус саннарны да, аларның шигырь, поэма, повесть-хикәяләрен дә дөньяга күп чыгарды. Мисалга, Балтач районы мәктәпләрендә балаларга белем бирүче Гөл-Миһади соңыннан Башкортстан Язучылар берлегенә дә кабул ителде... Иҗау каласында яшәгән көе күпчелек әсәрләрен “Мәйдан” журналы битләрендә яңгыраткан Ринат Баттал соңыннан Татарстан Язучылар берлегенең Һади Такташ премиясенә дә лаек булды.

Шушы ук уңайдан зуррак бүләкләр, хәтта Тукай премиясе турында да сүз кузгату мөмкин. Әнә, Уфада яшәгән көе Татарстан татарлары өчен дә якынга әверелгән җырчыбыз Идрис Газиев Башкортстанның – С.Юлаев, Татарстанның Г.Тукай исемендәге иң югары бүләкләренә лаек булды бит әле. Бездә Тукай бүләгенә дәгъва итүчеләр өчен старт бирелдеме, ел саен бер дистәдән артык шагыйрь яисә прозаик, исеме йөз кешегә таныш рәссам, көйче, хәтта биючеләргә хәтле чәчрәп сәхнәләргә чыга. Ана теленә һәм изге тарихына балта чабылган чакта газиз милләтен яклап сүз әйтүчеләрне көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый, ә Тукай премиясен эләктереп алу өчен терсәк сугышу оештырудан да тартынып торучы юк. Уйга килегез, Татарстаннан тыш, Башкортстан мәйданында да бер миллионнан артык татар яши бит әле! Ул бер миллион арасында әле бер ай элек безнең Кремль эчендәге “Хәзинә” сараенда меңнәрне сокландырырдай күргәзмә ясап киткән Вәкил Шәйхетдинов атлы күркәм рәссам яши. Ул миллион татар арасында Татарстандагы татарлар кулына килеп җитмәгән бер дигән романнар, поэмалар, повестьлар иҗат итеп яшәүче шагыйрь һәм прозаиклар бар. Ә Тукай премиясе дигәндә нигә алар турында һаман онытабыз?! Татарстандагы татарлар беренче сортлылар да, Башкортстандагы татарлар безгә ятиммени?!. Менә, аңладыгызмы, Чаллыдагы “Мәйдан” журналы булдырган Илдар ага исемендәге премия нинди рольне үти?..

Чаллыга мәркәздән Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкчелегендә иҗатлары кабат-кабат пропагандага һич тә мохтаҗ булмаган Марсель Галиев, Газинур Морат, Нәбирә Гыйматдинова, Вахит Имамов, Рафис Корбан белән бергә, әлбәттә инде, Илдар абыйның улы Салават Юзеев та килгән иде. Чаллы хакимияте һәм язучылар оешмасы күршедәге Әлмәт, Мамадыш, Түбән Камадан да каләмдәшләрен чакырырга онытмаган. Чаллыда яныбызга Татарстан Дәүләт Советы депутатлары Камил Нугаев белән Марсель Мингалимов һәм “Татмедиа” акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шамил Садыйков килеп кушылу да олы шатлык булды. Һәммәбезне җыеп, Чаллыда былтыр гына ачылган “Адымнар” мәктәбенә алып киттеләр. Мәктәп белән танышу, түгәрәк өстәл артында милли рух темасына әңгәмә, ахыр чиктә мәктәпнең актлар залында Илдар Юзеев исемендәге премиянең быелгы лауреатларын бүләкләү тантанасы булды. Татарстаннан шагыйрь Рафаил Газизов, Башкортстан дәүләт университеттан галимә һәм шагыйрә, безгә бик тә сирәк күренгәнгә күрә сагындырган Лилия Сәгыйдуллинаның шушы бүләкне алуын сөенеп күзәттек. Быел “Мәйдан”ныкылар журналны нигезләгән һәм аның мөхәррир йөген дистә еллар буена тарткан Факил Сафин белән без фәкыйрегезне дә шушы ук премия белән билгеләп үтәргә карар кылган, сәхнә йөзен без сукбайларыгыз да күреп төштек, рәхмәт!..

Кичә агышында янә без моңача эшләп җиткермәгән бер чир ачыкланды. Татарстанның һәрбер районында диярлек “Якташлар” җәмгыяте бар, алар Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама кебек калаларда да актив эшли. Берәү өчен дә сер түгел, Татарстанның һәр районында Башкортстан җирлегендә туса да, Казан югары уку йортларында укыганнан, йә гаилә корганнан соң бездә яшәп калган “башкорт татарлары” да меңнәрләгән. Ике арадагы “алыш-биреш” дистә еллар гына түгел, ә гасырлар буена дәвам итә. Аннары XVII-XVIII гасырда дип әйтмим, әле “кул сузымындагы” чорда, “столыпинча” яңа авыллар нигезләү башлангач та, Татарстандагы бүгенге Актаныш, Мөслим, Әгерҗе, Лениногорск, Ютазы, Азнакай районнары җирләрендә яшәгән дистәләгән авылның йөзләрчә гаиләләре чагыштырмача “ташландык” хәлдә яткан бүгенге Илеш, Краснокама, Дүртөйле, Балтач, Борай, Чакмагыш... җирләренә күчеп китә һәм анда яңа хутор, яңа салалар нигезли. Иске нигездә калучылар белән күчмәннәр дистә еллар буена уртак җыен, уртак базарлар үткәрә, хәтер һәм нәсел җебен өзмичә яши. Әүвәл канкойгыч инкыйлаб, аннары туганара сугышлар нәтиҗәсендә генә аралашу өзелә, кардәш-туганлык ерагая.

Районнарыбызда һәм калаларда якташлык кичәләре үткәргән чагында без менә шул – ерак киртәләр артында калган кардәшләребезне искә алырга, үзебез үткәргән чараларга кунак итеп чакырырга онытабыз. Мисаллар меңнәрләгән. Учалы районының Ахун авылында туып-үскән Нәзифә Кадыйрова Мамадыш районындагы Урта һәм Кече Кирмән авылларына концерт белән килгәч, табын артында кирмәнлеләрнең нәкъ Ахундагы бер үк җыр һәм көйне ишетеп, күз яшьләренә бирелә, туганнарын таный. Актаныштагы Иске Богады авылы белән Чакмагыштагы Яңа Богады кешеләре әле сугышка кадәр үк очрашып, гел бер үк җырны суза торган булганнар, бер үк биюне башкарганнар, бу йола сугыштан соң гына өзелгән... Дәвам итәсе юк: Татарстан белән Башкортстан арасындагы “Берлин стенасы” булып саналган Ык һәм Сөн елгаларының ике ярында да чип-чиста татар авыллары тезелешеп ята. Безгә ул инкыйлаб яки сугыш аерган киртәне атлап узасы, замананың зәһәр җилләре тузгыткан туганнарны табып, өр-яңадан кушыласы иде. Ул чагында җанисәп саен үпкәләшеп-әрепләшеп йөрүләр дә, иң яманы – татар җирләренә килеп ыру баганасы, тәре баганасы утыртып йөрүләргә дә җирлек калмас иде. Туганлык кулын, ярдәм кулын, иң беренче чиратта, без сузарга тиеш!

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

ЙОЛДЫЗ

Таркалуны көткән чакта Кирәк безгә берләшү...

БЕЗ БӘЛЕШ ТӘ, ТОРТ ТА ТҮГЕЛ

Нигә соң бу милләтемне
Бүлмәкчеләр кисәкләп.
Шулай итсәк, бөек халык
Югалыр дип исәпләп.
Андыйларны төп башына
Утырту кирәк шәпләп.

Таркалуны көткән чакта
Кирәк безгә берләшү.
Бергәләшеп киләчәккә
Туган телдә эндәшү.
Бер-беребезгә кардәшләрдәй
Бәхет- шатлык өләшү.

Кискәләргә торт түгел без,
Түгел зур итле бәлеш.
Әгәр бүленә калсак бүген,
Яман булыр безнең эш.
Һәркем бу хакта белергә
Һәм онытмаска тиеш.

Мишәрме син, типтәрме син –
Бөек татар баласы.
Ана телен киләчәккә
Сиңа алып барасы.
Милләтне исән-сау килеш
Бергә саклап каласы.

Аерылганны аю ашар,
Ә бүленгәнне – бүре.
Көтмәсен шул бүленүнең
Бик тә куркыныч төре.
Кара урманда адашсак,
Чәйнәр бүре өере.

Һәрбер сакауга бер милләт
Булмыйдыр ул, җәмгать.
Сораганда «Мин татар!» дип
Үз сүзеңне горур әйт.
Шикләреңне эчеңә йот,
Башыңны югары тот.

Шундый зур милләт баласы
Булганыңа сөен син.
Бабаң рухы, онытың да
Синең белән сөенсен!

Безне бик тә тырышалар
Таркатырга, бүләргә.
Туры килмәсен һичкемгә
Милләт белән түләргә.
Бер йодрык булып калыйк без,
Теләмәсәк үләргә.
Шуны ничек аңлатырга
Бүген һәрбер җүләргә?!

БИЛӘР. ИЗГЕ ЧИШМӘ

Монда һәр таш тарих сөйли
Тыңлый белгән кешегә.
Монда күңел кайнап ташый,
Аннан туңып күшегә;
Шәһри Биләр. Заманында
Атаклы булган, диләр.
Шул хакта сөйләргә теләп,
Исәме әллә җилләр?!
Гыйлем үзәге булган, ди
Ташпулат булган өйләр.
Кеше мескен ни эшләсен
Югалган әнә илләр.
Серле җир бу. Монда хәтер
Тарих капкасын кага.
Монда күктән йолдыз булып,
Борынгы бабаң бага.
Йокыга киткән җаннар да
Монда, гүя, терелә.
Бабайларга рәхмәт укып,
Куллар күккә үрелә.
Без килмешәк токым түгел,
Алыплар нәселеннән,
Һәрбер ташка, һәр үләнгә
Батырлык яшеренгән.
Илен саклаган халкыма
Табигать һәйкәл куйган,
Гүя, тамган күз яшьләрен
Бер чишмә итеп җыйган.
Ә тулгач, ургып агызган
Биек тау үзәненнән.
Саркый бугай ул халкымның
Хәтере үзәгеннән.
Табигать һәйкәл куйган шул
Булмасын белгәч бездән.
Бу һәйкәлгә башың и, син,
Ихтирам белән тезлән.

Чишмә суы күз яшеме –
Нәрсәдер тама күздән..

Шуңа да ул шифалыдыр,
Тылсымлыдыр шуңа да.
Игелек теләп, иман теләп,
Халкым җанын сугара.

МИН

Мин үземнән зур түгелмен,
Бары тик үзем кадәр.
Кичерегез, кемнәргәдер
Зуррак күренсәм әгәр.
Куркак, диеп кимсетмәгез,
Оятсызлардан качсам.
Йолдызларга буем җитә,
Аяк очыма бассам.

ТАҢ АЛДЫ

Төн. Дөнья дөм караңгы.
Күңелемне берәү какты,
Йокымнан уятты –
Илһам икән.
Хәл белергә килгән,
Икәү учак яктык,
Хисләр ташты, акты,
Очты чаткы.
Ул чаткыдан
Җиһанга ут капты.
Инде дөнья якты –
Таң атты!

ТАТАР ЗИРАТЫНДА

Каләмдәшләр, шагыйрь дуслар,
Күбәйдегез инде анда.
Артып торасыз һаман да,
Безне дә шул көтә алда.

Тик бер сорау яши җанда:
– Нишлисез сез икән анда?
Тик ятасыз дип кабердә
Ышанасым килми бер дә...

Шигырь тулган дәртле җанны
Куялмыйдыр туфрак күмеп.
Борчыласыз булыр, беләм,
Телебезнең хәлен күреп.

Күрешәсездер, йөрешәсездер,
Барасыздыр кунакларга...
«Туган тел»не сузасыздыр
Шулай күрешкән чакларда.

Бардыр әле берлегегез,
Рәисе туры Тукайдыр.
Талантлар күп инде сездә –
Урынбасар чал Туфандыр.

Бик күп анда сезнең ишләр:
Такташ, Зөлфәт, Мөдәррисләр...
Ник китәсез уйламыйча,
«Дөнья, – диеп, – безсез нишләр?»
Әйе, дөнья сезсез соры,
Туган телгә сез бик кирәк.
Талантлар да туа сирәк.
Сез киткәнгә сыктый йөрәк.

Татар зиратында йөрим
Бата – чума кар эченнән.
Кабат җиргә кайтарырга
Килсә иде дип көчемнән...

ОМСК. ВОКЗАЛ. ТӨНГЕ ӨЧ

Төн карасын ерта тальян тавышы
Себер каласында перронда.
Татарымның күпме моң-сагышы,
Сагынуы да сыйган бер моңга.

Шәһәр йоклый. Ә перронда бәйрәм –
Татар белән татар очрашкан.
Араларда озын юл ятса да,
Җаннар безнең бергә тоташкан.

Поезд китте. Тальян тавышы тынды,
Ә моңнары калды күңелдә.
Бүген менә яңа шигырь булып,
Кәгазь битләренә түгелә.

Кайда гына язмыш ташламасын
Син, татарым, минем туганым.
Бу сәяхәт күзләремне ачты –
Ярый, татар булып туганмын!

ЭТ ХӘЛЕ

Ул – сакчы эт, этнең дә
Төн шикелле карасы.
Хуҗасына тугры булган
Атасы да, бабасы.
Тугрылыкны ул алардан
Алгандыр мирас итеп.
Яши бөтен тирә-якны
Дер селкетеп, өркетеп.
Ак эт бәласен карага
Япкалыйлар еш кына...
Күп вакыты бәйдә уза,
Ә кайчакта – ычкына.
...Беркөн шулай чын иреккә
Татыган чакта тәмен,
Бер көтү кәҗә күренде,
Бозып дөньяның ямен.
Бу хәлгә нинди эт түзсен,
Ул да уктай атылды.
Тотса, берсен чәйни иде,
Ярый, качып котылды.
Эт тавышына хуҗа чыкты,
Кулында озын таяк.
Этне кабат бәйгә куйды,
Һич тә тормады аяп.
Ә кәҗәләр йөгерешә,
Ә кәҗәләр иректә.
Иректә буласы килә
Кара этнең дә бик тә.
Чылбыр калын, кадак та нык –
Ычкыну инде кая?!
Зур табакта аш чыгарды
Хуҗа малае бая.
Алдына китереп салды
Дәү бер сөяк тә, итле.
Бер сыер боты булса да,
Алмаштырмый ирекне.

Хуҗага ихлас тугрылык
Ирекне чикли икән,
Дөньяның бар ләззәте дә
Ирекkә җитми икән.
Нигә кирәк булды инде
Кәҗәләрне куарга.
Нигә тик кенә ятмады?
Башы җитми шуңарга.
Имеш, ул бик яхшы сакчы,
Хуҗага хезмәт итә.
Гомерен дә җәлләп тормас –
Тугрылыкка ни җитә?!
Озак басып карап тордым
Күңелләрем сызланып...
Күп күргән, күп өргән этне
Чын күңелдән кызганып.
Юк, юк чайкалма күңелем,
Чайпалма – түгелерсең.
Без дә шушы бәйдәге эт
Хәлендә түгелме соң?!

ДӨНЬЯ УЛ – МИН!

Явызлыкны күрә-күрә
Кысылдылар күзләрем.
Замананы сүгә-сүгә
Кырысланды сүзләрем.
Бик үзгәрдек?!
Ник үзгәрдек?
Әллә дөнья, әллә мин?
Җавабын төгәл белмимен,
Күрәсең, дөнья ул – мин!

РЕДАКЦИЯДӘН. Танылган шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, А.Алиш исемендәге әдәби бүләк иясе Йолдыз Шәрапова 10 апрельдә 60 яшь тула. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән котлыйбыз, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.

Мәдәни җомга
8 апрель
№13, 2022

ӘДИПНЕҢ КАБЕРЕ

Март аенда мәшһүр әдип, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галим Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулды. Әдипнең беренче иҗат үрнәкләре дөнья күрә башлауга да 115 ел булды. Аның башлангыч чор хикәяләренең бер-бер артлы «Шура» журналында, шуннан соң аерым китап булараk Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә нәшер ителүе үк ул әсәрләрнең югары сыйфатлы булуын белдерә. Мәсәлән, 1911 елда аның «Диңгездә», «Ике йөз ел элек», «Уты сүнгән җәһәннәм», 1912 елда «Карт ялчы» китаплары шул рәвешле укучыга тәкъдим ителә. «Казакъ кызы» романының тәүге вариантын да ул шул нәшриятка тапшырган була. Шул чорда «Бубый мәдрәсәсе»нә бәйле рәвештә оештырылган тентүләр барышында ул кульязма юкка чыга.



1911 елның көзендә Галимҗан бер сәүдәгәр балаларын укытырга дип Киевкә китә. Аның шуннан Дәрдемәнд исеменә атап тагын бер кульязма җибәргәнлеге мәгълүм. Шул ук 1912 елда аның Казанда атаклы «Яшь йөрәкләр» романы басылып чыгачак... Шул елда әдипкә 25 яшь тулган була.

Әмма Г.Ибраһимовның иҗат биографиясендә бүген дә ачыкланып бетмәгән бик күп ак таплар барлыгы да күпләребезгә мәгълүм. Ләкин әлегәчә аларга аерым тукталучылар булмады шикелле. Әйтик, шул ук «Яшь йөрәкләр» романы нәшер ителүгә бәйле бер сер. 1902-1903 елларда Оренбургта укыганда ул Гаяз Исхакый белән актив аралаша. Г.Исхакыйның «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыткан чоры. Кайберәүләр әйтүенчә, Галимҗанның сул эсерлар фиркасына керү фикере дә шул йогынты нәтиҗәсендә туа. Шул ук елларда Галимҗан Г.Исхакыйның туганнан туганы, Орск шәһәрендә матбугат сәүдәсе йортын тотучы кеше белән дә таныша. Әлеге романны Казанда нәшер итүгә заказ бирүче дә шул кеше була, дип искә ала иде кайбер Оренбург ягы кешеләре.

Әйе, иҗат итә башлавына йөз елдан артык вакыт үтүгә карамастан, аның иҗатына да, җәмәгать эшчәнлеге һәм биографиясенә дә бәйле ак таплар тулаем өйрәнелгән һәм ачыкланган дип тәгәл генә әйтә алмыйбыз әле. Әйтик, аның үз мөхәррирлегендә нәшер ителгән «Ирек», «Безнең юл», «Чулпан» газеталарында чыккан, милләтебез язмышына кагылышлы фикерләре өстенлек иткән күпсанлы хезмәтләре бүгенге заман укучысына тулаем мәгълүм түгел дияргә була. Дөресен әйткәндә, нәкъ шундый эчтәлекле хезмәтләре һәм шул юнәлештәге эшчәнлеге өчен бит инде ул зинданга утыртыла һәм җәфалап үтерелә дә. Әдипнең ул чор язмаларының барланмавының төп сәбәбе, әлбәттә, әлеге газеталарның Совет хакимияте чорында кабул ителмәгән сул эсерлар рухында чыгарылуына бәйледер. Татар милләте язмышын сул эсерлар күзлегеннән карап бәяләүгә...

Әйе, Совет хакимияте дәверендә әдипнең милләт язмышына кагылышлы эшчәнлеген барлау, аларны тәфсилләп язып чыгу мөмкин дә түгел иде. Ә 1991 елдан соң, элекке «ябык» архивларның тимер ишекләре бераз ачыла төшкәч исә, Г.Ибраһимов шәхесе һәм язмышы белән кызыксыну нишләптер кими төште. Аның иҗатын һәм эшчәнлеген өйрәнүче элекке олпат галимнәр картайды яисә вафат булды. Алар урынына яңалары килмәде бугай.

Шушы уңайдан бер-ике кечәрәк фактка тукталып китәсем килә. Әдипнең иң актив иҗат иткән елларында аның иң якын ярдәмчесе һәм кайбер хезмәтләренең рус теленә тәрҗемәчесе булган Өммегөлсем апа Мөхәммәдева 1960-1980 еллар аралыгында иренә багышлап берничә биографик очерк, өч документаль повесть язган иде. 1980-1990 елларда мин аның шундый эчтәлекле, бай мәгълүматлы ике китабын – «Эзләнүләр» белән «Олы юл»ын бастырып чыгаруда катнаштым. Ул китапларның мөхәррире дә, алар турында матбугатта беренче хәбәр бирүче дә булдым.

Шул хезмәтләрен тупларга керешкәнче Гөлсем апа Г.Ибраһимовны якыннан белгән кешеләр белән аралаша, хатлар алыша, төрле-төрле документларның күчермәләрен алдыра. Әдипкә кагылышлы булган фотоларны туплый. Әдипнең 1920-1921 елларда бергә яшәгән беренче «зәүҗәны» Мәстүрә Фәйзуллина һәм Киевтә чакта якыннан аралашкан якташы Гөлсем Әхтәмова-Ордубатская белән дә хатлар алыша. Өммегөлсем апа сөйләвенчә, Уфа-Бәләбәй төбәге морзалары нәселеннән булган Гөлсем туташ белән Галимҗан арасында дуслык мөнәсәбәтләре бөреләнеп килгән бер вакытта Киевтә байтак кына яшьләрне кулга алалар. Алар белән бергә Галимҗан һәм аның дусты, Киев университеты студенты Хәлил Еникиев тә кулга алына. 1912 елда ул университетта Идел-Урал белән Кавказ төбәгеннән чыккан 184 мөселман шәкерт белем алган. Алар арасында Бәләбәй ягы морзасы, Уфада яшәүче адвокат Әхтәмов Биньямин кызы Гөлсем дә була. Төрмәдән чыгып, Казанга кайткач та Галимҗанның шул якташ кыз белән хат алышып торулары турында миңа Өммегөлсем апа сөйләгән иде. «Берничә хат алышкач та аларның аралары өзелә. Галимҗанның 1914 елда Кавказга ял итәргә барышлый яңадан Киевкә «кереп чыгуы»ның бер сәбәпчесе дә әлеге кыз була. Ләкин инде ул вакытта Гөлсем Әхтәмова Киев университеты студенты Фирүз Ордубатскийга вәгъдә биреп өлгергән икән. Шул сәбәпле әдипнең Гөлсем белән үзара мөнәсәбәтләре ялганмый кала...» Калган гомерен иренең туган илендә - Әзәрбайҗанда уздырган Гөлсем 1960-1970 елларда Казанга юллаган хатларында шул хакта да язган...

Ө.Мөхәммәдева тарафыннан алынган менә шундый хатлар, фотолар, документ күчермәләре тупланган калын-калын папкаларның хәзерге язмышы миңа билгесез. Элек алар әдибәнең эш өстәле өстендә өелеп тора иде. Гөлсем апа вафат булгач, бер очрашу вакытында аның кызы Сөмбел дә: «Мин аларның кайда икәнлеген белмим», – дип җавап бирде. Әмма ул хатлар, ул документлар бөтенләй үк юкка чыкмагандыр дип уйлыйм. Гөлсем апа аларны бәлки Дәүләт музее мирасханәсенә тапшырып өлгергән яисә Г.Ибраһимов иҗатын барлау өлкәсендә зур эшләр башкарган олуг галим Мансур Хәсәневкә бүләк иткән булгандыр.

Шуңа охшаш тагын бер очрак. Казанда Г.Ибраһимов исемендә йөргән мәктәп бар иде. Ленин районының Восстание урамындагы 89 нчы татар мәктәбе. Урыныннан кузгала алмыйча ятакта ятучы, булачак халык шагыйре Фәнис Яруллинны урта белемле итеп тәрбияләүдә үз өлешен керткән мәктәп. 1960 еллардан бирле аның директоры Вазыйх ага Надриев белән ара-тирә аралашып яшәдек. Бер районнан чыккан кешеләр идек. 1990 елларда мин аны бик тә борчылган кыяфәттә Язучылар берлеге урнашкан бина ишегалдында очраттым. «Г.Ибраһимовка багышлап 35 ел дәвамында тупланган истәлек язмаларын һәм фотоларны югалттык. Ике-өч ел элек, илдә зур үзгәрешләр башлангач, аларны без шушында китереп биргән идек. Шуларны хәзер таба алмыйлар. Ул кыйммәтле истәлек язмаларын, фотоларны кем, кая куйган – белмиләр. Анда әдипне соңгы елларда карап, тәрбияләп торган соңгы хатыны Хәдичә апа Фәтхуллинаның истәлекләре дә бар иде. Ул истәлекләр башка беркайда да басылмады, бездә аның тулы нөсхәсе иде. Мансур Хәсәнович: «Ул папкаларны нигә анда тапшырдыгыз? Үзәк музейга бирәсе булган», – ди. Нишләргә инде хәзер? Шул тарихи истәлекләрнең язмышын ачыклый алмыйча, якташым тиздән вафат та булды. Ул берничә альбом, папкаларга тупланган хәзинәләрне кемдер, «кирәкмәс нәрсәләр» дип, чүпкә ташлагандыр, мөгаен. Вазыйх ага әйтүенчә, ул истәлек язмалары бик авырлык белән тупланган. «Авыру Хәдичә апа янына күкрәгенә Ленин орденын таккан әдәбият укытучысы үзе барып йөрде. Ул апа укучыларны гына кабул итми иде», – дип тә өстәп куйган иде якташым. Хәер, Афзал ага Шамов та ул ханымның истәлек сөйләргә ни өчендер авырсынганлыгын искә ала иде. Шул сәбәпле Хәдичә Фәтхуллина язмалары «Г.Ибраһимов турында истәлекләр» (1966) китабына да кермәгән.

* * *

Г.Ибраһимовка кагылышлы тагын бер ачыкланып бетмәгән мәсьәләгә тукталып китик. Еш кына аның биографиясенә багылышлы язмаларда «җәсәде җирләнгән кабере билгесез», дигән сүзләргә тап буласың. Тууына 125 елга багышланган, 2012 елда узган конференциядә дә шул җөмләне әйтүчеләр булды. Илбашы И.Сталин идарә иткән елларда эзсез югалучы татар зыялылары исемлеге бик зур. Алар турында сүз чыкканда, бик еш кабатлана торган әйтем инде ул: «Эзсез югалды, кабере дә билгесез» диюләр. Чынлап та аларның күпчелегенең кайларда үлеп калганлыгы да, җәсәде җирләнгән җире дә билгесез. Әйтик, Казан зинданнарының берсендә атып үтерелгән дип фаразланган Кәрим Тинчуринның кайсы зиратта җирләнгәне әле дә ачыкланмаган бугай. Совет хакимияten урнаштыруда актив катнашкан комиссар һәм классик язучы Шамил Усмановның да кабереңең кайдалыгы билгесез кебек. Фәтхи Бурнаш соңгы айларын хәзерге Самара шәһәре читендәге «Безымянка» исемен йөрткән лагерьда үткәргән. Шунда үтерелгән. Ул лагерьда булган тоткыннар зур бер хәрби завод төзелешендә эшли. Шундый заводлар төзелешләрендә төп кул көче саналган һәм вакытсыз вафат булган меңнәрчә тоткыннарның каберләре билгесез кала. Шул исәптән Ф.Бурнашның да, «асыл сөякләре менә шушында ята» дип, тәгәл генә әйтә алмыйбыз. Аларны эзләү мөмкинлекләр дә тудырылмады. Күпчелек тоткыннарның кайсы лагерьда җан биргәнлеге турындагы хәбәрләр дә якыннарына бик соңлап җиткерелде. Кайберәүләргә андый мәгълүматны 1990 еллардан соң гына ачыкларга мөмкинлек тудырылды. Совет хакимиятенең «иң явыз дошманнарын» аклау карары СССР таркалгач кына чыгарылды иҷ. Шулар арасында Совет хакимияten урнаштыруда актив катнашкан, Гражданнар сугышы батыры буларак ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән Муса Мортазин да бар. Аның төп гаебе «милләтче Зәки Вәлиди «әшнәсе» булуында...

Г.Ибраһимов җәсәден барлауга бәйле вакыйгалар башкачарак

САКЛАНГАНМЫ?

тора. Бердән, ул рус телендә «ГУЛАГ» дип исемләнгән ярым яшерен лагерьларның берсендә үлеп калмаган. Ул төрмәдә вафат булган. Хокукый яктан – юридик караштан чыгып фикер йөрткәндә, беркадәр өстенлеккә ия урында, дәүләтнең бер махсус оешмасы карамагында. «ГУЛАГ»лар исә – ярым яшерен оешмалар. Алар һәм андагы тоткыннар турында рәсми мәгълүматлар ярым яшерен төстә сакланган. Шул җәһәттән караганда Г.Ибраһимовның язмышы күпчелек башка тоткыннар язмышыннан аерылыбрак тора. Икенчедән, И.Сталин вафат булгач ук, күпчелек тоткыннарның аклану ихтималы турында карар кабул ителде. 1954 елда Казанда да аклану ихтималы булганнар турында уйлана башлыйлар. Партия өлкә комитетының икенче секретаре Салих Батыев җитәкчелегендә репрессияләнүчеләрне аклау комиссиясе төзелә. Шул елның декабрендә Тел, әдәбият һәм

ны). Аңа Г.Ибраһимовның эшен яңадан карауны үтенеп Партия Үзәк комитетына гариза язуны тәкъдим итә. Бик хәвефле хәлгә калу ихтималын уйласа да, әдип Еникиев, мондый йөкләмәне үтәү үзенең намус эше дип, риза була. Озакка кичектермичә гаризаны яза да Г.Бәшировның кулына тапшыра». Берничә ай үткәч, 1955 елның 29 октябрендә СССР Прокуратурасы Ә.Еникинең өй адресына Г.Ибраһимовның аклануы турында хат юллый. Шуның нигезендә тиздән Татарстан хөкүмәтенең Галимҗан аганың исемен һәм мирасын халкына кайтару турындагы махсус карары чыгарыла. Ул карарда әдип әсәрләренең күп томлыгы тиз арада нәшер ителергә тиешлеге, аңа багышлап истәлек язмаларын туплау кирәклеге турындагы тәкъдимнәр белән янәшә каберен барлау бурычы да куелган була. Шул карар җирлегендә оештырылган аклау комиссиясенә Язучылар берлегеннән дә берничә кеше керә. Язучылар оешмасы

нен ачыкларга тиешле булган, хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән икенче бер комиссия утырышларында да катнаша. Аның сөйләвенчә, ул комиссия Пләтән төрмәсе эшчәнлегенә бәйле булган дистәләгән кеше белән әңгәмә оештыра. Шул кешеләр арасында әдип белән бер вакыттарак төрмәдә утыручылар да, төрле дәрәҗәдәге төрмә хезмәткәрләре дә була. Шулар арасында әдипкә карата яхшы мөнәсәбәттә булган бер татар хатынын да еш искә ала иде Афзал ага. Нишләптер минем хәтердә ул табибә буларак истә калган. Исемен инде онытканмын. «Олы юл» повестенда исә «санитарка Фатыйма» гына телгә алына. Болар икесе ике кеше булгандырмы – әйтә алмыйм. Шул ук Афзал ага сөйләвенчә, комиссия эшләгән вакытта төрмәдән мәетләрне зиратка илтүче олаучы да, шул вакыйгада катнашкан тагын берничә кеше, шул исәптән Казанның Архангел бистәсе зираты хезмәт-

гы идарә рәисе М.Әмир, аның урынбасары З.Нури һәм әлеге комиссия вәкиле А.Шамовлар башлаган ул эшне «очлап чыгу» вакыйгасында миңа да катнашырга туры килгән иде. Татарча язулы зур бер гранит һәйкәл 2012 елда үз урынында иде. Галимҗан аганың җәсәден төрмәдән алып чыккан төндә күмелгән 3-4 кеше кабере өстенә куелган ул. Алда атап үтелгән комиссия ачыклаган урын шушы була. Әлеге дәүләт комиссиясе төзегән актта әдип белән бергә җирләнгән башка кешеләрнең дә исемнәре теркәлгән булырга тиеш. Шул кабердән ике-өч метр арырак, бер төркем агачлык ышыгындарак, икенче бер татарча язулы истәлек ташы да бар иде. Ул кабердә әдипнең замандашы булган Закир Самитов ята. Афзал ага белән Зәйнәп Самитова сөйләвенчә, бу ике кабер ияләрен дә Пләтән төрмәсеннән бер үк төндә, бер чанада алып чыгалар.

Әлеге комиссия тарафыннан

●Атаклы Пләтән төрмәсенең дәвамчысы - 2 нче төзәтү колониясе.

●Архангел зиратында Г.Ибраһимовка һәйкәл.

тарих институтында үткәрелгән бер җыелышта да шул хакта башлап сүз кузгатыла. Ә киләсе ел башында С.Батыев Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гомәр ага Бәшировны: «Шундый кешеләр язмышы турында СССР Язучылар берлеге җитәкчесе Александр Фадеев белән дә киңәшеп кайт», – дип Мәскәүгә юллый. А.Фадеев аңа гаепсез дип фаразланган тоткыннарның аклануын үтенеп дәүләт оешмаларына аерым-аерым хатлар юлларга киңәш итә. «Андый хатларны гаепләнүченең берәр туганы язарга тиеш. Андый кеше булмаганда – һәр язучы да яза ала. Тик андый хатны язучы кеше партиядә торучы булмаска тиеш», – дип кисәтә Фадеев.

Шушы уңайдан Г.Мөхәммәдеваның Г.Ибраһимов язмышына багышланган «Олы юл» повестена күз салыйк. «Казанга кайткач та оешма рәисе Әмирхан Еникине чакырып ала (Олуг әдипнең якташын һәм үзен аның рухи шәкерте дип санаган язучы-

һәм нәшрият вәкилләре төркеменең җитәкчесе итеп сугыш ветераны А.Шамов билгеләнә. Ул комиссиягә билгеләнүенең сәбәпләрен үзе болайрак дип аңлаткан иде. 1930 елларда китап нәшриятында эшләгәндә, ул Г.Ибраһимовның иң соңгы әсәрләрен бастырып чыгарырга әзерләгән, әдип белән хатлар аша аралашкан була. Булачак соңгы китапның корректура вариантын редакцияләгәндә бер-ике җөмләне үзенчәрәк төзәткәне өчен автор бер хатта аңа шелтә дә белдергән була. Ләкин ул редакцияләгән соңгы китап басылып чыкмый, корректурасы юк ителә. Ул китапка әдипнең «Безнең көннәр» романының дәвамы һәм «Караңгы төн мәңге булмас» романы кергән була. «Әлекке шул хезмәтләремне истә тотып, миңа аның өч томлыгын туплап, бастырып чыгару һәм башка эшләр йөкләтелде», –дип сөйләгән иде Афзал ага.

А.Шамов шулай ук әдипнең кайчан, кайда җирләнгә-

кәре дә әле исән була. Алар сөйләгәнгә нигезләп, комиссия Г.Ибраһимов җәсәденең кай тирәдә җирләнгәнен ачыклый. Һәм шул хакта махсус акт төзелә. Бүген ул комиссия документлары архив киштәләрендә сакланган булырга тиештер.

Хәзер шәһәр уртасында калган Архангел зиратының үзәк аллеясеннән ерак булмаган бер мәйданчыкта олуг әдип истәлегенә куелган затлы кабер ташы бар. Ул истәлек ташы 1967 елда куелды. Шул чорда-

шулар ачыклана: төрмәдә үлүчеләрне кыш айларында атнага бер мәртәбә җыеп җирләгәннәр. Г.Ибраһимов хастаханәдә вафат булган атнада Пләтән төрмәсеннән берничә кеше чыгарып җирләнгән. Алар барысы да бер чокырга күмелергә тиеш булган.

З.Самитов хатыны Зәйнәп апа бу вакыйгаларны болайрак искә ала иде. Төрмә вакыйгаларына кагылышлы комиссия утырышларында ул да катнашкалаган. Шул комиссия төзегән актта аның да култамгасы булырга тиеш икән.

Әйе, үзе әйтүенчә, комиссия актларына кул куючылар арасында ул да була. Ире Гражданнар сугышы чорындагы бер гаскәри берәмлекнең комиссары булган кеше. Аннары Закир Самитов 1934 елга чаклы Казанда урнашкан милли укчы дивизиядә хезмәт иткән. Шул елның көзендә аны «Кызылармеец» газетасының элекке мөхәррире, яңарак кына Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайланган К.Нәҗми Татарстан әдәби фондына эшкә чакырган. Ә 1937 елда аларның икесен дә кулга алалар. Әлеге Беренче татар укчы дивизиясенең элекке командиры булган Я.Чанышев белән бергә ниндидер бер «милли хәрәкәттә катнашуда» гаеплиләр аларны. Закир Самитов шул «яшерен оешманы» оештыруда ук гаепләнгәндер, мөгаен. Шул сәбәпле 1938 елның гыйнварында ул төрмәдә атып үтерелә. Аның белән бер вакыттарак кулга алынган К.Нәҗми белән Я.Чанышев бераз соңрак азат ителә.

Шул элекке комиссарның чая хатыны Зәйнәп апа ирен зинданга илтеп япкач та, аның белән элемтә урнаштыру мөмкинлекләрен эзли башлый. Һәм төрмә тирәсендәге татар бистәләре кешеләрен якыннан белүе сәбәпле, тиздән үз дигәненә ирешә дә. Ире белән аратирә хәбәрләшә башлый. Закир атып үтерелгәч, иренең җәсәден төрмәдән кайчан алып чыгачакларын да алдан белә. Шул төндә эшләүче олаучы белән дә таныша. Ирен башкалардан аерып күмү чарасына керешә. Зират кешеләре төркеменә эләгеп, әлеге олауны каршы алуда катнаша. Төрмә кешеләре киткәч үз ирен читкәрәк алып чыгып җирли. Шул олаучы аңа: «Болар арасында язучы Галимҗан да бар» дип әйткән була. Әдипнең каберен ачыклаучы комиссия эшенә дә Зәйнәп Самитова шул төнге олаучы һәм башкаларның күрсәтмәсе буенча эләгә.

Зәйнәп апа Самитова белән миңа берничә мәртәбә озаклап сөйләшеп утырырга да насыйп булды. Төрмәдә хезмәт итүче милләттәшләребез белән ни рәвешле элемтә урнаштыра алганлыгын да сөйләгән иде.

Өстәп шуны гына әйтәсе кала: тоткынлыкта вафат булган яисә үтерелгән башка бер генә татар язучысының каберен ачыкларга булышлык иткән комиссия төзелми шикелле. Сугыш башлангач та, Мәскәүдән Алабуга шәһәренә җибәрелеп, анда унике көн яшәгәннән соң үз-үзенә кул салган рус шагыйрәсе Марина Цветаева каберен барлауга карата чыгарылган карардан башка. Ул комиссия 1967 елда СССР Язучылар идарәсе тарафыннан оештырылган иде. Шагыйрәнең каберен ачыклау акты Алабуга шәһәре башлыклары катнашында төзелде. СССР Литфондының Татарстандагы вәкиле буларак, ул комиссия карарын үтәүдә мин дә катнашкан идем.

Лирон ХӘМИДУЛЛИН.

Мәдәни җомга
8 апрель
№13, 2022

Мәгъсүм НАСЫЙБУЛЛИН

ТАМАША

Олы бәйрәм якынлашып килгән чак. Ире белән киңәшкәннән соң, Фәридә Нәбиева Казанда иң данлыклы ресторанга китте. Аны озын буйлы, төз гәүдәле, чем-кара чәчле яшь егет каршылады. Зәвык белән заманча итеп үстерелгән сакал-мыек егетнең какча йөзен тулган ай кебек түгәрәк итеп күрсәтә иде.

– Бәйрәмне ресторанда каршыламакчы идек, – дип башлады сүзен Фәридә. – Дүрт кешелек бер өстәл билгели алмассызмы?

– Соңлагансыз, ханым... – диде өлкән официант итагатьле генә, аннары: – Туктагыз әле! – дип, исенә нәрсәдер төшергәндәй күршедәге бүлмәгә кереп югалды. Озак та үтмәде, кире әйләнеп чыкты. – Бәхетегез бар икән, моның өчен хакның бер өлешен хәзер үк түләргә кирәк. – Нәбиеваны тыңларга әзерләнеп, кулына куен дәфтәре белән каләм алды.

Фәридә, өлкән официант әйткәнчә, аванс итеп алтмыш сум акча түләде.

– Эш бетте, кәлтә җыясы гына калды, – диде официант, шыгырдап торган кызыл унлыкларны кесәсенә салгач. – Рәхим итегез, ханым, сезне нәкъ сәгать алтыда көтәбез. – Өстәп, Нәбиевага чакыру кәгазе бирде.

Санаулы көннәр тиз узучан, бәйрәм дә килеп җитте. Чакыру кәгазендә күрсәтелгән вакытка Нәбиевләр ресторанга килгәндә, парлы кунаклар җыела башлаган инде, әмма ишек бикле иде әле. Җыелган халык артканнан-арта барды. Арадан берәү сәгатенә күз салды да, ишек шакыды. Җавап-мазар булмады. Ишек төбенә сыенган халык хәйран калды. Теге шакыган кунак, түземлеген җуеп, ресторан ишеген дөбердәтергә кереште. Шалт-шылт иткән тавыштан соң ишек теләр-теләмәс, яртылаш кына ачылды.

– Нишләп тәртип бозасыз? – дип, усал кыяфәтле швейцар кунакларның юлын бүлде. – Үз өйләре диярсең!.. Кертмим!.. Берегезне дә!.. – диде ул, кырт кисеп. Сүзнең тәмамлануын аңлатып, кулы белән тотып торган ишекне кире япмакчы булды. Тик бикли алмый калды: җыелган ир-ат ишек тоткасына нык ябышкан иде.

– Бу ни дигән сүз?! – дип гаҗәпләнде әзмәвердәй таза кунак. Аңа кушылып, калганнары кесәләреннән чакыру кәгазьләре алып күрсәттеләр, акча кабул иткән кешенең исемен атадылар: «Шестеркинны чакырыгыз!»

– Шестеркин юк! – дип кырт кисте швейцар, тагы да усалланып.

– Ул кирәкми безгә, ресторанга үткәрегез, үз өстәлебезгә...

Халык та сөйләшә белә.

Швейцарның үз кырыгы һаман кырык иде:

– Мин бернәрсә дә белмим! Кертмәскә кушылды, шуның белән вәссәлам! Таралыгыз! Югыйсә!..

Һич көтмәгәндә вакыйга детектив төс ала башлады. Кәефе кырылган кунак төркеме, чакыру билетларын селти-селти, нәрсәдер төшендермәкче булып алга атлады. Аңа карап швейцар мыегының бер бөртеге дә селкенмәде. Тагы да усаллана төште ул. Халык гөж килде, директорны таләп итте. Җир йоткан диярсең, директоры да күренми бит. Озак тартыша торгач, швейцарга ярдәмгә тагы бер ир-ат чыгып кушылды. Директорның урынбасары икән.

– Җәмәгать, дим, иптәшләр! – җыелган халыкны тынычландырмакчы булып, урынбасар кулын күтәрде. – Көтелмәгән хәл килеп чыкты, иптәшләр. Шестеркин чирләде бит әле.

И тартышты халык, и бәхәсләште! Алдан уйлап ятланган тантаналы бәйрәм сүзләре юкка чыкты. Ресторан алдындагы тәшвиш сабан туендагы аркан тартышын хәтерләтә иде. Тартышып та күрсәтте инде казанлылар! Нишлисең, бер якның да арканны кулдан ычкындырасы килми. Ниһаять, усал швейцар да, тасма телле урынбасар да арканны ычкындырырга мәҗбүр. Каты куллы, бердәм иде кунакка дип килгән халык.

Ниһаять, чакырулылар төркеме мең бәлаләр белән залга үтеп керде...

Иртән эшкә килүенә өлкән тикшерүче Гайнан Ибраһимовны прокуратурада ресторан директоры көтеп тора иде.

– Гайнан ага, бездә бик аяныч хәл бит әле, – диде чырае сытылган юантык директор. – Зинһар, ярдәм итегезче, – дип ялварып, бер бит кәгазь бирде.

Тикшерүче алып, укырга кереште. Гариза икән: «Ресторанда өлкән официант булып эшләгән Шестеркин Николай Семенович, бәйрәм өстәле вәгъдә итеп, кешеләрдән заказ кабул иткән. Якынча исәпләүләр буенча, 3780 сум акча җыйган. Аларны кассага тапшырмыйча, юкка чыккан. Шестеркинны үзебез эзләп карадык, әмма нәтиҗәсе булмады. Н.С.Шестеркинны эзләп табуыгызны, ул урлаган акчаны түләтүегезне үтенәбез. Директор... Баш бухгалтер...»

– Ресторан штатында ничә кассир бар? – дип эндәште аңа тикшерүче.

– Өчәү, – диде директор, сискәнеп.

– Нишләп акчаны алар җыймады? – дип дәвам итте Ибраһимов.

– Алар сменалап эшли бит, Гайнан ага.

– Бу дөрес түгел, ул көнне эшләргә тиеш кассирыгызны Мәскәүдәге туганыгызга нәрсә төяп озаттыгыз? – Тикшерүче директорның урынсыз аклануына чик куйды. Юантык директор, телен тешләгәндәй, авызын кысты.

– Нишләп акча түләп, бәйрәм мәҗлесенә җыелган халыкны утыз ике минут ишек төбендә алҗыттыгыз?

– Шестеркин булмагач, ни... – дип әйтергә өлгермәде, директорны яңа сорау бүлдерде:

– Аның юклыгын халыкка нәрсә дип аңлаттыгыз?

– Билгеле инде, чирләде дип...

– Ялган! – Ибраһимов, вакыйганы яхшы белгәнлектән, шәһәрдә «шома» дигән даны чыккан директорга боргаланырга урын калдырмады. – Нишләп халык янына чыгып, үзегез дөресен аңлатмадыгыз, гафу үтенмәдегез?

– Кем уйлаган бит аны! Абынасын белсә, кеше юлына салам түшәп куяр иде. – Директор, кулларын як-якка җәеп, башын иде.

– Аңлашыла, димәк, сездә дә кул кулны юа. Җаваптан җиңел котылмакчы буласыз.

– Тикшерүче тартмасыннан ике язылмаган рәсми кәгазь алды. Берсе җинаять эше кузгату карары, икенчесе – җавап алу беркетмәсе иде.

– Бу хакта сезнең белән сөйләшәсе сүз алда әле. Хәзер шушы беркетмәгә гозерегезне, өлкән официант турында бөтен белгәнегезне тукми-чәчми языгыз.

– Ибраһимов директорны каршысына утыртты. Нәрсәдер хәтерләп, телефон трубкасына үрелде.

– Рестораннар трестымы бу? Кем тыңлый? Мин прокуратурадан, Ибраһимов. Кадрлар бүлеге мөдирен дәшәсезме әле. Рәхмәт. Хәерле иртә, Зәйтүнә ханым, Шестеркин Николай Семеновичны беләсезме? Өлкән официант. Кайсы ресторанда? Әйе. Аның шәхси тегелмәсе, фоторәсемнәре, хезмәт кенәгәсе кирәк безгә. Бүген үк! Сәгать уникегә. Рәхмәт. Көтәм.

Тикшерүченең бүгенге гадәти эш көне әнә шулай башланып китте. Вера Шестеркина килгәнче ул кирәк кешеләр белән хәбәрләшеп өлгергән иде инде.

– Көндезге уникеләрдә Коля, эшкә барам дип, ресторанга киткән иде. Шуннан сон мин аны күрмәдем. Кичкә таба ресторанга барсам, вакытлыча каядыр чыгып киткән, озакламый кайтыр, диделәр. Ул әүвәл дә шулай югалгалый торган иде. Ләкин шул көнне дә, икенчесендә дә Коля өйгә дә кайтмады, эшкә дә килмәгән... – диде Вера, офтанып. – Исән генә була күрсен, илаһым.

Тикшерүче өчен бу бик аз иде әле. «Бәлки, ресторан хезмәткәрләре берәр нәрсә беләдер». Гайнан берәм-берәм өлкән официантның эштәге иптәшләрен чакырта башлады. Ниһаять, аларның берсе Шестеркинның таксига утырып киткәнен әйтте.

– Таксиның номеры?

– Кем карап торган ди аларны!

– Кая китте?

– Анысын хода гына белә.

– Ни йомыш белән?

– Шайтан белсен.

– Үзе генәме, кеше беләнме? – Тикшерүчене борчыган мәсьәлә бихисап иде булса кирәк.

– Кеше белән йөрми ул, – диде официант егет, исе китмәгәндәй.

– Нишләп?

– И-и, аптырамагыз ла шуңа! – диде егет, сораудан котылмакчы булып. – Ул элек-электән таксида җилдертергә ярата. Кушаматы да «Стиляга» бит аның.

– Кушамат? – Гайнан көтелмәгән нәрсәгә тап булгандай, сүзне эләктереп алды. – Элек хөкемгә тартылганы бармы?

Официант егет, авызының киңрәк ачылганын абайлап, шундук телен йотты: «Юк», «белмим»нәрдән узмады.

«Бәлки Шестеркинның атасы белә торгандыр?» Ибраһимов секретарь кызга повестка тоттырды.

– Идарәнең машинасына утыр да, хәзер үк илтеп бир. Семен агайга әйт, иртәгә сигезгә килеп җитсен.

– Исәнмесез, Гайнан Ибраһимович! Сез чакырттыгызмы? – Тикшерүче каршына озын буйлы, киң күкрәкле, илле яшьләрдәге ир килеп басты. Күз төпләре көйгән. Маңгаендагы җыерчыклар тирәнәйгән. Гайнан ата кешенең хәсрәтен шәйләп алды. Үз янына утыртты, әңгәмәне уратып, ерактан башлады. Икесе дә «бакчачы» исемен йөртүчеләр дә икән әле. Шулай һава торышы, бакча хәлләре хакында гәпләшеп ун минутлап вакыт уздырды тәки. Тикшерүчене борчыган сораулар җитәрлек булса да, аларны чишкәнче аңлашасы бар иде әле. Адәм баласын эти-әнисеннән дә яхшы белүче бар микән? Әйдә, сорауларыңны чиш, өлкән Шестеркин алдында утыра бит.

– Улыбыз Коляның кыек юлга басарын кем уйлаган, иптәш Ибраһимов, – дип башлады ата. – Аны җинаять эшлә дип үстермәдек бит без. Ашаса да, эчсә дә, кисә дә – ни тели, барысы да бар иде ул үскәндә. Мин – геолог, әнисе – фельдшер. Бернәрсәдән дә мәхрүм булмады, дип авыз тутырып әйтә алам. Бәлки шул муллык бозгандыр да. Мәктәптә укыганда ук «танцы» дип исе китә башлады Колябызның. Озын чәч үстерде, сакал җибәрде. Көтүләре белән кыз-егетләр иярә башлады. Барысы да, кызганычка каршы, алар теле белән әйткәндә, стилягалар иде. Сөйләшә башласаң, уй-хисләренең бик сай икәнен сизәсең. Әдәбиятны, сәнгатьне юньләп белмәсәләр дә (динне әйткән дә юк инде), мода, эротика, тәмәке, секс, исерткеч эчемлекләр турында мәгълүматлары ташып тора иде. Шулай бервакыт, Камчаткадан командировкадан кайткач, Коляны кулга алмакчы булдым. Соң булса да уң булсын дип тотындым «тәрбияләргә». Тотынуым булды, әнисе килеп муенга асылынды. «Үзебез ач, ялангач үстек. Улыбыз рәхәтлектә үссен ичмасам. Бердәнбер бөртек кенә бит ул», – дип, аяк чалды. Ә мин, ачык авыз, аны тыңладым. Үзе дә шифаханәдә ята хәзер. Коляның укуы да «өчле»дән артмады диярлек.

(Дәвамы бар).

2004 елның маенда, ягъни 18 ел элек, Равил Сабырның Әгерже районы Тугызбуй (Девятерня) авылында яшәп ятучы 85 яшьлек ветеран Муллаҗан Галләмов турындагы мәкаләсе чыкты. Бабайга үз гомерендә беренче мәртәбә паспорт тапшырганнар. Ничек төп документсыз гомер кичергән дисезме? XX гасырда совет кешесенең башына төшкән бөтен афәтләр аны да чикләп узмаган: Бөек Ватан сугышы, әсирлеккә төшү, немец концлагере, аннан кайткач совет ГУЛАГы – күрмәгәне калмаган, кыскасы.

Дөнья кичкән ил карты

Мәкалә чыкты, җәмәгатьчелек арасында шактый резонанс тудырды, ләкин Равилне канәгать дип әйтеп булмый иде. «Сөйләштерә алмадым мин ул бабайны, курка, нидәндер шөлли иде», – диде ул. Уйланып йөри торгач, ул бу бабай янына яңадан барырга булды. Хыялында. Повесть яза башлады, монда инде бабай белән журналист иркенләп сөйләшә.

Нәкъ шул вакытта Татарстан Мәдәният министрлыгы Камал театры белән берлектә «Яңа татар пьесасы» бәйгесе игълан итте. Равил үзен драматургиядә сынарга булды. Һәм иң беренче язган пьесасы шундук уңышка ирешә, Сабыр конкурсның лауреаты булды. Тик бабай турында язылган әсәр түгел, башкасы – «Земфирәкәй, сылуым, аппагым!» мелодрамасы җиңде.

Сабыр ярты юлда туктальп кала торган кеше түгел, аннары бабай язмышы да, төгәлрәге XX гасыр тегермәнен үткән миллионнарча корбаннарның язмышы да тынгысызлап торды аны. Ул өлкәнрәк каләмдәшләре, иҗаттәшлары – Туфан Миңнуллин, Вахит Имамов, Факил Сафин, Илдар Хәйруллиннар белән киңәште, сабыр гына әсәрнең эшләнеп бетмәгән урыннары турындагы аларның фикерләрен тыңлап, күңеленә сеңдерә барды, кайсын кабул итте, кайсын юк. Шул рәвешле ул пьесасын ике ел дәвамында камилләштереп, «Абага алмасы ачы була» дигән яңа исем куеп, яңадан конкурска җибәрде.

2008 елның 27 мартында конкурс нәтиҗәләрен Камал театры сәхнәсеннән игълан иттеләр. Жюри рәисе – күренекле әдәбият белгече, тарихчы-галим, академик Миркасыйм Госманов башта бәйгегә килгән әсәрләрнең сыйфаты күтәрелүе турында әйтте.

«Быелгы конкурсның тагын бер үзенчәлеге булды, – дип дәвам итте ул. – Башта минем бик нык ачуым чыккан иде, тик соңрак моңа сөендем генә. Бер авторыбыз өч ел элек конкурста катнашкан пьесасын яңадан җибәргән. Бәйге нигезләмәсе буенча болай эшләргә ярамый. Тик без пьесаның беренче вариантын да, яңадан язылганын да укып шундый нәтиҗәгә килдек: автор сыйфат ягыннан берничә баскычка өстен торган яңа әсәр язган. Драматургларның шулай кайта-кайта, тәзәтә-төзәтә әсәрләрен камилләштерүләре безне бик шатландыра, татар театр сәнгатенең киләчәге якты булачагына өмет уята. Шулай да без бу әсәрне җиңүче дип таный алмыйбыз, чөнки формаль яктан конкурс шартлары бозылган. Әмма җәмәгатьчелек якын арада бу һичшиксез көчле әсәр белән таныша алсын өчен без аны «Казан утлары» журналының чираттагы санында бастырырга карар кылдык», – диде Миркасыйм ага... һәм сәхнәдән төшеп китте. Кайсы авторның нинди әсәре турында сүз барганы аңлашылмый калды.

Сәхнәгә Равил Сабыр да чыкты, «Теләк» пьесасы белән икенче урынны яулаган иде ул. Аны бүләкләгәч, кичәне алып баручы Татарстанның халык артисты Илдар Хәйруллин: «Миркасыйм ага сөйләгән драматург менә шушы инде, – дип серне чиште. – Ул пьесаны тыныч кына укып булмый, күзләргә яшь тула. Режиссерлар бу пьесага ташланды инде, спектаклен дә һичшиксез якын арада сәхнәдә күрәчәкбез!»

Тик мәртәбәле жюри әгъзалары – режиссерлар, язучылар, әдәбият галимнәре, театр сәнгате белгечләре – «Абага алмасы ачы була» драмасының югары кимәлдәге, сыйфатлы, көчле әсәр икәнен таныса да, премьераны тагын ике елдан артык көтәргә туры килде...

Хикмәте шунда, Чаллы драма театрының ул чактагы баш режиссеры Фаил Ибраһимов тәкъдиме белән пьеса театрның худсоветы утырышында укылды, хуплау алды, киләсе сезонда куелачак пьесалар исемлегенә кертелде һәм шунда... гөнаһ шомлыгы (!) дөньяда финанс кризисы башланды. Театрларның яңа спектакльләр чыгарырга дигән болай да санаулы тиеннәрен инфляция йотты.

Ләкин бер яманның бер яхшысы, дигәндәй, театрның шундый четерекле хәлдә калганын белгәч, Чаллы шәһәре җитәкчелеге, атап әйткәндә, Васил Шәйхразиев, театрга ярдәмгә килеп, «Абага алмасы ачы була» драмасын сәхнәләштерергә акча бүлеп бирде. 2010 елның 23 октябрендә спектакльнең премьерасы булды!

Драманы карарга дип, Казаннан Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетының ул чактагы рәисе Р.Вәлиев һәм халык язучысы Т. Миңнуллин килгән иде. Театр залында шулай ук Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлегенең ул вакыттагы сәркатибе В.Имамов, башка язучылар, «Чаллы икмәге»нең генерал директоры Р.Юнысов, Яр Чаллы педагогика институтының ул чактагы ректоры Ф.Мостафина һ. б. бик күп дәрәҗәле, исемнәре билгеле, ихтирамга лаек кешеләр бар иде. Премьерага игътибар бик зур булды, аны җәмәгатьчелек, чыннан да, көтеп алды. Спектакль тәмамлангач, тамашачылар әле озак залдан чыга алмыйча, кичәселәре килмичә торды.

Ә аннары драма авторлары тагын бер көтелмәгән адым ясады: яңа гына чыккан спектакльне телевидениедән күрсәттеләр. Гадәттә театрлар үз спектакльләрен тамашачы игътибары кими башлагач, репертуардан төшереп калдырыр алдыннан, архивта язмасы саклансын дип видеотасмага төшерәләр, яңа спектакльне телевизордан күрсәтсәң, халык йөрмәс, диләр. Ә Фаил Ибраһимов бөтенләй башкача фикер йөртте. «Театрга халык барыбер йөриячәк. Безгә бу спектакльне бүгенге көндә әле исән булган ветераннарга күрсәтеп өлгерергә, гафу үтенергә өлгерергә», – диде ул. Хаклы булып чыкты – премьера узганга 12 ел үтте инде, ә халык һаман бу драманы карарга Чаллы театрына йөри. Хикмәт нидә, дисезме?

Фаил Ибраһимовтан да төгәлрәк итеп әйтеп булмастыр: «Дөреслектә аның бөтен көче һәм тылсымы! Һәрбер кешенең бабасы сугышта булган, ләкин һәрберсе Рейхстаг өстенә кызыл әләм кадамаган бит, әсирлеккә төшүчеләре дә, бик күп михнәтләр аркылы үтеп көчкә-көчкә, могҗиза белән генә исән калучылар да бихисап. Театрга килгән һәр тамашачы, сәхнәдә Насыйбулланы күргәч, үз бабасының йөрәк тибешен тойгандай була, күңеленнән аның газап тулы тормыш юлын исенә төшереп утыра».

Бу урында, һичшиксез, Насыйбулла образын тудырган артист Рафил Сәгъдуллинның осталыгы турында ассызыклап әйтми ярамый. Аның турында шагыйрә Лилия Гыйбадуллина әнә ни дип язган: «Насыйбулла – типик персонаж, аксакал, җор телле, хәйләкәр, дөнья кичкән ил карты. Спектакльне тамаша кылганда, ирексездән, Әлмәндәр искә төшә. Мөгаен, Шәүкәт Биктимеровтан соң шундый ук үз-газиз татар картын Рафил Сәгъдуллин гына сәхнәгә чыгара алгандыр».

Таланты зурлыгындагы үзенә тиешле бәясен алып бетермәгән артист дип тә өстәсәк, тагын да дөресрәк, гаделрәк булыр. Яратып бетермиләр шул бездә фикерле, газета-журналлар, китаплар укый торган, дәрәҗәләргә карап тормыйча үз фикерен биткә бәреп әйтә торган артистларны...

Үзенә тиешле бәясе димәктән, 2021 елның мартында Чаллыда шәһәрнең татар драма театрына нигез салган Ф. Ибраһимовның 70 яшьлек юбилеена багышланган кичә узды. Режиссерга «бүләккә» шәһәр җитәкчелеге исеменнән Рәхмәт хаты тапшырылды. Казаннан юбилярны котларга килгән язучыларга бу гамәл, йомшак кына итеп әйткәндә, бер дә ошамады. Башта Рабит Батулла ризасызлыгын белдереп чыгыш ясады, аннары Вахит Имамов. Үзе дә күп еллар буена Чаллыда эшләп киткән тарихи романнар авторы соңрак мәкалә дә язып бастырды.

«Фаил Ибраһимовның яшәү миссиясендә иң мөһиме — 1990 елда ул Чаллы каласында өр-яңа драма театры оештыра алды һәм 30 ел буена төбәк тамашачыларын яңадан-яңа иҗат әсәрләре белән сөендерде. Бу гомер эчендә ким дигәндә 150гә якын спектакль куелды. Фаил әфәндenең түземлегенә һәм ўҗәтлегенә сокланмыйча булмый. 30 елдан артык Чаллы театрын барыбер яшәтте, барыбер дөрләтте бит. Артистлары байрак күтәреп йөрмәсә дә, театр каладагы милли рух һәм милли көрәшнең бер үзәге булды», – дип яза В.Имамов.

Аңлашыладыр шәт, бүген Ф.Ибраһимов иҗаттәшлары белән бергә Тукай премиясенә кандидат итеп күрсәтелгән икән, менә шушы 30 еллык иҗат юлын да күз алдында тотарга кирәк, әлбәттә.

...Иҗатны бизмәнгә салып үлчәп буламы? Юктыр. Тик шунысы да бар, кара исәп белән генә санаганда да Фаил Ибраһимов куйган спектакльләрне бер миллионнан артык тамашачы караган. Шулкадәр халыкны Казан-Чаллы юлына тезеп бастырсаң, кешеләр арасындагы ара нибары 24 см тәшкил итәр иде. Әле бу спектакльләрне телевизордан күрсәтүләрне исәпләмәгәндә. Һәм әгәр шул бер миллион кеше Чаллы спектакльләре, шул исәптән «Абага алмасы ачы була» драмасы тәэсирендә чүт кенә фикерләгән, юк, үзләре түгел, уйлары гына булса да бераз яхшы якка үзгәргән икән, димәк...

Илисә ГАНИЕВА.

Фотолар Чаллы татар драма театры архивыннан алынды.

МӘХМҮТ ВАҺАПОВ:
«Рәссамнарга киңрәк мәйдан кирәк!»

1995 елдан – Казан сынлы сәнгать училищесын һәм 2007 елдан Мәскәүнең В.И.Суриков исемендәге дәүләт академик сынлы сәнгать институтының Казандагы филиалын җитәкләгән директор, яшь кадрлар әзерләүгә күп көч куйган рәссам-педагог Мәхмүт Ваһаповка Казан сынлы сәнгать мәктәбе бинасын рәссамлыкка укучылар өчен кире кайтару эшенең үзәгендә кайнарга туры килгән.

Сүзне Мәхмүт Әхәт улының ни өчен Казан музыка училищесында, Казан дәүләт консерваториясендә белем алуны сайламыйча, Казан сынлы сәнгать училищесына керүен белешүдән башладык. «Дәрестән дә, җырлау сәләтем бар, – ди ул. – Гомерем буе җырлыйм. Татар җырларын да, рус романсларын да... Әмма рәсем ясауга сәләтем балачакта ук җиңде.

Әти-әнием гади хезмәт кешеләре иде. Әтием Әхәт Ваһапов – Яшел Үзән районының Күлбаш авылында туган, 1911 елгы, ә әнием Рәхимә Апас районының Турай авылыннан, 1918 елгы иде. Алар инде Бөек Ватан сугышына кадәр үк гаиләле булган, әмма сугыш афәте аркасында беренче гаиләләрен югалтканнар. Әтием сугыш хакында бик сирәк сөйләде, сугыш елларында ул поездлардагы йөкләрне саклауда катнашкан, бомбага тотуларга тарыган, үлем гел янәшәсендә йөргән... Сугыштан соң эти Киров районындагы күн эшкәртү заводында эшләгән. Ул, гомумән, үги әнисе тәрбиясендә үскән, һәм инде 12 яшеннән үк үз көнен үзе күрә башлаган, читкә китеп эшләгән. Ә әниемнең беренче гаиләсендә Илдар исемле улы туган, тик аның ире генә сугышның беренче көннәрендә үк һәлак булган. Әнием дә сугыштан соң Киров районының җитен туку комбинатында хезмәт куйган. Алар гаилә коргач, 1955 елда без, игезәкләр, мин һәм Әхмәт туганбыз. Балачагыбыз Казанның шул Киров районында узды».

Мәхмүт Ваһапов башлангыч сыйныфларда укыган чакта ук рәсемнәрне яхшы ясаган һәм аның шушы сәләтен күреп алган укытучысы әти-әнисенә Мәхмүтне сәнгать мәктәбенә бирергә киңәш иткән. «Сәләтем әниемнән күчкәндер дип уйлыйм. Хәтеремдә, ул миңа ат сурәтен ясарга булышкан иде. Әти-әни өйдә татарча гына сөйләште, шуңа без дә әлегәчә туган телдә яхшы сөйләшәбез. Без укыган елларда урта мәктәпләрдә татар теле һич укытылмады бит», – дип искә ала әңгәмәдәшем балачагын. Ул Казанның 2 нче балалар сәнгать мәктәбен тәмамлаган, урта мәктәптә дә яхшы укыган, һәм 1970 елда Казан сәнгать училищесына укырга кергән. 1974 елда аны тәмамлап, Казанның 113 нче рус-татар урта мәктәбендә бер ел рәсем һәм сызым дәресләрен укыткан. «Балалар рәсем дәресләрен шулкадәр ошата, көтеп ала иде», – ди ул. Аннан соң иҗатчы 1975-1977 елларда Совет Армиясе хезмәтен Германиядә үткән. Армиядән соң, 1977 елда башкаланың 3 нче балалар сәнгать мәктәбендә белем бирә башлаган. 1979-1985 елларда В.И.Суриков исемендәге дәүләт академик сәнгать институтында, профессор Д.К.Мочальский остаханәсендә укыган.1985 елны Казан сынлы сәнгать училищесында сынлы сәнгать, рәсем, композиция дәресләрен укыта башлаган. 1995 елда шушы училищеның директоры итеп билгеләнгән, бер үк вакытта укытучы булып эшләвен дәвам иткән. «Тулаем санаганда, барлыгы йөздән артык студентка белем биргәнмендер. Укучыларымның бик күбесе белән горурлана алам. Студентларыбыз тырышып укудан тыш, төрле илкүләм конкурсларда да призлы урыннар еш яулады. Ә училищены тәмамлаганнарның бик күбесе Мәскәү, Санкт-Петербург һ.б. югары уку йортларында укулары белән куандырдылар», – дип дәвам итә ул әңгәмәбезне.

Мәхмүт Әхәт улыннан 1901-1905 елларда рәссамнар өчен махсус төзелгән Казан сәнгать мәктәбе бинасын Казан сәнгать училищесы базасына кайтара алу вакыйгасы хакында сорамыйча калу һич тә мөмкин түгел. «Узган гасыр башында төзелгән матур бинадан рәссамнарны 1926 елда ук башка бинага чыгарганнар. Аннары әлеге мәһабәт бинаны индустрия техникумы, политехника институты, коммуналь төзелеш инженерлары институты һәм 1941-2005 елларда КАИ биләгән. Әлеге тарихи бинабызны кире кайтаруны теләп, берничә буын рәссамнар һәм укытучылар хыялланып яшәде. Ниһаять, Казан сәнгать училищесы коллективы белән берлектә, элеккеге бинабызны кайтарып алу бәхетенә ирештек, – ди ул. – Билгеле, мондый мөһим вакыйга Татарстан Республикасы хөкүмәт җитәкчеләре булышлыгы белән барды. 2005 елның 5 августында Казан илкүләм тикшеренү техник университеты ректоры белән имзалар куешып, мин, директор буларак, ул бинаны кабул итеп алдым. Элеккеге Казан сынлы сәнгать мәктәбе бинасы бары тик бу бинада югары уку йортын ачу максаты белән кайтарып бирелде. В.Суриков исемендәге сәнгать институтын тәмамлаганга күрә, мин бу институтта эшләүче профессорларны да, Россия Сынлы сәнгать академиясе академикларын да яхшы белә идем, шуңа күрә әлеге институт филиалын үзебездә ачу максаты белән Мәскәүгә, килешүләр төзергә юнәлдем. Бу рәссамнар өчен зур вакыйганы уңай якка чишүдә Зиля Вәлиева да зур өлеш кертте. Ул да, башка мөһим эшләрен читкә куеп, Мәскәүдәге күп очрашуларда, килешүләрдә катнашты. Ниһаять, 2000 еллар башында элеккеге Казан сәнгать мәктәбе бинасының беренче каттагы бер аудиториясенә кереп, укыта башладык. Чөнки моңа кадәр училищеда эшләп килүче ике бүлеккә тагын бер өр-яңа бүлек – керамика бүлеген өстәдек. Бу Татарстанда декоратив-гамәли сәнгать традицияләрен яңадан торгызу, саклау, үстерүгә юнәлгән дәүләт программасы кабул ителү һәм аны тормышка ашыру белән бәйле иде. Шулай итеп, керамика остасы булырга теләүче яшьләребез укый башлады. Һәр яңа уку елында берәр өр-яңа бүлек ача бардык. Училищеда тагын скульптура бүлеге, металлны сәнгати эшкәртү бүлеге, декоратив-гамәли сәнгать төреннән, күнне сәнгати эшкәртү бүлеге оештырылды. Аннары костюм дизайны бүлеген дә ачтык. Бүлек җитәкчеләренә, дәрәҗәле, тәҗрибәле осталарыбызга: «Сез үзегезгә алмашлар, булышчылар әзерлисез», – дидек. Шулай килеп чыкты да. Бу бүлекләрдә яшьләр гыйлем җыйды, аларның күбесе әлегәчә үз һөнәрләрендә. 2009-2014 елларда Яшел Үзән балалар сәнгать мәктәбендә училищебыз филиалы эшләде. Әлеге филиалны ачу декоратив-гамәли сәнгатебезне тернәкләндереп җибәрү белән бәйле булды. Тик шундый вакыт килеп җитте, дәүләт акчасы кимеде һәм училище керамика, металлны сәнгати эшкәртү бүлекләрен ябарга мәҗбүр булды. Планнар шул капиталь ремонтка барып тоташты. Ә ул капиталь ремонт дигәннәре әкренләп булса да ясала барды, хәзер дә дәвам итә...

2008 елда Татарстан Хөкүмәте, Мәдәният министрлыгы, Россия Сынлы сәнгать академиясе һәм В.Суриков исемендәге дәүләт академик сынлы

●Ананас белән натюрморт.

●Кабак белән натюрморт.

●Яз.

●Чистайда көн уртасы.

сәнгать институты арасындагы үзара килешү төзелде. Әлеге мәшһүр институтның Казандагы филиалы директоры итеп билгеләндем. Шунысын да әйтергә кирәк, бу филиал институтның илебездәге бердәнбер филиалы буларак ачылды! Минем эшем шушы дәрәҗәле югары уку йорты белән бәйле булды. Бар студентларыбыз әлеге мәртәбәле институт дипломнарын алды. Филиалыбызда скульптура, сынлы сәнгать һәм графика бүлекләре ачып укыттык. Мәскәүдән ярты елга бер, ә кайчак аннан да ешрак килеп, тәҗрибәле иҗатчылар, Россиянең халык рәссамнары, академиклар белем бирде. Казанның бик зур тәҗрибә туплаган остазлары да хезмәт куйды. Әмма Россия дәүләте тарафыннан матди булышлык киселү сәбәпле, 2017 елда әлеге филиалыбыз ябылды».

– Татарстанга андый югары сынлы сәнгать уку йорты кирәкме соң?

– Һичшиксез! Без, татарлар, Россиядә халык саны буенча иң зур милләтләрнең берсе. Талантлы халыкның үз сынлы сәнгать институты да булырга тиеш. Чөнки безнең Н.Фешин, П.Беньков, Х.Якупов һәм башка остазлардан башланган укыту традицияләребез бар. Әлеге мәктәп Россиядә иҗатчылар әзерләүдә һәрвакыт әйдәп бару позицияләрендә булган. Бәлкем, бу идеяне тормышка ашыручы да табылыр әле.

Әйе, менә минем үз хыялларымны, ниятләремне җиренә җиткерерлек елларым булды. Әнием миңа гел әйтә иде: «Улым, синең хыялларың бигрәк күп. Алар тормышка ашармы икән инде?» Ә алар, ни куаныч, чынга ашты! Дөресен әйткәндә, бар уңышларымның нигезен әниемнең миңа карата булган ышанычы тәшкил итә.

– «Якындагы ерактан күренә» дигән әйтемне искә алсак, сезнең өчен бары да артта калды. Соңгы биш елда укытмыйсыз. Көннәрегез төрле очрашулар һәм иҗат эше белән үтә. Тормышыгызның кайсы вакытын аеруча сагынып искә аласыз һәм Казанда тагын нинди сәнгать бинасы булуын теләр идегез?

– Мин игезәгем Әхмәт белән җәй айларын күбесенчә Апас районының Зур Күккүз авылында ял итеп, шунда хезмәт куеп үстем. Апасның үзендә яшәүче туганнарыбызда да кунак була идек һәм әтиебезнең туган ягына, Күлбаш авылына да кайта идек. Туганнарыбыз безне һәрчак үз итте! Туган телебездә сөйләшүебезне шунда да шомарттык. Мин шул бәхетле чакларны сагынам. Әбиләремнең сурәтләрен дә ясап кала алдым. Аннары авыл өйләре интерьерларын, авыл тормышы күренешләрен... Хәзер дә шул эшләрем күңелемә хозурлык өсти. Институтны тәмамлаганда, «Аналар язмышлары» дип исемләнгән диплом эшемне язганда, шунда туган бихисап эскизларыма таяндым.

Тагын... Казан сәнгать училищесын алга этәрү буенча кылган гамәлләремне беләм, 2006 ел ахырында училищебызга Н.И.Фешин исемен бирү турындагы дәүләт карарын күреп тә шатландым. Борынгы, тарихи бинабызда Казан сынлы сәнгать мәктәбе тарихы музеен ачтык. Казан сынлы сәнгать мәктәбе – Император Сынлы сәнгать академиясе ризалыгы белән һәм аның җитәкчелегендә 1895 елда ачылган урта махсус һөнәри уку йорты. Методика фонды янәшәсендәге мәйданда, узган гасырдагыча итеп, якты күргәзмә залын булдырдык һәм анда төрледән-төрле күргәзмәләр оештырылды.

Җырда җырланганча, дөнья – матур, дөнья киң бит ул. Бу елларда дусларым белән дә, элеккеге студентларым белән дә күбрәк телефон аша элемтәдә торам. Алар уңышлары белән уртаклаша, шәхси күргәзмәләре ачылу тантаналарына чакыралар... Училищеда, институт филиалында бергәләп эшләгән хезмәттәшләремнең күбесе белән әлегәчә аралашам, үзем укыган сәнгать мәктәбендә укыткан укытучыларымның да хәл-әхвәлләрен белешәм. Хәзерге интернет мөмкинлекләреннән файдаланып, сәнгать хакында, төрле рәссамнар турында төшерелгән тапшыруларны, кинофильмнарны карыйм, белемемне арттырырга тырышам.

Ә менә Казанга нинди бина җитми дисәк... Билгеле, Казан – бик дәрәҗәле шәһәр. Бездә «Эрмитаж-Казан» үзәге, «Манеж» күргәзмә залы да ачылды. Рус дәүләт музее белән дә багланышларыбыз бар. «Хәзинә» милли галереясы да сокландыргыч! Мондый зур галереялар башка калаларда бик юк та әле ул. Әмма мине дә, башка рәссамнарны да Заманча сынлы сәнгать галереясында уздырырга мөмкин булган күмәк күргәзмәләр булмау бик борчый. Татарстан рәссамнарының үз тамашачылары белән очрашу мәлләре юк диярлек, баштагы елларда мондый күмәк күргәзмәләргә әзерләнү, катнашу өчен стимул бар иде. Хәзер әлеге галереяда мондый күргәзмәләр үтми. Югыйсә «Россия Рәссамнар берлеге» иҗади җәмгать оешмасының Татарстан бүлегенә генә дә йөз җитмештән артык рәссам теркәлгән. Әгәр дә мондый отчет күргәзмәләре елга нибары ике тапкыр гына ачылса да, бик яхшы булыр иде. Баштарак элеккеге СССР республикалары рәссамнары иҗат иткән картиналарны Мәскәүгә барып карый идек. Хәзер анда да зур күргәзмәләр сирәк оештырыла... Уйлап карасак, бездә Ф.И.Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале 1982 елдан бирле һәр ел саен уза, Р.Нуриев исемендәге классик балет фестивале 1987 елдан бирле гөрли. Тик рәссамнар гына һәрвакыт читтә кала. Алар иҗаты өчен зур мәйданнар юк. Рәссамнарның, дизайнерларның да Татарстан халкына күрсәтерлек зур әсәрләр язасылары килә ләбаса. Алар бит романнарын өстәл астында тотып тора алырлык сабыр язучылар түгел. Тамашачы бәяләмәләренә бик сусаган, хиссиятле халык бит без! Үз вакытында миңа сәнгать фестивальләрендә, форумнарда катнашырга туры килде. Европаның барлык тарихи-мәдәни башкалаларында да һәрчак зур сәнгати форумнар үтә һәм шушы форумнарда сәләтле рәссамнар үзләренең соңгы вакытларда иҗат иткән яңа әсәрләрен күрсәтә. Әйтик, Парижда булганда миңа Франциядәге сәнгать эшлеклеләре тарафыннан 1903 елдан бирле оештырылып килгән Көзге салон – Salon d'automne күргәзмәсен күрергә туры килде. Бу дәүләттә Хөрләр салоны яз көне үтә һәм анда рәссамнарның кыш буе язган әсәрләре экспозицияләнә. Ә Көзге салонда рәссамнарның җәй көне язган әсәрләре куела. Моннан тыш Франциядә Париж биенналесе дә үтә. Мондый күләмле күргәзмәләрнең Grand Palais (Зур сарайда) узулары да гадәти күренеш! Мин Төркиядә, Грециядә, Кипр Республикасында, Испаниядә, Германиядә, Польшада да булдым. Кайбер кечкенә дәүләтләрдә дә рәссамнар өчен иркен мәйданнар булдырылган... Ә без кайчандыр үзебезнең Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге карамагында булган күргәзмә залыбызда күмәк күргәзмәләр ачудан да мәхрүм. Мин Казанда Татарстан рәссамнарының үз халкы игътибарына тәкъдим итәрлек күмәк күргәзмәләрен ачарлык тагын бер өр-яңа сынлы сәнгать галереясы бинасы булырга тиеш дип саныйм!..

●Авыл ызбасы.

●Мич арты. Пешкән кабартма.

Мәхмүт Әхәт улы – тыйнак һәм кыю, оптимист һәм үтә ихлас шәхес. Үзе хакында түгел, башка рәссамнар турында бик теләп сөйләргә әзер. Әмма мин аннан үз иҗаты хакында сорашам. «Иҗатымда һәрчак пейзажлар, натюрмортлар, портретлар өстенлек итте. Киндерләрдә якын туганнарымны һәм дусларымны гына сурәтләдем. Үз вакытында пленэрларга да еш йөрдем, Татарстан табигатен теләп сурәтләдем. Ә бүген исә күбесенчә натюрмортлар иҗат итәм һәм бу сәнгать жанрын иң демократик жанрга саныйм», – ди рәссам.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәхмүт Ваһаповның картиналары республикабыз музейларында һәм Төркия, Польша, Бельгия, Кипр, Германия, Испания, АКШ, Көньяк Кореядагы тупланмаларда да саклана.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

МАРИ ИЛЕНДӘГЕ

(Дәвамы. Башы 12 нче санда).

Аның данлыклы шәҗәрәсе хакында «Мәрҗани» китабында Шәһәр Шәрәф болай дип яза: «Татарлар арасыннан башлап дини вә милли бөек хезмәтләр иҗат иткән Мәрҗани хәзрәтләренең нәсәбе: Шиһабетдин бине Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим бине Габдеттәүваб бине Габделгани бине Габделкоддус бине Йәдәш бине Ядкәр бине Гомәр.

Бабаларыннан Габделкоддус Мәрҗан авылының урынына беренче мәртәбә килеп утырып, шул авылны нигезләгәнлектән, нисбәтләрендә «Мәрҗани» дип мәшһүр булганнар. Мәрҗан Казаннан 50 чакрым ераклыкта. Мәрҗанинең анасы Хөбәйбә бинте Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза бине Гали бине Йосыф әс-Сембери әл-Чокалый.

Мәрҗани хәзрәтләренең ата вә ана тарафлары заманасының бөек галимнәреннән булып, нәселләреннән бик күп имамнар вә галимнәр чыкканлыктан, Мәрҗанидә булган яхшы сыйфатлар һәм камиллекләрнең бер өлеше бабаларыннан мирас буларак калган. Мәрҗани үз нәселләреннән булган имамнарны санаганда егермедән артык авыл саный». *(Ш.Мәрҗани / төз. Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Әлмәт: Рухият, 1998. – Б.27.)*

ӘТНӘ РАЙОНЫНДАГЫ КОМЫРГУҖА

Комыргуҗа – язма чыганакларда Казан ханлыгы дәвереннән күрсәтелеп килүче борынгы авыл. Аның оешуы, археологик истәлекләргә караганда, гомумболгар чорына барып тоташа.

Комыргуҗада Ш.Мәрҗанинең Габделкотдуска чаклы ерак бабалары яши. Габделкотдус исә моннан күчеп китеп Мәрҗан авылына нигез сала.

XVIII гасырның беренче яртысында Россиядә ислам дине шактый эзәрлекләүләргә һәм кысуга дучар була. 1740 елда махсус оештырылган «Чукындыру буенча контора» эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1742-1744 елларда, мәсәлән, Казан өязендә 536 мәчетнең 418 е юк ителә. Шул исәптән Алат юлында мондый язмышка 91 мәчет дучар була. Алар арасында Абдул Ишбаев сотнясы йөзлегенә кергән Комыргуҗа, Ябынчы һәм Төрекләр авылы мәчетләре дә бар. Комыргуҗа ул вакытта 40 хуҗалыктан торган. XVII-XVIII гасыр чыганакларына караганда, мондагы халык ике социаль төркемгә – ясаклы һәм йомышлы татарларга бүленгән. Алар 1782 елны шул тәртиптә 91 һәм 87 ир-аттан торган. Комыргуҗада Семен морза Мостай улы кенәз Яушевның крепостной хезмәтчеләре яшәве мәгълүм. 1748 ел мәгълүматларына караганда, монда 18 кол бил бөккән. Өченче ревизия чорында (1762 ел) Комыргуҗадан биш гаилә Казан губернасы Чар өязенә марилар яшәгән авыл янына барып төпләнә. Торак пункт башта Свободные ключи дип йөртелә, соңрак марилар яшәгән өлешен Мари-Чодраял, татарлар яшәгәнен Тат-Чодраял дип йөртәләр. Соңгысына тарихи исем беркеп калып, Яңа Комыгырҗа дип тә йөртәләр.

1859 елда 109 хуҗалыкта 387 ир-ат һәм 391 хатын-кыз яши. Гасыр ахырына (1897 ел) халык саны 1062 кешегә җитә.

1906 елда авылда өч лавка була. Шикәр, ярма, тоз һәм башка вак-төяк бакалея тауарлары белән Шаһиәхмәт Хәйбуллин, Әхмәдулла Гыйззәтуллин һәм Маһитап Төхвәтуллиналар сәүдә итә. Беренче икесенең еллык сәүдә әйләнеше – 400, соңгысыныкы 200 сум тәшкил итә. Дүрт хуҗалык чыпта сату белән шөгыльләнә. Әхмәдулла Гыйззәтуллин елга биш меңгә кадәр чыпта саткан, сәүдә әйләнеше биш йөз сумга кадәр җитә. Аның белән 12 кеше эшли. Калган өч чыптачының (Сәфәргали Хәмидуллин, Бәйрәмгали Хәмидуллин, Әхмәтгали Шәмсетдинов) керемнәре күпкә азрак була. Алар елга ике меңешәр данә чыпта җитештереп, ике йөзешәр сум табыш алганнар.

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Комыргуҗа Әтнә волостенда уртача зурлыктагы авыллардан санала. 1914 ел башында анда 625 ир-ат һәм 588 хатын-кыз исәпләнә. *(Әтнә р-ны Комыргуҗа авылындагы Ш.Мәрҗани музее мәгълүматлары.)*

Шул рәвешле, Казан губернасы Әтнә волосте Комыргуҗа авылын Ш.Мәрҗанинең сигезенче буын бабасы Гомәрхуҗа нигезләгән. Шушы авылдан китеп, Чар өязендә Яңа Комыгырҗа авылын нигезләүдә катнашкан Мәнди нәселенең дә нәкъ менә әлеге данлыклы нәселдән булуы ихтимал.

● Имам-хатыйб һәм мөдәррис Габделгазиз Габделгалләмов. 1906 ел.

● Яңа Комыгырҗа авылы мәчете.

ТАТ-ЧОДРАЯЛ АВЫЛЫНДАГЫ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘР

Яңа Комыгырҗа авылы оешу бер гасырдан артык дәвам итә. Килүчеләргә ихата һәм чәчүлек җирләр өчен урын арчырга, йортлар төзергә кирәк була. (МЭР ДА. 301 ф., 1 тасв., 34 сакл. бер., 1-6 кгз.) Аларның кулында балтадан башка кораллары, әйтик, хәтта аркылы пычкылары да булмый. Моның шулай икәнлеген ачык күрсәтеп торган бер-ике каралты-кура 1941 елгы янгынга кадәр саклана әле. Ул каралтыларның почмаклары балта белән генә тигезләнгән иде, дип сөйли авыл картлары. Җирне агач сука белән эшкәртәләр. Сәнәк, тырма ише корал-яраклар да агачтан була. Авыл халкы аучылык, балыкчылык, урман төпләү белән шөгыльләнә. 1834 елда Чодраял авылында 15 хуҗалыкта барлыгы 96 кеше яши. Шуларның – 48 е ир-атлар, 48 е хатын-кызлар. *(ТР ДА. 3 ф., 2 тасв., 137 сакл.бер., 213-218 кгз.)* 1858 елда хуҗалыклар саны 18 гә җитә. Җәмгысе 170 татар яши. Шуларның 89 ы – ир-атлар, 81 е – хатын-кызлар. *(ТР ДА. 3 ф., 2 тасв., 567 сакл. бер., 623-635 кгз..)* 1897 елдагы халык саны алу мәгълүматларыннан күренгәнчә, авылда барлыгы 423 татар һәм мари яши. Губерна үзәгенә кадәр ара 70, өяз үзәгенә кадәр 124 чакрым тәшкил итә. *(Список селений Казанской губернии / Сост. чл. Казан. губ. зем. управы К.П.Берстель. – Казань Казан. губ. зем. управа, 1908. – С. 161.)*

ДИНЛЕ МИЛЛӘТ

Яңа Комыгырҗа авылында тәүге иман йорты кайчан төзелүе төгәл мәгълүм түгел. Әмма архив документларыннан бу сорауга чагыштырмача тулы җавап табарга мөмкин. Авылда 1881 елда җәмигъ мәчет төзү буенча авыл халкы мөрәҗәгатен тикшерү уңаеннан тупланган документлар төпләнмәсендә авылдагы иман йортының шактый борынгы икәнлеге бәян ителә: «Кем и когда именно разрешен в деревне Чедроял молитвенный дом – этого никто в деревне не знает, а все утверждают, что он существует с издавна; указного муллы при этом молитвенном доме никогда не было, а Богослужение в нем отправляется и отправлялось прежде грамотными лицами и знающими магометанские [законы] обряды, требо же исправление совершается указным муллой деревни При-ключе-Сап». *(ТР ДА. 2 ф., 2 тасв., 1951 сакл. бер., 7 кгз.)*

Документтан күренгәнчә, авылда дин эшләрен укымышлы затлар алып бара. Тарихыбызга күз салып, протестчы укымышлылар, ягъни абзагайлар (абзый-агайлар) хәрәкәтен искә төшереп узыйк әле. Бу хәрәкәт вәкилләре Диния нәзарәтенә буйсынган, ягъни патша хезмәтендә үткән муллаларга каршы була. Билгеле ки, татар крестияннары дәүләт крестияны санала һәм хөкүмәт тарафыннан эксплуатацияләнә. Шуңа күрә аларның нәфрәте феодаль дәүләткә, аның башлыгы – патшага каршы юнәлтелә. Муллаларның патшага хезмәт итүе сыйнфый дошманны яклау, куәтләү буларак кабул ителә. Укымышлыларның (абзагайларның) бу килешүгә каршы чыгуларында милли азатлык идеяләре белән бергә халыкның иҗтимагый тормышка карашы да чагылыш таба. Дөрес, әүвәлге заманнарда муллаларга хезмәт хакы түләнми, алар авыл халкыннан кергән сәдака хисабына мәчет-мәдрәсә тота, гадәти крестияннар кебек үк гомер итә. Чит өязләрдән килгән дин әһелләренә авылда җир бирелми. Әмма авылда указлы мулла булмавына болар гына сәбәпче булмагандыр, ә абзагайлар хәрәкәте дә йогынты ясагандыр.

Авыл җәмәгатьчелеге, мәчет төзергә рөхсәт бирүне сорап, кабат 1883 елда мөрәҗәгать яза. Шул вакытта хөкүмәт вәкилләре тарафыннан тупланган белешмәдә болай дип язылган: «Крестьяне деревни Чедроял состоят в приходе деревни Приключи-Сап более 50 лет; сообщение между этими деревнями крайне неудобное, особенно в весеннее время, когда... эти деревни два оврага наполняются водой, препятствующей в прохождении, по крайней мере,... двух являтся к богослужению и отправлению необходимых треб». Димәк, мәхәлләнең Ключи Сап авылы мәчете карамагына кертелүе якынча 1833 елларга туры килә. Авыл халкы мөрәҗәгатьтә мәчетне элекке иман йорты урнашкан мәйданда төзергә ниятләүләрен белдерә. 1883 елның 19 июлендә мәчет төзергә дәүләт тарафыннан рөхсәт бирелүе хакында билгеле була. Бу хактагы документ 13 августта халыкка укыла. *(ТР ДА. 2 ф., 2 тасв., 2606 сакл. бер., 18 кгз.)*

(Шуны да ассызыклап узыйк: 1881 елгы мөрәҗәгатьтә авылдан 8 чакрым ераклыкта урнашкан борадәр Желтухиннарның шанлы пыяла фабрикасында хезмәт куйган 106 ир-атның да авылда мәчет төзелүен хуплавы һәм шул мәхәлләгә керергә теләк белдерүе искәртелә. Фабрика хуҗалары мәчет төзетү мәсьәләсендә нинди дә булса ярдәм күрсәтү хакында уйлап та

ТАТАР АВЫЛЫ

карамый. Заманында әлеге «череп баеган» алпавытлар нәселенең күренекле вәкиле Федор Федорович Желтухин (1749-1812) Казан, Нократ, Пенза, Сарытау губерналарындагы 9000 душ крестиянга хуҗа була. Казан вице-губернаторы, Тубыл губернаторы, Нократ наместниклыгы идарәчесе вазифаларын били. 1784 елда «олуг мәрхәмәт иясе»нең тырышлыгы белән Себерне яулап алуның 200 еллыгы «тантаналы рәвештә» бәйрәм ителә, төрле шәһәрләрдә рус телле уку

●**Биккенә Бикчәнтәй углы истәлегенә куелган кабер ташы.**

йортлары ачыла... Ни кызганыч, Г. Тукайның «Рус белән тормыш кичердек сайрашып, Тел, легать, гадәт вә әхлак алмашып», - дигән сүзләре бу очракка һич тә туры килми.)

Авылда мәчет төзү турында император карары 1883 елның 11 ноябрендә кабул ителә. *(БР ҮТА. 295 ф., 3 тасв., 10719 сакл. бер., 7 кгз.)*

Ниһаять, 1883 елның 22 ноябрендә авылга мулла итеп Габделгалләм Исмәгыйлевне (1835-1900) билгелиләр. *(ТР ДА. 2 ф., 2 тасв., 2568 сакл. бер., 15 кгз.)* Ул Ары мулласының улы була. 1875 елның 19 июнендә 1750 нче номерлы имам-хатыйб һәм мөдәррис шәһадәтнамәсенә ия булган бу шәхес Вятка губернасы Малмыж өязе Сәрдекбаш авылыннан чакырып алына. Габделгалләм мулла хезмәт итә башлагач, авылда мәчет салына, балалар сабакка йөри. Мулланың вакыты булмаганда, балаларга гыйлем бирүне абыстай башкара. Габделгалләм Исмәгыйлевнең беренче хатыныннан Габдрахман, Нәҗип, Мәннан, Газиз исемле уллары, Хөршид исемле кызлары туа. Уллары барысы да укып чыгып мулла булалар һәм читтә хезмәт итәләр. Беренче хатыны авыру сәбәпле, Габделгалләм икенче хатын ала. Бу никахтан соң бербер артлы Мәрьям, Саҗидә, Сәрбисафа, Фәрит, Мәлик, Кәримә, Фатыйма исемле балалары туа. Габделгалләм мулла вафатыннан соң аның эшен кече улы Габделгазиз дәвам итә. Ул 1906 елның 18 сентябрендә мулла итеп раслана. *(ТР ДА. 2 ф., 2 тасв., 7480 сакл. бер., 15 кгз.)* Габделгазиз мулланың Мөнир, Кәрим, Габдулла, Госман исемле уллары, Мәсрурә исемле кызы була.

1910 елда авылда зур янгын чыгып, биш-алты йорт яна. Гади крестияннар ярлы гомер итә. Җирләре аз, уңдырышсыз була. Аты булган кешеләр кыш көне төрле җирләргә барып ялланып эшли. Атсызлары, сумала кайнату өчен агач төпләре чыгарып, урманда чиләнә. Кайберләре авылга әйләнеп тә кайта алмый.

1911 елда авылда беренче мәктәп ачыла. Аның укытучысы итеп Мәгъния Сәетова (хәзерге Арча районына караган Түбән Оры авылыннан) билгеләнә. Мәктәп мөдире мулла үзе була. Моркида урнашкан волость конторасы кушуы буенча, метрикалар тутыру һ.б. язу-сызу эшләрен мулла үзе башкара. Революциядән соң татар балаларын программа нигезендә укыту башлана.

1918 елда авылда яңа мәчет төзелә. *(ТР ДА. 2 ф., 7 тасв., 2401 сакл. бер.)* Мәчет бурасы өчен һәр хуҗалыктан берәр, хәллерәкләреннән икешәр бүрәнә агач җыеп алалар. Төзү эшләренә матди ярдәмне Әтнә өязе Мамыш авылы бае Мәҗит Усманов күрсәтә. (Мәҗит бай Усманов үзенең туган авылында 30 балага исәпләнгән таш мәдрәсә төзетә. Мәдрәсәгә күрше-тирә авыллардан, хәтта Чар өязендәге татар авылларыннан килеп тә шунда яшәп белем алалар.)

Дин әһелләре авыл зиратын карап, өмәләр ясап, җыештырып тәртиптә тоту өчен дә җаваплы була. Авыл оешып җиткән заманнарда олы юл Чыршылык елгасы аша уза. Ике Шиншә арасыннан узган юл башта Сапка (Ключи-Сап), ә аннан Шөрунҗага (Шуруньжа) илтә. Шул исәптән, узган-барган дога кылып китәр дип, зират өчен җир авылның көнчыгышында бүленә. Ул зиратка беренче булып Рәхмәтулла (халык телендә аны Шөкери бабай дип йөртәләр) бабай җирләнгән. Яңа Комыгырҗага беренче булып нигез салучы Рәхмәтулла бабайның кабере авыл читендә. Авыл халкы аны хөрмәтләп, чардуган куеп, изге кабер буларак саклый.

Күпмедер вакыт узгач, олы юл авылның югары башына тоташа. Шуннан соң зират өчен җир авылның югары очы ягында бирелгән. Анда иң беренче итеп Биккенә исемле кеше җирләнә. Бу зиратка 1928 елга кадәр җирлиләр. Революциядән соң җир бүлгәндә, ул зиратның җире Мари Чодраял ягына кереп кала. Авылның бу өлешенә мөселманнарны җирләүгә марилар (бигрәк тә Марка белән Иван) каршы чыга. Шуннан соң авылның яңа (хәзерге вакыттагы) зираты барлыкка килә. Анда беренче итеп мәрхүм Сиражетдин (Сирай) җирләнә.

Габделгазиз мулла вафатыннан соң, 1934 елда мәчет ябыла. Бинасын авыл клубы итеп файдаланалар.

Габделгалләм мулланың икенче никахыннан туган улы Фәрит Галләмов башта муллалар хәзерли торган Кишет мәдрәсәсен, аннары Арча укытучылар хәзерләү училищесын тәмамлый. 1916 елда армия сафларына алына. Шунлыктан аңа мулла булып хезмәт итәргә туры килми. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Революция башлангач, революция ягына чыга. 1918 елда укытучы дипломы булганнарны, авылларда мөгаллимлек итү өчен, армиядән кайтаралар. Фәрит Галләмов Йошкар-Олада Мәгариф министрлыгында инспектор булып эшли. 1920-1921 нче уку елында мәктәптә Фәрит Галләмовның җәмәгате дә укыта башлый.

Кулак ярлыгы тагылучылар авылдан качып киткәннән соң, 1930 елда мәктәп элеккеге мулла Габделгазиз Галләмов һәм Шакир Нәҗмиев өенә күчә. 1934 елда колхоз тарафыннан яңа башлангыч мәктәп бинасы төзелә, ә 1938 елда әлеге мәктәп җидееллык итеп үзгәртелә. Фәрит Галләмов исә 1958 елга кадәр мәктәп директоры булып эшли. 1974 елда, балалар аз булу сәбәпле ябылып, авыл балалары Шиншә мәктәбенә йөри башлый. Укыту рус һәм мари, бераз татар телендә алып барыла.

1998 елның 26 августында Фәйзелгаян хаҗи Фатыйхов тырышлыгы белән авылда яңа кирпеч мәчет сафка баса. Төзелеш эшләре Илгиз Җиһаншин җитәкчелегендә башкарыла. Мәчет ачу тантанасында Марий Эл Республикасы Президенты Вячеслав Кислицын катнаша. Президент авыл урамына асфальт түшәргә вәгъдә бирә. Аның вәгъдәсе 1999 елда тормышка ашырыла.

ЯҢА ДӘВЕР, ЯҢА СЫНАУЛАР

1931 елда авылда М.Вахитов исемендәге колхоз оештырыла. Колхозга керүче хуҗалыклар саны 12 дән дә ким булмаска тиеш дигән шарт куела. Тат-Чодраялда күмәк хуҗалыкка 28 хуҗалык берьюлы керә.

Бу елларда ат абзары, складлар, сарай, сыер фермасы, әвен һ.б. объектлар төзелә. 1932 елда Тат-Чодраялда 103 хуҗалыкта 508 кеше яши. Шуларның 476 сын татарлар, калганнарын марилар тәшкил итә. Шул ук елның язында авылда колхозга кермәгән 7 хуҗалык кына кала. Колхозда марилар белән бергә 90 лап хуҗалык исәпләнә. Шул 90 хуҗалыкның 55 ендә ат асрыйлар. Колхозның 550 гектар басуы, 150 гектар печәнлек җире була.

Мари-Чодраялда, нибары 5 хуҗалык кына теләк белдерү сәбәпле, башта колхоз оештыра алмыйлар. Шуңа күрә алар Вахитов исемендәге колхозга кушыла. 1932 елда Мари-Чодраялда 130 мари гомер итә. 1933 елда анда М.Горький исемендәге авыл хуҗалыгы артеле оеша. 1949 елда М.Горький исемендәге колхозда 28 хуҗалыкта 134 кеше исәпкә алына.

Инкыйлабка кадәр Тат-Чодраялда бай дип исәпләрлек хуҗалык Шакир Нәҗмиевнеке була. Ул җил тегермәне, кечкенә генә кибет тота. Сәүдәгәр Биккенә дә чагыштырмача байлар рәтендә йөри. Ул үлгәч, аның улы Гәрәй бөлә. Шунлыктан 30 нчы елларда авылда кулак ярлыгы тагарлык кеше дә табылмый. Шакир Нәҗмиев бу вакытта инде бакыйлыкка күчә. Тегермәнен колхозга алалар. Уллары читкә чыгып китә.

1934 елда авылда, яшен сугып, зур янгын чыга. 10 йорт янып бетә. Бу хуҗалыкларга иминиятләштерү акчасы түләнә. Ул зыян күрүчеләргә бик зур ярдәм була. Шул ук елны сайлау уздырыла, мәчетне клуб итеп үзгәртергә дигән карар чыгарыла.

Колхоз оешкан тәүге елларда иген уңышы шактый югары була. Хезмәт хакы итеп 2-3 килограмм икмәк бирелә. Әммә 1936 елның җәендә корылык була. Икмәк уңмый, аны йолкып кына җыйныйлар. Хөкүмәт билгеләгән икмәк бәясе кибетләрдә арзан була. Авыл халкы Казанга барып ипи ташый. Язга чыккансы, колхозның бик күп атлары үлә. Дизентерия авыруыннан 25 кеше дөнья куя.

Репрессия җилләре колхозчылардан 1904 елгы Әхмәтхан Ибәтуллин (1938 елның 14 сентябрендә кулга алынган, 2 ел да 2 айга ирегеннән мәхрүм ителгән), 1908 елгы Газыйм Шакиров (1938 елның 25 июнендә кулга алынган, 1 ел да 19 көнгә ирегеннән мәхрүм ителгән), 1903 елгы Лотфулла Гыйниятуллин (1938 елның 14 сентябрендә кулга алынган, шартлы рәвештә 2 ел да 2 айга ирегеннән мәхрүм ителгән) язмышларына җәрәхәт ясый.

1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башлангач, Тат-Чодраял һәм Мари-Чодраял авылының 146 ир-егете Ватанны сакларга китә, шуларның 77 се яу кырында ятып кала. Кайбер чыганаклардан күренгәнчә, Тат-Чодраялдан фронтка 99 кеше китә, шуларның 54 се яу кырында ятып кала.

1941 елның 13 октябрендә СССР Дәүләт Оборона комитеты Идел буенда саклану чикләре төзү турында карар кабул итә. Шуны төзүгә авылдан ике ай дәвамында 60 кеше җәлеп ителә. Авыл халкы, үз хезмәтләреннән тыш, урман кисүдә катнаша.

Колхоз 1941 елгы янгыннан зур зыян күрсә дә, башка хуҗалыклар белән чагыштырганда яхшырак нәтиҗәләргә ирешә. 1951-1952 елларда «Октябрьгә 15 ел», «Вахитов», «Максим Горький» колхозлары берләшә.

1959 елда Чодраялда татар һәм марилардан барлыгы 295 ир-ат, 380 хатын-кыз гомер итә. 1958 елда хуҗалыкны Шиншә белән берләштерәләр һәм Ленин исемендәге күмәк хуҗалык дип атыйлар.

1972 елның 15 маенда авылда, балалар тәртипсезлеге аркасында зур янгын чыгып, 9 йорт янып бетә. Унынчысының каралтылары яна.

1973 елда МАССР Югары Советы Президиумы Карары нигезендә Мари-Чодраял һәм Тат-Чодраял авыллары бер исем белән генә – Тат-Чодраял дип атап йөртелә башлый.

1980 елда авылда 136 хуҗалыкта 226 кеше яши. Авыл халкында 103 велосипед, 58 мотоцикл, 5 мотороллер була. Халык кое суы эчә, хуҗалыкта зәңгәр ягулык һәм электр файдаланыла. Халык радио тыңлый, телефоннан сөйләшә, телевизор карый. 100 кеше сыйдырышлы клуб, библиотека, азык-төлек кибете хезмәт күрсәтә. Даруханә, участок хастаханәсе, урта мәктәп Шиншә авылында урнаша.

Туксанынчы елларда башланган икътисади торгынлык 2000 елларга кадәр дәвам итә. Авыл үсешенә тоткарлык ясала. 1930-2000 еллар арасында авылда 50 дән артык хуҗалык юкка чыга.

2002 елда Тат-Чодраялда 119 хуҗалыкта 396 кеше исәпләнә. Шәхси хуҗалыкларда 119 мөгезле эре терлек, 7 ат асрала. Мәдәният йорты, район кулланучылар җәмгыяте кибете эшли. 2010 елда халык саны – 306, аларның 154 се ир-атлар, 152 се хатын-кызлар.

Фидаил МӘҖИТОВ.

Көрәшче Мәүлә Колый

Питрәч районында «Мишә елгасы үзәнлегендә кеше һәм табигать, Казан артындагы Питрәч төбәгенең тарихы. Питрәч төбәге шәхесе Мәүлә Колый: тормышы эшчәнлеге, мирасы, һәм татар халкының рухи-мәдәни тормышына керткән өлеше» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция узды.

Питрәч районы җитәкчелеге, районның мәдәни һәм тарихи оешмалары, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте, Бөтендөнья татар конгрессының татар төбәкчеләре белән эшләү комитеты белән берлектә оештырылган җыенда катнашу өчен Россиянең 12 төбәгеннән, шулай ук Татарстанның 24 районыннан 150гә якын тарихчы, төбәкне өйрәнүче, дин эшлеклеләре, әдәбият галимнәре, укытучылар килгән иде. Гыйльми җыенда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, Питрәч районы хакимияте башлыгы Илһам Кашапов, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, галимнәр Индус ага Таһиров, Энгель Таһиров, Хатыйп ага Миңнегулов кебек мөхтәрәм затлар катнашты һәм чыгыш ясады. Конференция Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлап үткәрелде. Фәнни-гамәли җыенның секция һәм пленар утырышы яңа «Прогресс» күп профильле лицеенда узды. Фәнни-гамәли конференциядә төбәкне өйрәнүчеләр, дин эшлеклеләре, галимнәр, укытучылар сигез секциягә бүленеп эшләде, аларда барлыгы Мәүлә Колыйның тормыш юлы һәм иҗатына, туган як тарихына багышланган 100 дән артык чыгыш ясалды.

Татар әдәбияты тарихының кайсы гына чорына игътибарны юнәлтсәк тә, анда асылташлардай җемелдәп торган шәхесләрне күрәбез. Әдәбият галиме Х.Миңнегулов үз чыгышында искәртеп үткәнчә, XIII йөздә – Кол Гали, Алтын Урда чорында – Котб, Хисам Кәтиб, Сәиф Сараи, Мәхмүт Болгари, XVI йөздә – Казан ханлыгы чорында – Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, XVIII йөздә әдәбият мәйданына Утыз Имәни, Габдессәлам бин Урай, Габделҗәббар Кандалый һ.б. килә.

XVII гасыр татар әдәбиятында зур урынны Мәүлә Колый алып тора. Бу – татар халкы өчен бик авыр – милләтнең киләчәге кыл өстендә калган заманнар. Бу елларда татар дөньясы нык болганган, халкыбызның шактые кырылган, бер өлеше яшәү урыннарыннан читкә төбәкләргә, илләргә качкан, илдә урыслаштыру, чукындыру сәясәте канат җәйгән. Бу авыр заманда безнең дин әһелләребез, тәвәккәл, кыю фикерле затларыбыз электән килгән йола-традицияләрне яңартырга, сакларга, дәвам итәргә, аларны гавамга җиткерергә һәм алдагы буыннар өчен саклап калырга тырышкан. Шушы вакытта татар әдәбияты мәйданына электән килгән күп гасырлык әдәби, язма мәдәниятебез традицияләрен дәвам итүче, әдәби иҗатка мөрәҗәгать итеп, аны алдагы буыннарга тапшыручы, кыю фикерле Мәүлә Колый килеп чыга. Индус ага Таһиров үз чыгышында билгеләгәнчә, Мәүлә Колый – Тукаебызга тәңгәл кеше була. «Ул халкыбызның күтәрелешенә иң зур өлеш керткән кеше. Әгәр шушы рәвештә эш башкарылмаса, татарның яңарышы һич кенә дә булмас иде, халкыбыз иң укымышлы милләткә әверелмәс иде», – диде галим.

Х.Миңнегулов шагыйрьнең кыска гына гомерендә, иҗатында элекке казанышларга яңа төсмер биргән һәм алдагы буыннарга тапшыруын, аның шагыйрь генә түгел, имам да, халык хәрәкәтен оештыручы да, кешеләрне иманлы, намус, гадел яшәргә өндәгән фидакяр зат булуын да ассызыклап үтте. Кайбер чыганакларда М.Колыйның Степан Разин хәрәкәтендә катнашуы да әйтелә икән. Мәүлә Колый хикмәтләрен бүген дә дәрес итәргә мөмкин. Аның әсәрләре үзәгендә – кеше. Шагыйрь инсанны тәрбияләү мәсьәләләрен күтәрә, аның иманлы, намуслы, гадел, сабыр булуын, ата-ананы хөрмәт итүен алга куя, байлыкка, хакимлеккә кызыкмаска өнди. Татар тормышының үзәгендә игенчелек булган. М.Колый игенчелекне иң изге эш итеп санаган. Аның әсәрләрендә шулай ук гыйлемле булу кирәклеге әйтелә. Шагыйрь «Наданнар коңгыз-кортка охшар булгай», – дип, наданнарны тирестә казына торган коңгыз кортлары белән чагыштыра. Шагыйрь тормыштагы тәмәке тарту, хәмер эчү кебек ямьсез күренешләрне һ.б. тәнкыйтьли. Аның әсәрләрендә хәзерге заманга аваздаш булган, әһәмиятле, кызганыч ки, тормышыбыздан югалган, күбесе икенче планга калган мәсьәләләр үзәккә куела.

Әмма бүгенге көндә киң катлам Мәүлә Колыйны тирәнтен белми, аның затлы итеп нәшер ителгән бер генә җыентыгы да юк. Гомумән, Мәүлә Колыйга әле тиешле бәянең бирелгәне булмады. Әлбәттә, аның тулы басмасын әзерләү бик кирәк. Хатыйп ага үзендә сакланган басмаларны – Мәүлә Колыйның Камил Дәүләтшин әзерләп 2010 елда Уфада нәшер иткән шигырьләрен, Мәсгут Гайнетдиннең шушы гасыр башында «Иман» нәшриятында әзерләп чыгарган «Хикмәтләр» китабын гыйльми җыенны әзерләүчеләргә биргән. Аларны Альберт Борһанов җитәкчелегендә кабат бастырып чыгарып, конференциядә катнашучыларга тараттылар. Әлбәттә, Мәүлә Колый кульязмаларын эзләү дәвам итә. Заманында, галим Марсель Әхмәтҗанов, Мәүлә Колый биографиясен тасвирлап, аның Питрәчтәге Чыты авылында дөньяга килгәнен исбатлады. Шагыйрьнең безнең көннәргә кадәр сакланып калган йөзгә якын хикмәте тупланган кульязма мәҗмугасын Татарстанның Зәй-Каратай авылы кешесе Гайшә Мөхәммәдиевадан әдәбиятчы Фазыл Туйкә күчереп алган була. Археограф, текстолог Раиф Мәрданов М.Колыйның ике поэмасы теркәлгән кульязма җыентыкны 1990 елда Татарстанның Әгерҗе районындагы Яңа Аккуҗа авылында яшәүче Фазлетдин ага Габдрахмановтан алган. Шагыйрьнең әсәрләренең кульязмалары тагын да табылырга мөмкин. Әмма аларны төрле кешеләр күчергән, хаталар да киткәләгән. Шуңа да әсәрләр текстологик яктан эшкәртүне дә сорый. Соңгы 50-60 елда Мәүлә Колыйга игътибар булса да, аның әсәрләрен, хикмәтләрен фәнни өйрәнү, аларны тиешле кимәлдә укучыларга җиткерү күптән кирәк, югыйсә. Аннары шагыйрь иҗатының һич югы беркадәре үрнәкләрен рус, төрек, казах, кыргыз һ.б. телләргә тәрҗемә итү дә әйбәт булыр иде. Марат Әхмәтов та Мәүлә Колыйның тормышы һәм иҗаты әз өйрәнелүенә игътибарны юнәлтте. «Мәүлә Колый – милләтебезнең язмышы өчен көрәшкән кыю шәхесләрнең берсе, әмма иҗаты, эшчәнлеге бик аз өйрәнелгән. Бу җыенны алда торган зур эшләрнең башы дип кабул итәм», – диде. Интернетта да шагыйрь турында мәгълүматлар бик аз.

Питрәч хакимияте, үзләренең якташларын күтәреп, аны үзәккә куеп әһәмиятле эш башкара. Алар моның белән Питрәчнең үзен генә түгел, татар халкының да, әдәбиятыбызның да дәрәҗәсен үстерәләр, элеккеге мираска игътибарны да арттыралар.

Бу көнне шулай ук дәрәҗәле кунаклар катнашында Питрәч районының Чыты авылында Мәүлә Колый стеласына нигез ташы да куелды, аңа киләчәк буыннарга атап туган телне саклау һәм кадерләү турында рус, татар, инглиз, гарәп телләрендә мөрәҗәгать язылган капсула да салынды. Язуны 2072 елның 1 апрелендә ачып укыячаклар. «Мәүлә Колый дәвамчылары буларак, без аның мирасын киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез», – диде бу уңайдан район башлыгы Илһам Кашапов.

Авыл кергәндә урын алачак алты метрлы стела җәй айларында әзер булачак, аның әйләнә-тирәсен ямьләндерү, агачлар утыртылып, бакча ясау да планлаштырыла. Шулай ук бу көнне мәртәбәле кунаклар катнашында Чыты авылында 1991 елда төзелгән мәчеткә Мәүлә Колый исеме бирелде. Чыты авылында алга таба Мәүлә Колый музеен ачарга да ниятлиләр. Ул ишек алды белән бергә элеккеге татар йорты рәвешендә булыр, дип күзаллана.

Пленар утырышта Мәүлә Колыйның Казанда яшәүче туганнары Саҗидә Русинова, Әнис Ибраһимов та катнашты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

«Матур апа»

Шулай диде бәләкәй Әлисә өстәлдәге матур китапларны актарып утырганнан соң, берсеннән шагыйрәнең фоторәсемен күреп. «Каен алмасы», «Колаклы коймаклар», «Китаплы кич» китапларыннан берничә шигырьне укып күрсәткәч, кызчык бөтенләй җанланды. «Ятлыйм, ятлыйм! Бакчада сөйлим, язып кына бирегез әле!» – диде. Ә мин «Каен алмасы» дигән китапны үзенә бүләк иттем. Кызчык балалар бакчасында артистка булып санала. Бабасы аны күптән туган телебездә шигырьләр ятларга өйрәтте бит.

●Йолдыз Шәрапова каләмдәше Нурзия Мирхазова белән.

Әлисәнең бу сүзләре «Яңа гасыр» телеканалында «Әй, язмыш, язмыш» тапшыруын караганнан соң, кабат исемә төште. Бу эчтәлекле тапшыруның минем өчен кадере тагын да артты. Чөнки Йолдызның чын матурлыгы, эчке дөньясының гаҗәеп байлыгы шаккатырды. Моңа кадәр дә белә идек аның тормышындагы игелекләре хакында. Журналист буларак, «Яшь ленинчы» газетасында, «Ялкын» журналында даими чыгып килгән язмалары аша каләменә соклана идек. Дүрт улы янына ятим кыз алып үстерүләренә (бик теләсәләр дә, кызлары булмагач) халык, әлбәттә, рәхмәт-хуплауларын яудырды. Шулкадәр эшләве, гаиләсен, балаларын каравы өстенә әле Йолдыз атаклы Рәшидә Исхакый дәресләренә йөреп, намазга басты. Чын Ана, бәхетле хатын, олы шагыйрә, талантлы журналист, татар халкының асыл кызы! Менә кем ул безнең «матур апабыз» Йолдыз Шәрапова.

– Шигырьләрем белән үз балаларыбызны тәрбияләргә тырыштым. Иҗатым шуңа корылган. Үзебезнекеләргә аталган шигырьләрем аша бүтән сабыйларның да күңелләренә күркәм сыйфатлар орлыклары салынуы нык сөендерә, – менә шулай ди Йолдыз ханым тыйнак кына. Ул дүрт малай: Сәйдәш, Ядкәр, Айнур, Газиз һәм бер кыз Әдилә инде тәрбияле, иманлы-инсафлы булып үсте. Алар бүген туган телнең сакчылары, милләтебезнең тугры ул-кызлары, әти-әниләренең зур бәхете. Йолдызның бәхете яраткан ире Сирин белән бергә, бер-берсен аңлап, санлап, хөрмәт итеп яшәүдә.

Хәзерге көндә Йолдыз Шәрапова «Шәһри Казан» газетасында эшли. Аның халкыбыз мактанычы булган ул-кызларыбыз турындагы язмаларын укып куанабыз. «Шәһри Казан»ның әле 23 март санында гына чыккан «Ерак Көнчыгыш асылташы» дигән мәкаләне искә аласым килә. Атилла Расихның кызы Фәридә Рәсулова абыйсы Илдарны эзләп чыгып вафат була. Тәкъдир! Артем шәһәрендә татар-башкорт иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Фәния Хисамова Фәридә ханымны җирләүне үзе хәл итә. Йолдыз аның белән элемтәгә чыга. Фәния ханым бик игелекле милләттәшебез икән бит! Шунда Ерак Көнчыгышта фаҗигагә юлыккан татар солдаты Рәмиснең хастаханәдә дәваланып өч операция кичергән чорында 7 ай буе 50 чакрымлы араны узып, хәлен белешеп тора, күчтәнәчләр ташый. Ул шунда яшәүче милләттәшләребезнең авторитеты, булышчысы, яклаучысы да икән.

16 китап! Аларда – балалар дөньясы! Элегрәк чыккан «Ярый әле» китабын Яшел Үзәннең «Идел» шифаханәсе китапханәсендә күреп алган идем. Бер кичтә укып чыктым һәм моңа хәтле Йолдызның мондый шигырьләрен белмәгәнемә бераз оялдым да.

Аның балалар өчен язылган китаплары үзләре бер ачыш. Чын сабыйлар теле, уйлавы-уйнавы белән шыплап тулган алар. «Антенналы бәрәңге» дигән беренче җыентыгы «Ел китабы-1994», «Китаплы кич» җыентыгы «Ел китабы-2018», ә инде ике телдәге «Аппак һәм Шапшак» китабы «Ел китабы-2016»да призлы урыннарны юкка гына яуламаган. Китапларның исемнәре дә оригиналь бит. «Колаклы коймаклар», «Каен алмасы» – барысы да нәкъ балаларча.

Менә иң яңа китабы «Тәмле сүзләр» 2021 елда китап нәшрияты табасыннан төшкән. Шулхәтле матур сурәтләр, нәкъ шигырьләр эчтәлеген ача торган чын үзебезнең милли бизәкләр, милли вәзгыять! Рәссамы – Илдус Әҗемов. «Телебез, динебез, гореф-гадәтләребезгә багышланган балалар өчен иҗат ителгән шигырьләр тупланмасы.

Дәү әниемдә бик күп
Бал кебек тәмле сүзләр.
Ишеткәндә сөенечтән
Елмая минем күзләр.

Менә бу шигъри юлларны укыганда кем генә елмаймас икән?! Әйе, анысы хак: әби-бабайлар оныкларын аеруча ярата. Бәләкәчләребезне иркәләп сөйгәндә үзебезнең дә җаннар нурга күмелә бит! Телдә гел матур сүзләр, күңелдә гел изге теләкләр. Бу хисләрне шушындый ихлас шигырь юлларына салу – бусы чыннан да чын шагыйрьлекне дәлилләли. Китапның битләрен ачкан саен, балалар дөньясына ныграк, тирәнрәк кереп чумасың.

Актәпинең балалары:
Аккойрык та Акмуен.
Өрәләр дә йөгерәләр,
Йөгерәләр дә өрәләр -
Бар белгәннәре уен.
....
Татарча исемле бу этләр
Урысча аңламыйлар.
Урысча дәшкән малайны
Дуска да санамыйлар,
Борынын яламыйлар.

«Сизгер бакалар», «Алтын балык», «Рәхмәт яңгыры», «Тылсымлы түбәтәйләр» – балаларча ихласлыкка терелеп бирелгән олы максатка мәдхия бу, туган телебезне сакларга, балаларга-оныкларга сеңдерергә тиешлегебезне искәртү.

Й.Шәрапованың шигырьләре заманча, көн кадагына суга торган мәгънәле. Һәркайсы укучыны туган телебезне, гореф-гадәтләребезне саклаудагы бурычларыбыз турында уйландырырлык.

Бу изге иҗат киң халык тарафыннан танылды. Балалар шигырьләрне бик теләп укый, ятлый, чыгышлар ясый. Әсәрләрнең шактые мәктәп дәреслекләренә кергән. «Яңа гасыр»да Й.Шәрапованың шигырьләрен балалар сөйләгәнен тыңлап та, аның сүзенә язылган «Тылсымлы «Туган тел» җырының «Балачак җыры» бәйгесенең беренчесендә үк җиңеп чыгуына сөенгәнем бар.

Республика балалар китапханәсе коллективының Йолдыз Шәрапованы бөек Тукаебыз премиясенә тәкъдим итүләре бик тә урынлы. Бу иҗатта газиз халкыңа, газиз илеңә-җиреңә җаның-тәнең белән бирелгәнлек, аңа мәхәббәт, тугрылык, фидакярлек гел Тукайча чагыла.

Мөслимә ШӘФЫЙКЪ,
матбугат ветераны.
Казан шәһәре.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

9 апрель (шимбә). ***Рамазан аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 8.51 сәгатьтә калка, 3.30 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.43 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин. Мунча керү файдалы.

Җиләкле май

Күп кеше, холестерин микъдары артудан куркып, атланмай ашамый. Организмга исә бу витаминлы продукт бик кирәк. Майның зыянын киметү өчен, аңа мүк җиләге кушалар. 200 грамм йомшартылган майга чирек стакан мүк җиләге, 1 чәй кашыгы төелгән дарчин һәм 1 аш кашыгы бал кушып, блендерда болгаталар да, икмәккә ягып ашыйлар.

10 апрель (якшәмбе). ***Рамазан аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 10.01 сәгатьтә калка, 3.53 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.48 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Өрек сихәте

Көнгә 100-150 грамм күрәгә ашау йөрәк аритмиясе һәм ишемия авыруыннан бик файдалы. Тәмәке тартасы килгән чакта бер күрәгә ашап кую тарту теләген бетерә. Эчәкләрнең кыскаруын яхшыртып, өрек эч катудан саклый. Тик менә симерү һәм шикәр чиреннән интегүчеләргә әлеге җимешне чикләнгән күләмдә генә куллану зарур. Шулай ук ашказанында җәрәхәт булган кешегә дә өрек ашарга киңәш ителми. Шешенкелекне бетерү үзлегенә бәйле рәвештә, өрекнең куе төнәтмәсе - йөрәк-кан тамырлары системасын дәвалаганда алыштыргысыз чара.

11 апрель (дүшәмбе). ***Рамазан аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 11.19 сәгатьтә калка, 4.10 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.52 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Суган кайнатмасы

Бавыр авыртканда, болай дәвалану файдалы. 1 килограмм суганны турап, 2 стакан шикәр кушып болгаталар да, газ мичендә сары ширбәткә әйләнгәнче тоталар. Иртән ач карынга 1 аш кашыгы кабалар. Дәва курсы – берничә ай.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

12 апрель (сишәмбе). ***Рамазан аеның 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,12.40 сәгатьтә калка,4.22 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.57 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Эч кипкәндә

Кызыл чөгендер, помидор, кишер, болгар борычы, суганны (төгәл пропорцияләр юк, чөгендер генә башка яшелчәләрдән күбрәк булырга тиеш) иттарткычтан чыгаралар да, тоз һәм шикәр кушып пешерәләр, банкага салып, суыткычта саклыйлар. Көненә бернечә тапкыр 2-3 әр кашык ашыйлар. Яисә ярты стакан су кушылган 1 стакан сөткә 2 алманы турап, кайнап чыкканнан соң 7 минут пешерәләр дә, ач карынга ашап бетерәләр.

13 апрель (чәршәмбе). ***Рамазан аеның 12 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,14.04 сәгатьтә калка,4.32 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 14.01 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Сулыш кысылганда

Тын беткәндә булыша торган нәтиҗәле чара бар. 10 бүлемтек сарымсакны пыяла банкада изеп, 10 лимон согы, 1 кг бал кушып болгаталар да, капкачын ябып, суыткычта 1 атна тоталар. Аннары көн саен 4 әр чәй кашыгы кабалар. Дәва курсы – 2 ай, бер көн дә калдырырга ярамый. Яисә 2 аш кашыгы мелиссаны 1 стакан кайнар суда 10 минут тәнәтәләр дә, сөзеп, өчкә бүләләр һәм көн дәвамында эчеп бетерәләр. Чәй пешергән саен мелисса яфраклары кушарга да була.

14 апрель (пәнҗешәмбе). ***Рамазан аеның 13 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 15.28 сәгатьтә калка, 4.41 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 14.06 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төякkә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

15 апрель (җомга). ***Рамазан аеның 14 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,16.54 сәгатьтә калка, 4.50 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 14.10 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Чикләвекле кәнфит

1 әр стакан шикәр, вакланган чикләвек һәм салкын сөтне яхшылап болгатып, кайнатып чыгаралар, сүрән утта, әледән-әле болгаткалап, куерганчы пешерәләр. Сөт парга әйләнә башлагач, чикләвек янмасын өчен, гел болгатырга кирәк. Тәлинкәне майлап, куе массаны шунда җәяләр, суынгач, кисәләр.

Бай иҗатлы Байтирәк

Бүгенге абстракт музыка канат җәйгән чорда Илһам Байтирәк иҗаты үзенең байлыгы һәм матурлыгы белән күңелне әсир итә. Аның музыкасы тулып-ташып ага да ага, ул гүя иксез-чиксез чишмә… Ирексездән әлеге дөньяга чумып тормыш мәшәкатьләрен бөтенләй онытып җибәрәсең.

Илһам Байтирәк иҗаты белән миңа узган ел якыннан танышу насыйп булды. Концерт заллары ябык, музыка дөньясына юллар бикле, нindидер күңелгә авыр халәт иде. Мине шул чакта депрессиягә бирелүдән нәкъ менә аның музыкасы коткарып калды да. Аның язмаларын тыңлаганда, кинәт минем күз алдымда композиторның саф, ихлас эчке дөньясы ачылып киткәндәй булды. Бу – минем өчен чын ачыш иде. Яшьлегемдә үзем өчен нәкъ шулай итеп Мансур Мозаффаровны ачканым исемә төште. Музыкадагы аңлаешсыз чалымнар урынына – күңелгә ятышлы ягымлылык белән тетрәндергеч хәрәкәтнең үзара үрелүен күрү - бу инде җан төпкелендә казыну гына түгел, ә фикер йөртүдән, хакыйкатькә ирешүдән хасил булган тоташ шатлык хисе иде. Шул чагында Илһам Байтирәк – М.Мозаффаров музыкасын заманча дәрәҗәдә дәвам итүче бит, дип уйлап куйдым. Бу музыканы тыңларга кирәк, ләкин хәзер Байтирәкне генә түгел, көнебезнең башка композиторларын да телевизор экраннары һәм радио аша ишетүе мөмкин түгел диярлек: бик кыенлык белән эстрада әсәрләренә генә чыгару мөмкинлеге бар. Болай булырга тиеш түгел дә бит. Әгәр дә әсәрләрең кабат-кабат җанлы музыка коралларында уйналмый икән, кем өчен язарга соң ул чакта?.. Ә инде «Әсәрегезнең бернечә минутын кыскартсагыз, без аны башкарачакбыз», – диюләре исә бөтенләй акылга сыярлык түгел. Мине бу очрак тирән гаҗәпләндерде. Иҗатчыга мондый сүзләрне, гомумән, ничек әйтеп була? Бу бит рәссамга киндергә сыймауны сәбәп итеп, Мона Лизаның колагын яки күзен кисеп калдырырга тәкъдим итү белән бер! Гаиләңне ашатыр өчен, син бүген иҗатыңны акча эшләүгә сарыф итәсең, яследә эшлисең, уннарча ел буе башкаларның иҗатын туплап нәшриятта эшләргә мәҗбүрсең. Яисә вахтер булып утырасың… Берәмтекле тауар булган профессиональ композитор менә шулай бәяләнә бүген.

Байтирәк тә конкурсларда үзенең яңа әсәрләре белән катнашып, грантлар откан. Ләкин тормышны алып барырга бу гына җитми шул. Үзе чыгарткан дисклардан мин аның барлык симфоник оркестр өчен язылган әсәрләрен тыңлап чыктым, кулымны йөрәгемә куеп әйтә алам – бу музыка хисләндерә, дулкынландыра, бинһая рухи канәгатьләнү бирә. Аның музыка теле аңлаешлы. Ул тел җете бизәкле, моңлы, аһәңле, образлы, чын милли, татарча. Аның иҗаты халык җырларының тирән тамырларына, Мозаффаров, Сәйдәшев, Яхиннар салып калдырган традицияләргә нигезләнә. Ул яңа заманда әлеге традицияләрне дәвам итә. Моны Илһам Байтирәк әсәрләренең колачлы булуына таянып әйтәм. Ә нәрсәдән башланган соң бу?

Ул искиткеч зыялы гаиләдә туып-үсә. Әтисе – табиб, әнисе – укытучы. Өйләрендә пианино була, һәрчак музыка яңгырап тора. Музыкага сәләте дә бик яшьли, 2 сыйныфта укыганда ук ачыла башлый. Шул яшьтә ул үзенең беренче әсәрен язып карый, аннары ул гаҗәеп педагог Лоренц Блинов шәкерте була, ә музыка училищесында һәм консерваториядә исә профессор Шамил Шәрифуллиннан белем ала. Үзенең остазын искә алып, Илһам бер интервьюсында аның турында: «Ул күбрәк сүгә иде, тәнкыйтьли иде һәм бик сирәк кенә мактап җибәрә иде. Ләкин аның педагогик алымы бик лояль иде. Шамил әфәнде беркайчан да минем әсәрләремә кул тигезмәде. Хәтта гади көйләр язганда да ул халык һәм күренекле композиторларның көйләрен мисалга китерә иде.

Әлбәттә, Шамил әфәнде фольклорчы буларак халык көйләренә акцент ясый иде. «Халык җырлары телдән телгә, буыннан буынга күчеп, шомарып бетә, һәм ахырда энҗеләр генә кала. Алар камил була. Шуңа күрә көйнең төзелешен халык материалында өйрәнергә кирәк», – дигән сүзләрен искә ала Илһам.

Мин аны 7 нче сыйныфта укыган чагыннан хәтерлим, ул 5 нче музыка мәктәбендәге бер кичәдә үз әсәрен уйнаган иде. Консерваториядә укыганда да, ул барлык танылган композиторлар белән аралашып яшәде. Хәзер аның әсәрләрен А.Сладковский җитәкчелегендәге татар дәүләт симфоник оркестры һәм Россиядән читтә яшәүче музыкантлар да башкара. Академик жанр белән берррәттән Илһам Байтирәк иҗатында зур катламны эстрада музыкасы биләп тора. Җырлардан тыш, композитор эстрада һәм джаз ритмнарында язылган инструменталь пьесалар иҗат итә. Шуларның берсе – күпләрнең концерт репертуарларына кергән, фортепиано дуэты өчен язылган виртуоз «Эстрада сюитасы».

Холкына хас булганча, И.Байтирәк бик актив шәхес, ул һәр съездда, җыелыш, пленумнарда чыгышлар ясый, үз сүзен әйтә. Аның хезмәт сөючәнлегенә, эшкә сәләтенә, мәдәниятнең күп өлкәләрендә киң карашлы булуына сокланмыйча мөмкин түгел. Сүземне йомгаклап, аның танылган шәхесләребезгә багышлап язылган әсәрләрен искә алып китәргә телим. Шуларның берсе – бөек Тукаебыз белән Илһамның бабасы дус булган, шагыйрь хәтта аңа атап: «Фамилиясе Байтирәк, аның кебекләр сирәк. Мондый кешеләр кайда? Безнең милләткә кирәк!» – дигән юллар да язган, диләр. Композиторның Салих Сәйдәшевкә багышлап язылган әсәрләре дә байтак. Аның иҗатын симфоник, камера, вокаль музыка, балалар өчен музыкаль әсәрләр тәшкил итә. Аның күп кенә әсәрләре музыка уку йортларының уку-уйнау репертуарына кертелгән. Ике симфониясе, «Сәрвиназ» балеты, «Гөлнара», «Дала» симфоник поэмалары, валторна һәм оркестр, виолончель һәм оркестр өчен концертлар һәм башка әсәрләрен барлап карасак, без бу композиторның гомере һич тә әрәмгә узмаган, ә халкыбызның музыка хәзинәсен баетуга зур өлешен керткән һәм шул иҗтиһадын дәвам итә дип әйтә алабыз.

Шуңа күрә дә чорыбызның әлеге күренекле композиторын бүген Тукай бүләгенә тәкъдим итү бик тә вакытлы булды, дип саныйм.

●«Мирас» фестивале концертыннан соң.

Клара ТАҖИЕВА,
музыка белгече,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Г.КАМАЛ ИС. АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

9 апрель – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).

10 апрель – 12.00, 12.30 – «Дәрсе гыйбрәттер театр» (Р.Мөхәммәтшин). 18.00 – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).

12 апрель – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).

13 апрель – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).

14 апрель – «Исәнмесез!?» (М.Гыйләҗев).

15 апрель – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).

М.ҖӘЛИЛ ИС. АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

11 апрель – «Тщетная предосторожность» (Л.Герольд).

К.ТИНЧУРИН ИС. ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

9 апрель – «Кияүләр» (Х.Вахит).

10 апрель – «Полиционер» (И.Зәйниев).

12 апрель – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).

13 апрель – 13.00, 18.30 – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).

14 апрель – 14.00 – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).18.30 – «Алтын көз» (Ш.Фәрхетдинов).

15 апрель – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИС. ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

12 апрель – «Корт» (Ф.Галиев).

13 апрель – 13.00 – «Асылкош җыры» (Р.Мөхәммәтшин). 18.30 – «Шәй-бу! Шай-бу!» (К.Кәримов).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

9 апрель – 11.00, 13.00, 15.00 – Цирк на нитях. 12.00 – «Су анасы» (Г.Тукай. З.Хөснияр инсценировкасы).

10 апрель – 10.00 – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина). 12.00, 14.00 – «Новые приключения трех поросят» (Б.Вайнер). 13.00 – «Җырла, Курай!.. Уйна, Шомбай» (С.Дорожко).

15 апрель – 11.00, 13.00 – «Дюймовочка» (Г.-Х.Андерсен). 19.00 – Премьера. «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).

Г.ТУКАЙ ИС. ФИЛАРМОНИЯНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

13 апрель – «Бряц Гайс» төркемә балалайкаларда музыка башкара.

15 апрель – Даниил Прокопьев башкаруында «Вечер на Кубе» дип исемләнгән концерт.

С.СӘЙДӘШЕВ ИС. ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

10 апрель – Орган музыкасы концерты. Башкара – Татарстанның атказанган артисты Лада Лабзина.

ТӘҢРЕ ТАМГАСЫ

(Ахыры. Башы 12 нче санда).

Икенче кыйссаны төгәлләгән ат мотивы өченче кыйссага алып кереп китә: «Ат җибәрдем табырга». Бу исем – халык җырыннан алынган (табырга – ирекле утлауга мәгънәсендә), халыкның ирекле-иркен яшәү рәвешенә кагыла. Аның артыннан килгән «Угыз сөте» кабат Сөембикә туган нугай далаларын иңли, андагы тормыш-көнитешкә туктала; Казанның егылуын, Сөембикәнең һәм Үтәмеш-Гәрәйнең Мәскәүгә озатылуын бер халыкның үз тормыш-яшәеш тәртибен югалтуы итеп шәрехли. Еглау-сыктау жанрына охшатылган «Үтәмеш-Гәрәй хан» – ханбикәнең һәм аның улының фаҗигасен яңарта. Шул рәвешле, халык җыры, халыкның ышанулары һәм гадәтләре, көнкүреше – тормышта җуелып, тарихи хәтердә сакланучы кыйммәтләр буларак тергезелә.

«Кантүрә» кыйссасы татарларның империя басымы астында яшәү чорына кагыла, күп кенә тарихи вакыйгаларны хәтергә китерә, алар өчен сызландыра, шулар белән янәшәдә ил-йортыбызның шушы җирдә булуы да, Рәсәй империясенең Алтын Урда дәвамчысы икәнлеге дә, моның сәбәпләре дә – бүгенге укучыны борчый торган сорауларга җавап итеп яңгыратыла. Аннан соң килгән «Кайтып илен тапмаса», «Кисектел кыйссасы» – төрле заманнарда ирек өчен җанын аямаган батырларга мәдхия булып яңгырый. Кабат – азатлыкны кайтару өчен көрәшчеләрнең: Кантүрәләрнең, Батыршаларның халыкта онытылмавын искәртә.

Аннан соңгы ике бүлекчә лирик җырау формасында язылганнар. Аларда халыкның хәтерен яңартырга сәләтле Чатыр таулар, Ык буйлап дисбе кебек тезелгән авыллар, учаклар һәм ак кылганнар, җиләклекләр һәм чабыр үлән исләре – милли менталитетның билгеләре булып тәгәлләшә. «Җиләкле учак урыннары» – югалтуларны күңелдән үткәрү, шулар аша киләчәкне фаразлау булса, «Ырудашым чабыр үлән» дигән соңгы бүлек тарихи хәтернең – тарихи хакыйкатьне дә, ил-күчне һәм ил-көчне дә тергезер кыйммәт булуын раслый. Шул рәвешле, тарихи дастандагы шикелле, Л. Зөлкарнәй дастанында да борынгы шигъри жанрлар билгеле бер тәртиптә берсен-берсе алмаштыра.

Әмма әсәр моның белән төгәлләнми. «Идегәй итеге (Кунычтагы илъязма)» дигән өченче баб тагын 4 кыйссаны берләштерә. Алар тарихи хәтернең тергезүнең үзгә юллары турында сөйли. Илъязма – ягъни язма сүз, тарихның хатирәсе буларак, аны саклаучы һәм киләчәк буыннарга тапшыру гыйлеме. Беренче кыйсса – «Җәбәлестан» шагыйрь тарафыннан «Нәкый Исәнбәт рухына дога» дип багышлана. Ягъни бу бүлекчә – «Идегәй» дастанын җыеп халыкка кайтарган, шул дастаннарда Алтын Урда тарихының һәр сәхифәсен тергезгән галимнәрнең хезмәтен бәяләү итеп уйланылган. Андыйларны шагыйрь, исламдагы тирән мәгънәле гыйбарәне уйнатып, «Ил рухына Китап чыгучылар» дип атый.

Икенче кыйсса «Яса-ясама» совет чорында татарның тарихын үзгәртү – «итектән чыккан» тарихны чабата тарихы итеп халыкка кайтару проблемасын күтәрә. Кыйссаның исеме Чыңгызның бозарга ярамаган Кануны – «Яса»-ны искә төшерә; Мәскәүнең татар тарихын үзгәртергә омтылышын – шул Канунны үзгәртү белән тиңли.

«Иске Кисекбаш» бүлекчәсе тарихтан – XXI гасыр башына, Советлар берлеге таркалып, мөстәкыйльлек даулаган көннәргә алып кайта, өметләр һәм аларның өзелүе хакында сөйли.

Соңгы бүлекчә «Җидесу» дип атала, шагыйрь аны «Миркасыйм Госманов рухына дога» дип төгәлләштергән. Татар тарихчыларының онытылган-югалтылган татар тарихын кабат тергезүен – шагыйрь хәтер төпкеленә ук атуга тиңли.

Гомумән алганда, «Алтын Урда» – борынгы, онытылган һәм ерак җан хәтерендә генә яши торган жанрларны тергезү тәэсирен уята. Текстның үз логикасы бар, андагы охшаш яңгырашлы сүзләр тезмәсе күңелдә аерым сүз-образларга бәйле калкулана торган тарихка мөнәсәбәт, хис-кичереш кузгатса, катлаулы структура бөтенләй башка, тирән эчтәлеккә алып керә.

Минем өчен әлеге бәйләм – татар поэзиясенең модернизмны яңартып элитар, югары сәнгать үрнәкләре тудыруына мисал, бәлки, төрки әдәбиятларда модернизмның XXI гасырдагы яңарыш юлыдыр (бигрәк тә хәзерге үзбәк әдәбиятындагы тәҗрибәләр белән чагыштырганда). Ул башка төрки халыклар өчен дә кызык булыр иде, әсәрне башка төрки телләргә тәрҗемә итәргә кирәклеге бәхәссез.

Шул ук вакытта китапның соңгы өлешендәге «Алтын Урда» белән танышкач, җыентыкның төзелешенә, тупланышына карата канәгатьсезлек хисе туа. Мөстәкыйль шигырьләр төсендә китапның беренче өлешенә чәчелеп кертелгән (аларның зур күпчелеге «Алтын Урда» бәянына эскиз дип билгеләнгән булса да) текстлар гомуми уңай тәэсирне киметә. Аларның күбесе, чыннан да, эскиз хәлендә, уйланып-эшләнеп бетмәгән. Күбесенең эскиз булуы да күрсәтелмәгән. Әйтик, «Кирмән тау һәйкәле» исеме астында бирелгән этюд күп сораулар уята, анда фикер аныклыгы юк. Шул ук текст «Алтын Урда» эчендә (399 бит) бөтенләй башка яңгыраш ала! Бәхәскә урын калдырмас өчен, шунысын да искәртик. Эскизлар җыентыкларга ике очракта туплана ала: чын мәгънәсендә мөстәкыйль шигырь булып өлгергәндә, яки шагыйрьнең иҗат лабораториясен күрсәтү өчен – әсәр ахырында махсус туплап бирелгәндә генә.

Шагыйрьнең 1970-1980 һәм XXI гасыр башына караган әсәрләрен аралаштырып урнаштыруы турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Л.Зөлкарнәйнең 1970-1980 еллар иҗатында – модернистик алымнар белән баетылган романтик язу рәвеше, фикер аныклыгы өстенлек итә. Шигырьләрнең лирик герое – матурлыкны тоя-күрә һәм кабат тудыра белүче, гамьле, романтик табигатьле шагыйрь булып күз алдына килә. XXI гасыр шигырьләре бөтенләй башка – алар тулысынча модернистик дулкында, борынгы тарихи һәм әдәби мәгълүматлар белән уйнауга, охшаш яңгырашлы сүзләр тезү хисабына катлауландыруга корылып, еш кына бу фикер төзеклегенә зыян китерә – асмагънә эзләргә этәрә. Мондый текстларны янәшә кабул итү авыр. Шул сәбәпле соңгы әсәрләрдә текстларның эчтәлеген махсус киңәйтү вакытында укылыш юнәлеше һәрвакытта да ачык күренеп тормау – укучыны фикернең тәмамланмаганлыгы, анык түгеллеге кебек нәтиҗәгә китерә.

Аерым бер очракларда тарихи мәгълүматларның кискенрәк шәрехләнүен дә әйтик. Сөембикәне озату вакыйгасын Кол Шәриф белән бәйләү шундыйлардан. Шиксез, Казан ханлыгының сәйеде анда булган, әмма әсәрләр эчендәге эмоциональ бәя (әйтик, 405 биттәге «Алтын Урда»дагы «Ханбикәне әманәткә бирешкәннең / Чалма башын татар орган чукмар ярды....» тезмәсе) аны бу хәлдә гаепләү чигенә җитә. Тарих фәнендә бу чыганаклар белән расланмый; Кол Шәриф Казанны Мәскәү гаскәреннән корал белән саклаганда һәлак була.

Яки тагын бер мисал – Үтәмеш-Гәрәйне «Казан ятиме» шигырендә Идегәйнең оныгы итеп күрсәтү (69 бит). Бер яктан, монда хилафлык юк: Йосыф мирза кызы Сөембикә ягыннан Үтәмеш чыннан да Идегәйнең нәсел шәҗәрәсенә барып тоташа. Әмма төрки-татарларда туганлык эти ягыннан билгеләнә бит: Үтәмеш – гәрәйләрдән, чыңгызыйлардан! Идегәйнең чыңгызый булмавы сәбәпле Ак киезгә күтәрелә алмавын искә төшерсәк, бу тарихи шәрехләүнең урынсыз булуы күренә.

Гомумән алганда, Ләис Зөлкарнәйнең «Узганны кабатлау» җыентыгы – шигырь яратучыларга зур бүләк. Интеллектуаль поэзия, модернистик шигърият үрнәкләре тупланган, фикри-фәлсәфи тирән әсәрләр – күпләр өчен тормыш-яшәешкә, кешенең кешелек асылына, татар холкы-характерына, миллилеккә авторның үзенчәлекле карашы белән кызыклы тоелыр. Зәвыклы укучы саф татарча матур әдәби тел, аһәңле-көйле яңгыраш, мөлдерәмә моң-сагыш табар. Сүзләрдән сурәт ясаучы рәссам каләме белән язылган иҗат, узганны кабатласа да, беркемне дә кабатламый.

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы.

"Яшел" миллиардерлар

Дөньяда иң бай кеше булып танылган Илон Маск Bloomberg басмасы төзегән "яшел" миллиардерлар исемлегендә беренче урынга куелган – былтыр аның мөлкәте 70 процентка арткан һәм 288 миллиард долларга җиткән. Капиталының күп өлеше (248 млрд) һәркемгә мәгълүм электрокарлар гына түгел, энергия саклау системалары һәм кояш чирәбе дә җитештерә торган Tesla компаниясеннән керә. Исемлеккә шулай ук җиһанда иң күп аккумулятор җитештерә торган CATL компаниясе башлыгы Цзэн Юйцюнь (капиталы – 95,2 млрд) һәм BYD автоконцерны хуҗасы Ван Чуаньфу (48 миллиард) да кертелгән. Унбиш "яшел" миллиардерның гомуми байлыгы 500 миллиард доллардан арткан. Яңа исемлек "яшел" миллиардер концептының соңгы елларда никадәр үзгәрүен ачык күрсәтә. 2015 елда әлеге сүзтезмә үз байлыгының бер өлешен әйләнә-тирә мохитне саклауга тотучы эшкуарларны аңлатса, хәзер исә экологик чиста проектларны гамәлгә кертү нәтиҗәсендә байлык туплаучы эшмәкәрләрне күздә тота. "Яшел" миллиардерларның 80 проценты Кытайда туган, бу илдә экологик технологияләрнең бик тиз үсешенә тагын бер дәлил булып тора. Исемлектәге 15 эшкуарның өчесе генә Кытайныкы түгел – Маск үзе, тагын Лео КоГуан (Сингапур) һәм Энтони Пратт (Австралия).

("РБК").

Казанышлар китабы

1955 елның 27 августында Гиннессның рекордлар китабының беренче чыгарылышы дөнья күргән. Йөздән артык илдә 25 телдә нәшер ителеп, ул иң күп сатыла торган еллык басма буларак үзе дә рекорд куйган – Библия, Коръән һәм Мао Цзедун цитаталары тупланмасының тиражлары гына аныкыннан зуррак. Бу китапка кешелек тормышындагы төрле казанышлар туплана. Алар арасында чынлап сокландырырлыклары да, кеше көлдерерлекләре дә бар. Кайберләрен искә төшерик әле. Опера җырчысы Лучано Паваротттины 165 тапкыр биска чакырганнар, алкышлар 1 сәгать 7 минут буе тынмаган. Пушкар Непал исә, китапка керү өчен, минутына 134 тапкыр үз башына үзе суккан. Австралиядән Лес Стюарт дөньяда иң зур һәм иң мәгънәсез китап язган: 16 ел һәм 7 айда ул, җиде язу машинкасын туздырып, 19890 биттә бердән миллионга кадәр саннарны хәрефләр белән язып чыккан. "Даһи" әсәрнең соңгы юлы мондый: "Тугыз йөз туксан тугыз мең тугыз йөз туксан тугыз, бер миллион." Рекордлар китабына кертелгән россиялеләр дә шактый. Мәсәлән, дөньяда иң күп бала тапкан хатын – Шуя өязе крестьяны Федор Васильевның хәләл җефете (1707-1782). Ул 69 бәби тапкан: 16 игезәк, 7 тапкыр өчәр игезәк, 4 тапкыр дүртәр игезәк. Сабыйларның күпчелеге исән калган. Безнең көннәр каһарманнары - Красноярскидан Николай Петшак һәм Наталья Усачева Тын һәм Төньяк Боз океаннарында Чукоткадан Арктикага кадәр 134 чакрымны бозлы суда йөзеп үткән. Данлыклы фигуралы шуу остасы, өч тапкыр Олимпия, ун тапкыр дөнья чемпионы Ирина Роднина Гиннесс китабына үзенең һөнәри карьерасы дәверендә бер генә ярышта да җиңелмәгән спортчы буларак кертелгән. Виртуоз гитарачы Виктор Зинчук 2001 елда Николай Римский-Корсаковның "Төклетура очышы" вариациясен бик тиз – секундына 20 нота алып, нибары 24 секундта башкарган. 2015 елның 7 маенда Орел шәһәрендә Александр Муромский үзенең китапка кертелгән тугызынчы дөнья рекордын куйган – бер минут эчендә диаметры 10 миллиметрлы 12 тимерчыбыкны башына куеп бөккән. Аңа кадәр ул минут эчендә меңәр битле 11 белешмәлекне ерткан булган. Валентина Закорецкая 1976, 1987, 1998 елларда парашют белән иң күп сикерүче хатын-кыз буларак Рекордлар китабына кертелгән – ул барлыгы 11500 тапкыр сикергән!

("Guinness-records.net").

Шешә әйләнеше

Норвегиядә барлык пластик шешәләрнең 97 проценты кабат эшкәртелә, алай гына да түгел, чималның 92 процентыннан кабат яңа савытлар ясала. Чималның кайбер өлеше инде 50 тапкыр эшкәртелгән. Әйләнә-тирә мохиткә барлык пластик шешәләрнең нибары 1 проценттан азрагы гына эләгә. Осло шәһәре читендәге калдыкларны кабат эшкәртү предприятиесеннән тәҗрибә уртаклашырга теләгән чит ил делегацияләре өзелми. Биредә пластик шешә җитештерүчеләргә экология салымы каралган: алар никадәр күбрәк шешә эшкәртә, салым шулкадәр кими бара. Шешәләрнең 95 проценты кабат эшкәртелә икән, салым түләргә кирәкми. Сатып алучылар өчен һәр шешә бәясенә өстәмә кертелгән, ул кайтма депозит кебек эшли. Депозит буш савытларны кибеткә кире кайтарып биргәндә сатып алучыга әйләнеп кайта – аңа башка товар алганда да түләргә яраклы купон бирелә. Супермаркетларда автоматлар тора, алар шешәне сканерлый, изә һәм җыючылар алып китәрлек хәлгә китерә. Бүген Норвегиядә юл читенә ташланган шешә тапмыйсың, ил халкы дөньяда иң нәтиҗәле кабат эшкәртү системасының үзләрендә булуы белән горурлана. Пластикка каршы көрәш энтузиастлары хәзер Норвегия хөкүмәтен шешә ясала торган пластикны җитештерүчеләргә дә салым кертү зарурлыгына ышандырмакчы була.

("The Local").

"Мона Лиза"

Флоренциядән ефәк сәүдәгәре хатыны Лиза дель Джоконда портреты – дөньяда иң танылган һәм иң кыйбатлы полотно. Джоконданың серле елмаюы тамашачыга инде ничә гасыр буе тынгы бирми. Бөек Леонардо да Винчи XVI гасыр башында язган картинаны кайбер белгечләр 800 миллион долларга бәяли. XVIII гасыр азагыннан картина Луврда саклана. 1911 елда аны музей хезмәткәре Винченцо Перуджи урлый. 2 елдан соң портрет Италиядә табыла һәм Луврга кире кайтарыла, әмма бу урлауда Пабло Пикассо, кайзер Вильгельм II кебек күренекле кешеләр һәм хәтта Франция хөкүмәте гаепләнә. 1956 елда музейга килүчеләрнең берсе картинага кислота сипкәч, аны пуля тишми торган пыяла астына яшерәләр. "Мона Лиза" һаман да Луврдагы иң популяр экспонатлардан берсе санала. 1974 елда, Япониядән алып кайтышлый, аны ике ай буе Мәскәүдә дә күрсәтәләр, ул чакта аны, 7-8 әр сәгать чират торып, көн саен 4600 әр кеше карый. СССР мәдәният министры Екатерина Фурцева, совет халкын әлеге сәнгать җәүһәре белән таныштыру өчен, тиз арада 100 миллион доллар иминият суммасы табу чарасын күрә.

("The Local").

Имтиханны ...машина алачак

Казан инженерлары машина йөртү хокукына практик имтиханны ЮХИДИ инспекторыннан башка ала торган дөньяда беренче пилотсыз автомобиль уйлап тапкан. Hyundai Solaris базасындагы машина ясалма интеллект системасы белән җиһазландырылган. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны ачыклау өчен, иярченле элемтә, берничә камера һәм махсус сенсорлар куелган. Автомобильдәге махсус өйрәтелгән нейрочелтәр исә радар ярдәмендә ачыклап булмый торган юл тамгаларын һәм светофор сигналларын таный. Ясалма интеллект имтихан бирүчене ЮХИДИ инспекторының субъектив фикереннән коткарачак. Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматлары буенча, РФ территориясендә машина йөртү таныклыгы алу имтиханын тапшыручыларның нибары өчтән бере генә беренче тапкырдан ук уңышка ирешә, калганнары берничә тапкыр барырга мәҗбүр. ЮХИДИ инспектор-машиналарны 2025 елдан файдалана башларга ниятли, шулай да андагы "акыллы" системалар имтихан алучы тере кешегә ярдәмче генә булыр, мөгаен. Мондый пилотсыз инспектор-автомобильне беренче булып Россиядә уйлап тапсалар да, дөньяда нейрочелтәрләр нигезендә эшләүче системалар бар инде. Мәсәлән, Microsoft компаниясенең HAMS проекты кысаларында машина йөртү күнекмәләрен тере инспектор түгел, бәлки ясалма интеллектлы смартфон тикшерә һәм билге куя, әлеге система Һиндстанның Дехрадун шәһәрендә файдаланыла.

("РБК").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

11 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.20 «СВОИ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «БАТАЛЬОНЫ ПРОСЯТ ОГНЯ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛЕТО ВОЛКОВ». 16+
10.25, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ТИТАН». 16+
14.35 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Спутник. Русское чудо». 12+
16.20 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «Жить здорово!» 16+
10.00, 12.15, 15.15, 18.20, 0.00 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Лидия Зверева.
7.35 «Вадим Шверубович. Честь имею».
8.35, 21.15 Цвет времени. Валентин Серов.
8.50, 16.35 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Встреча с кинорежиссером Алексеем Германом в Концертной студии «Останкино».
12.25 «Предки наших предков».
13.10 Линия жизни. Виктор Добронравов.
14.05 Цвет времени. Уильям Тёрнер.
14.15 «Мгновения Ефима Копеляна».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 Цвет времени. Карандаш.
17.45 Михаил Плетнёв на VI Международном конкурсе им. П.И. Чайковского.
18.40 «Иисус Христос. Жизнь и учение».
19.45 Главная роль.
20.05 «Почерк эпохи» с Кириллом Кяро. «Осип Мандельштам. Будет и мой черед...»
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «20-й блок. «Охота на зайцев».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
22.15 «СТРАЖА».
23.00 «Доверенное лицо истории».

«НТВ»

5.05 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+
22.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
23.30 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

12 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.15 «СВОИ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
22.10 «БАТАЛЬОНЫ ПРОСЯТ ОГНЯ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ЛЕТО ВОЛКОВ». 16+
10.30 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «БАЙКОНУР». 16+
14.35 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «Салют-7. История одного подвига». 6+
16.20 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «КОТОВСКИЙ». 16+
21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «Жить здорово!» 16+
10.00, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Русский стиль. «Купечество».
7.35 «Иисус Христос. Жизнь и учение». Проект митрополита Илариона. «Начало Евангелия».
8.25 Легенды мирового кино.
8.50, 16.35 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Считаю себя ленинградцем».
12.00 «Крым. Мыс Плака».
12.30 «Предки наших предков».
13.15 «Первые в мире».
13.30 «Игра в бисер» «А.С.Пушкин. «Полтава».
14.10 «Верхняя точка».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.45 Михаил Плетнёв и Российский национальный оркестр.
18.30 Цвет времени. Илья Репин. «Иван Грозный и сын его Иван».
18.40 «Иисус Христос. Жизнь и учение».
19.45 Главная роль.
20.05 «Почерк эпохи» «Федор Достоевский. Казнь».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Орбитальный бастион».
21.30 «Белая студия».
22.15 «СТРАЖА».
23.00 «Доверенное лицо истории».

«НТВ»

5.00 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+
22.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
23.30 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

13 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.15 «СВОИ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Сәйлән».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.00 «Соотечественники». 12+
22.10 «БАТАЛЬОНЫ ПРОСЯТ ОГНЯ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КОТОВСКИЙ». 16+
10.30, 21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «РАЙСКИЕ КУЩИ». 16+
14.50 «Наша марка 2». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Гастротур». 16+
16.20 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «Жить здорово!» 16+
10.00, 12.15, 15.15, 18.20, 0.00 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Русский стиль. «Высший свет».
7.35, 18.40 «Иисус Христос. Жизнь и учение».
8.25 Легенды мирового кино.
8.50, 16.35 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Арам Хачатурян».
12.10, 18.25 «Забытое ремесло».
12.30 «Предки наших предков».
13.15 «Первые в мире».
13.30 Искусственный отбор.
14.15 Острова. Эдуард Тиссэ.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.45 Михаил Плетнёв. Концерт в Большом зале Московской консерватории.
19.45 Главная роль.
20.05 «Почерк эпохи» «Сергей Эйзенштейн. Секреты мастера».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «План Маршалла. 1947».
22.15 «СТРАЖА».
23.00 «Доверенное лицо истории».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+
22.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
23.30 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

14 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «СВОИ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа, я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 12+
23.10 «БАТАЛЬОНЫ ПРОСЯТ ОГНЯ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КОТОВСКИЙ». 16+
10.30, 21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ОРБИТА 9». 16+
14.35 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Титаник». 16+
16.20 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «Жить здорово!» 16+

10.00, 12.15, 15.15, 18.20, 0.50 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Русский стиль. «Дворянство».
7.35, 18.40 «Иисус Христос. Жизнь и учение».
8.25 Легенды мирового кино.
8.55, 13.15 «Первые в мире».
9.15 «ЦВЕТ БЕЛОГО СНЕГА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 ХХ век. «Летопись телевидения и радио». Анатолий Лысенко».
12.15 «Забытое ремесло».
12.30 «Предки наших предков».
13.30 Абсолютный слух.
14.15 Больше, чем любовь.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Охотники и косторезы Чукотки».
15.45 «2 Верник 2». Максим Лагашкин и Мария Карпова.
16.35 Цвет времени. Надя Рушева.
16.50 65 лет Михаилу Плетнёву. Документальный фильм. Режиссер Ю. Борисов.
17.40 Михаил Плетнёв и Российский национальный оркестр. Р.Вагнер и Р. Штраус.
19.45 Главная роль.
20.05 «Почерк эпохи» «Марина Цветаева. Это уже не я...»
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Москва слезам не верит» - большая лотерея».
21.30 «Энигма. Герберт Блумстедт».
22.15 «СТРАЖА».
23.00 «Доверенное лицо истории».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+
22.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
23.30 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

15 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 0.00 «СВОИ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «СВИДЕТЕЛИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Туган җир». 12+
20.00, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КОТОВСКИЙ». 16+
10.30, 21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ПРОБУЖДЕНИЕ».
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «Титаник». 16+
16.20 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «Жить здорово!» 16+
10.00, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
22.00 «Голос. Дети».
23.40 «Одри Хепберн». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Русский стиль. «Чиновники».
7.35 «Иисус Христос. Жизнь и учение».
8.25 Легенды мирового кино.
8.50, 16.15 «ЛИВЕНЬ».
10.20 ХХ век. «Современнику» - 30! Юбилейный вечер».
12.10 Цвет времени. Леон Бакст.
12.30 «Предки наших предков».
13.15 «Первые в мире».
13.30 Власть факта. «План Маршалла. 1947».
14.15 Острова. Ростислав Юренев.
15.05 Письма из провинции.
15.30 «Энигма. Герберт Блумстедт».
17.25 «Забытое ремесло».
17.40 Михаил Плетнёв. Концерт в Большом зале Московской консерватории.
18.45 «Царская ложа».
19.45 Искатели. «Золотой секрет хохломы».
20.30 Линия жизни. Алексей Варламов.
21.25 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ».
22.50 «2 Верник 2».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Простые секреты». 16+
9.00 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
10.35 «ЧП. Расследование». 16+
11.10 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
20.00 «Жди меня». 12+
20.50 «Страна талантов». 12+
23.20 «Своя правда». 16+

Шимбә

16 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.40 «Марат Мухин хитлары». 6+
16.10 «Талгат Галиуллин - сомелье татарской литературы». 6+
17.00 «СТЕНДАПхана». 16+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «ЕЩЁ ОДИН ГОД». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Шагыйрьләрдән дә шагыйрьрәк». Айрат Арсланов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.05 «Бир кулыңны». Зәлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты. 6+
14.25 «Ватандашлар». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 Зәфәр Харисовның юбилей кичәсе. 12+
22.35 Спектакль «Король Лир». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Еда здорового человека». 12+
5.30 «Дорога в космос». 12+
6.30 «Биосфера. Законы жизни». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Джинглики».
8.00 «Планета лошадей». 12+
8.30 «СЫН». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПАРК РАЗВЛЕЧЕНИЙ». 16+
14.50 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПУТЕШЕСТВИЕ ГЕКТОРА В ПОИСКАХ СЧАСТЬЯ». 12+
23.05 «Человек - невидимка». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «Космос. Будущее рядом». 12+
11.20, 12.15, 15.15 «Битва за космос». 12+
15.55 «До небес и выше». 12+
17.00 «Спасение в космосе». 12+
18.20, 22.00 «ШИФР». 16+
21.00 «Время».
23.25 «ОДИССЕЯ». 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.10 «КЛЮЧИ ОТ ПРОШЛОГО». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ЧУЖАЯ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.40 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ».
10.05 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.35 Неизвестные маршруты России. «Золотое кольцо Бурятии».
11.15 «ДНЕВНИК ДИРЕКТОРА ШКОЛЫ».
12.30 «Эрмитаж».
13.00 «Брачные игры».
13.55 «Дом ученых». Алексей Жёлтиков.
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.15 Острова. Евгений Самойлов.
15.55 «СЕРДЦА ЧЕТЫРЕХ».
17.30 «Мальта».
18.00 «Москва слезам не верит» - большая лотерея».
18.40 «Русский бал».
19.35 «КОРАБЛЬ ДУРАКОВ».
22.00 «Агора».
23.00 «Неразгаданные тайны грибов».
23.55 «ДЕЛА СЕРДЕЧНЫЕ».

«НТВ»

5.10 «Хорошо там, где мы есть!»
5.35 «ЧЕСТЬ САМУРАЯ». 16+
7.25 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.50 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00 «Земля - не шар?» 12+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.30 Ты не поверишь! 16+
21.30 «Секрет на миллион». 16+
23.45 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

17 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Без». Илсөя Бәдретдинова концерты. 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Полосатая зебра».
9.00 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Тархан». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.40 «Наша Республика - наше дело». 6+
15.40 «Татар халык җырлары».
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Соотечественники». 12+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «НА БЕРЕГУ МЕЧТЫ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00, 16.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Бату Мулюков турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 «Җанымда яз булып кал әле». Эльмира Җәлилованың иҗат кичәсе. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «СТЕНДАПханә». 16+
21.40 Н.Җиһанов исемендәге «Мирас» татар музыкасы фестивале. 6+

«ЭФИР»

5.00 «Инвиво». 12+
5.30 «Дорога в космос». 12+
6.30 «Самые важные открытия человечества». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Джинглики».
8.00 «Кондитер». 16+
9.00 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПУТЕШЕСТВИЕ ГЕКТОРА В ПОИСКАХ СЧАСТЬЯ». 12+
15.05 «Планета лошадей». 12+
15.30 «СЫН». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПАРК РАЗВЛЕЧЕНИЙ». 16+
22.45 «Человек - невидимка». 16+
23.40 «Женщины против мужчин». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.45, 6.10 «ХИРОМАНТ. ЛИНИИ СУДЕБ». 16+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
8.25 «Часовой». 12+
8.55 «Здоровье». 16+
10.15 «АнтиФейк». 16+
11.05 «Ванга». 12+
12.15, 15.15, 18.20 «МОСГАЗ». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «СОЛЯРИС». 16+

«РОССИЯ»

5.20 «ЧУЖОЕ ЛИЦО». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.10 «КЛЮЧИ ОТ ПРОШЛОГО». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Лето Господне.
7.05 «Тайна третьей планеты».
7.55 «ЦИРК».
9.25 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.55 «Мы - грамотеи!»
10.35 «ДЕЛА СЕРДЕЧНЫЕ».
12.05 Письма из провинции.
12.35 Диалоги о животных.
13.15 Невский ковчег. Теория невозможного. Николай Гумилев.
13.45 «Игра в бисер» «Мэри Шелли. «Франкенштейн, или Современный Прометей».
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.25 Зимний международный фестиваль искусств в Сочи. Спектакль «Ибсен. Recycle».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 К 85-летию со дня рождения Анатолия Лысенко. Линия жизни.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ДНЕВНИК ДИРЕКТОРА ШКОЛЫ».
21.25 «Сквозь звёзды». Музыка к кинофильмам.
23.00 «СЕРДЦА ЧЕТЫРЕХ».

«НТВ»

4.55 «ТОНКАЯ ШТУЧКА». 16+
6.25 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.40 «Маска». 12+
23.40 «Звезды сошлись». 16+

Тал төбендә табылдык

Татарстанның Идел аръягындагы районында былтыр май аенда булган кеше үтерү очрагы буенча февральдә хөкем игълан ителде. Суд гаепле дип табылган 31 яшьлек ир-атны 8 елга ирегеннән мәхрүм итәргә булды. Яклау ягы әлеге карар белән килешмәү сәбәпле, хөкем үз көченә кермәгән әле. Ахыргы нокта куелмаган җинаять эше турында кайбер исемнәрне үзгәртеп сөйләрбез.

Агрофирмада эшләүче С.Абрамов 2021 елның 15 май иртәсендә терлекчелек фермаларына гадәттәгечә турыдан салынган сукмак буйлап бара. Авыл читендәге иске ветеринария дәваханәсе янына җиткәч юан тал агачы төбендә яткан кешене күреп туктап кала. Алдан берәр сәрхуш йоклап ята дип уйласа, якынрак килгәч 36 яшьлек авылдашы Рифат Хәтфуллинның җансыз икәнен аңлап ала. Шаукым тиз күтәрелә, үтеп баручы тагын бер хатын-кыз туктый, мәрхүмнең әти-әнисе килеп җитә.

Полиция һәм ашыгыч ярдәм дә озак көттерми. Соңгысы бары үлемне тиешле рәвештә теркәү өчен генә кирәк була. Ир-атның йөз-бит, башындагы канның кибүе җинаятьнең иртән түгел, ә шактый алдан эшләнүен күрсәтеп тора. Полиция хезмәткәрләре чигә, баш түбәсендәге «җимерелгән» урыннардан тыш, муенда рәсми кәгазьләрдә «буразна» дип йөртелүче бугалак җеп эзен дә абайлыйлар. Суд-медицина эксперты да үлемнең баш сөяге сыну, мигә кан саву кебек авыр җәрәхәтләрдән бигрәк, асфиксия, ягъни буу нәтиҗәсендә килүен белдерә. Мәрхүм Р.Хәтфуллин хәмергә хирыс зат буларак мәгълүм. Авылдашлары аның турында һәрвакыт ярдәмгә килә торган зыянсыз кеше иде дип уңай сөйли. Әлбәттә, аның вак-төяк эшләрне аракы хакына башкаруын да әйтәләр. Мондый затлар һәрвакыт күз уңаенда була, шуңа күрә Р.Хәтфуллинның 14 майда кемнәр белән аралашуын ачыклавы әллә ни зур хезмәт сорамый.

Участок инспекторы алдан шушы авылда яшәүче Р.Ибраев белән әңгәмә кора. Борчылган, каушаган кыяфәтле ир-ат, ким дигәндә, җинаять турында нәрсә дә булса белә дигән шик туа. Район эчке эшләр бүлегенә алып барып рәсми сорау алганда, ул алдагы көнне кич белән Рифат һәм Шамил Шиһапов дигән тагын бер авылдашы белән сабан туе мәйданындагы урындыкта, ягъни мәет табылган урыннан ерак түгел эчеп утыруларын әйтә, әмма иртәрәк киттем, алар икесе шунда утырып калдылар, белмим, күрмәдем дип белдерә.

Шамил исә 14 майда төшкә кадәр өчәүләп эчүләрен әйтә, ә кич белән Р.Ибраев белән икәү генә идек, үтерүгә катнашым юк дип белдерә. 15 майда иртүк бергәләп баш төзәтергә дип Хәтфуллинга шалтыраттым, телефонны алмады, аның үле килеш табылуы турында күршем Сергейдан ишеттем дип сөйли. Ләкин шик төшми калмый, кичкә таба аның өендә, түгәлрәге, әтисе йортында тентү үткәрелә, телгә алырдай дәлилләр генә

табылмый. Беренче көнне аны өенә кайтарып җибәрсәләр дә, иртәгесен яңадан алып китәләр һәм Ш.Шиһаповның җинаять кылуда шикләнелүче буларак тоткарлануы турында карар чыгарыла.

Эш шунда ки, аерым-аерым сорау алынган ике шешәдәш 14 май вакыйгасын нәкъ бертөрле итеп сурәтли башлый. Иң мөһиме, 17 майда Ш.Шиһапов дусты Р.Хәтфуллинны үтерүен таный, ачуымны китерде, үз-үземне белештермәдем дип, үтерү нияте булуын кире кага. Шул ук көнне авыл янәшәсендәге сабантуй мәйданы һәм мәет табылган урында ике пүнәтәй, адвокат каршында һәм статист ярдәмендә явызлыкны ничек кылуын күрсәтеп сөйләп йөри. Икенче көнне тагын бер өстәмә күрсәтмә бирә. Аңа аңлы рәвештә кеше үтерүдә беренчел гаепләү белдерелә. Ике көннән район суды сак астына ябарга дигән карар чыгара, Шиһапов әлеге утырышта да барысын да тануын белдерә.

Шул рәвешле, җинаять эшендә Ш.Шиһаповның гаебен раслап биргән дүрт күрсәтмә теркәлә. Шамил адвокаты аркылы бичара әтисенә Хәтфуллиннар гаиләсенә күмү чыгымнарына дип 50 мең сум акча тапшырырга куша. Ләкин алар өенә барып кергән өлкән Шиһаповка, сөйләшеп тә тормыйча, ишеккә ымлыйлар. Әти кеше акчаны почта буенча да җибәреп карый, ләкин Хәтфуллиннар тагын баш тарталар, улларын үтерүчегә кырыс җәза бирүне таләп итәләр.

Үтерүченең ул икәне мәрхүмнең ата-анасы гына түгел, бу авылда беркемне дә икеләндерми дигән фикер дә туа монда. Әйтик, җинаять эшендә шаһит буларак чыгыш ясаган дистәләгән кешенең күпчелеге Шамилнең укыган чакта ук тупас булуын, үзен башкалардан өстен куюын, сабакташларын, хәтта кызларны да кимсетергә, җәберләргә сәләтле булуын әйтәләр. Әлбәттә, эчкече егетнең хәзер дә исерек баштан гына түгел, аек чакта да котырынкы булуын искәртәләр. Курыкмады, абруйлы атасы коткарачагына ышанды дип бик кискен сөйләүчеләр дә бар.

Ш.Шиһапов турында уңай сүзләр әтисе күрсәтмәләрендә генә бар. Малайның бик яхшы укуы, фәнни олимпиадалар, спорт ярышларында алдынгы урыннарны алуы бәхәссез. Мәктәптән соң университетның юридик факультетын тәмамлый, бер ел чамасы суд приставлары хезмәтендә эшләп ала, аннан тарих буенча курсларда укып чыгып авылы мәктәбендә укытучы һәм хуҗалык эшләре буенча директор була. Ошбу эшчәнлеге дә озын-озакка сузылмый. Казанга китеп төзелеш өлкәсендә эшли. Күргәнебезчә, 31 яшендәге югары белемле юрист тормышта лаеклы урынын таба алмый.

Моның төп сәбәбе эчкечелек икәне аермачык. Н.Шиһапов, улын никадәр генә уңай бәяләргә тырышса да, аның вакыты-вакыты белән «запой»га китүен, наркологка да күрсәтеп каравын, ләкин файдасы тимәвен әйтми калмый. Ләкин Шамилне бөтенләй эшсез утыра дип булмый, юкса үзе эчү генә түгел, шешәдәшләрен дә сыйларлык акчасы булмас иде. Әти кеше аның яман гадәтен күп эшләгәнгә күрә ял итеп алу ысулы дип аклап та маташа.

Шамил соңгы елларда әнисе белән Казанда яши. Авылда торучы әтисе янына еш кайта, узган ел 7 майда да туган якларында пәйда була. Икенче көнне кич белән лаякыл исереп кайтып, тоташтан салып йөри башлый. Аны мәрхүм Р.Хәтфуллин белән авылда еш күрәләр. Хәвефле 14 май да гадәттәгечә башланып китә. Ике сәрхуш иртәнге сәгать 8 нчедә үк кибет тирәсендә эчә башлый. Тиздән аларга безгә төп шаһит буларак мәгълүм Р.Ибраев та кушыла. Күп тә үтми Хәтфуллинга «шабашка» тәкъдим итеп шалтыраталар. Ирләр сарай түбәсендәге иске шифрны сүтәләр. Ш.Шиһапов озак эшләми, исердем дип өенә кайтып китә, калганнар туктап тамак чылата-чылата бераз кайнашалар, ахыр чиктә, алары да алпан-тилпән өйләренә тәпили.

Көндезге сәгать 4 ләр тирәсендә шешәдәшләр тагын кибет янында очраша һәм баш төзәтергә булалар. Бу юлы Ш.Шиһапов алган аракыны Бакалы күл буендагы Сабан туе уза торган мәйданда эчеп утыралар. Шактый гына гәпләшкәннән соң, Ш.Шиһапов ачылмаган бер «чәкүшкә»не алып өенә таба китә. Аның артыннан Р.Ибраев та кузгала, мәйданда Р.Хәтфуллин гына кала. Күп тә үтми язмыш аларны тагын очраштыра. Чөнки Ибраев кайтып җиткәч тә өенә дә кереп тормый, ишегалдында бер тәмәке тарткач та, яңадан Бакалы күл янына юнәлә. Тиздән анда Ш.Шигапов килеп җитә, пакетыннан ике зур шешә сыра чыгарып куя.

Исерүләре җиткән сәрхушләр арасында низаг, гадәттәгечә, юк кына сәбәп аркасында чыга һәм аяныч тәмамлана. Вакыйга инде караңгы төшеп дуслар авылга таба кузгалгач була. Кыскача гына әйткәндә, таза бәдәнле Шиһапов ике мәртәбә сугып Хәтфуллинны чуерташлы юлга аудара, анысы торырга дип тезләнгән мәлдә арттан килеп муенына бугалак салып җепне үзенә таба тарта...

Тикшерү чаралары барышында җинаять кораллары табылмый. Шиһапов бауны үзенең спорт чалбарыннан тартып алганмындыр дип фаразлый, кая куйганын әйтә алмый. Ибраев ташны күлгә таба ыргытты дип әйтә. Ошбу ир-атның арага кереп комачаулык кылырга омтылып та карамавы аңлашылып бетми. Барысы да бик тиз килеп чыкты, үземне дә үтереп ташлар дип курыктым дип аклана ул соңрак. Шиһапов әйтүе буенча тынсыз калган дусларын берсе аяклары, икенчесе кулларыннан тотып күтәреп ачык урыннан читкәрәк илтеп ташлагач, үз юллары белән китәләр.

Ш.Шиһапов гел минем хисаптан эчеп-ашап йөргән кешенең сүгенеп җикеренүенә түзеп тора алмадым, ике тапкыр кул белән сугуымны, җеп белән бууымны, таш белән бәрүемне таныйм, үкенәм, ләкин үтерергә теләмәдем, андый ниятем булса бауны ахырга кадәр тартып торыр идем, ычкындырганда ул исән иде, өенә кадәр илтергә уйладык, авыр булганга ташлап калдырдык дип аклана.

Сүз дә юк, мондый очраклар гаепләнүче туганнары өчен дә зур бәхетсезлек. Ата-ана еш кына баласына белдергән гаепне кабул итә алмыйча нахак, хөкемне гадел түгел дип саный. Нәсим абзыйның да ышанасы килми. Иң беренче чиратта улының тәүбәле күрсәтмәләрен полиция басым ясау нәтиҗәсе дип саный. Әйтүенчә, атна буе өзлексез эчеп йөргән, димәк, махмырдан газапланган Шамилне сусыз, ашсыз тотып җәфалаганнар, куркытканнар, аны сигез полиция хезмәткәре «эшкәрткән» булып чыга. Ә инде малаеның полициядә үзенә психологик басым ясалу турында шикаять язарга теләмәвен сәламәтлеге һәм гомере өчен курку нәтиҗәсе дип белдерә.

Алай гына түгел, хәвефле кичтә Шамил өйдә булды, сәгать 6 ларда кайтты, «чәкүшкә»не юрганы астына тыкты, бераздан йокларга ятты ди ул. Әмма Н.Шиһаповның ялгышуы бик ачык күренә. Әйтик, кичке эңгер-меңгердә мәйданда сыра эчүче өч «мужик»ны, шул исәптән, Ш.Шиһаповны, күлдә балык тотып өенә кайтып баручы яшүсмер малай күрә, төнгә каршы аның алпан-тилпән урамнан килеп мәктәп ишегалдына кереп китүен капка төбендә сөйләшеп утырган өч хатын-кыз шәйләп кала, өстәвенә, сәрхуш мәктәп бинасына куелган видеокүзәтү җайланмалары язмасына да эләгә әле.

Ләкин яклау ягы бирешергә теләми. Башлангыч чорда, күрәсең, файдасыз икәнен аңлап, әллә ни активлык күрсәтмәгән ике адвокат тора-бара көрәшкә күтәрелә. Кыскасы, ай ярым изоляторда ятып өлгергән Шамил 7 июльдә алданрак гаебен танып биргән күрсәтмәләрен расламавын белдерә. Бу исә аның бар гаебен кире кагуын аңлата. Ләкин моңа әллә ни игътибар итүче булмый, каләм белән язганны балта белән юнып ташлап булмый дигән әйтемдәгечә, алдан бирелгән тәүбәле күрсәтмәләргә, тупланган башка дәлилләргә өстенлек бирелә һәм 1990 елгы Ш.Шиһаповка аңлы рәвештә кеше үтерүдә гаепләү белдерелеп җинаять эше судка тапшырыла. Әйтелгәнчә, аңа 8 еллык кырыс режимлы колония билгеләнә. Ш.Шиһапов анда кирегә сукалап тормыйча гаебен таныган булса йомшаграк җәза бирелү мөмкинлеге дә була. Район хөкемдары карарына Татарстан Югары судында да үзгәреш кертелмәс кебек.

Наил ВАХИТОВ.

Мәдәни җомга

Рәссам АЙГӨЛ

Рәссам Айгөл Мәҗитова 1991 елны Баулы районының Исергәп авылында туган. Кечкенәдән алып кылкаләмнәргә һәм палитрага өстенлек биргән ул. 2005 елны Баулы сәнгать мәктәбен тәмамлаган. Урта мәктәптән соң, 2006-2011 елларда Н.Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесында рәссам-педагог белгечлегенә укыган. 2011-2017 елларда Мәскәүнең В.И.Суриков исемендәге академик сынлы сәнгать институтының Казан филиалында белем алган. «Студент елларымны сагынып искә алам, чөнки без академик белем ала алган татар яшьләре буыныннан. Хөрмәтле укытучыларым: Мәхмүт Ваһапов, Рөстәм Хуҗин, Зөфәр Гыймаев, Григорий Эйдинов, Илнур Сиражиев, Анатолий Крылов. Аларга – олуг рәхмәтләрем, – ди Айгөл. – 2014 елны мине – Татарстан Рәссамнар берлегенең яшьләр бүлегенә, ә 2018 елны «Россия Рәссамнар берлеге»нең Татарстан бүлегенә кабул иттеләр».

Айгөл Мәҗитова төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләрдә катнаша, халыкара пленерларда да булган. «Зур Идел», «Яшь Россия» төбәкара күргәзмәләрендә, Баулыда узган «Иҗат – ул хөрлек» яшьләр күргәзмәсендә, Башкортстан Республикасы оешуының 100 еллыгына багышланган Халыкара яшьләр күргәзмәсендә, Татарстан Рәссамнар берлегенең оешуына 85 ел тулуга багышланган «Традицияләр яңалыгы», XI Рәссамнарның халыкара ассамблеясы кысаларында оештырылган «Пластов күзе» күргәзмәсендә дә катнашкан. IV Халыкара фольклориада-2020 күргәзмәсендә рәссам «Портрет. Башкортстан йөзләре» номинациясендә II урынга лаек булган. 2019 елны Төньяк Кипрда үткән Халыкара арт-симпозиумга чакырылган. И.Репинның 170 еллык юбилеена багышланган «Яшьләрнең сынлы сәнгатьтәге әсәрләре» төбәкара күргәзмә проектында катнашкан. «Алтын Урда кайтавазы. Җучи Олысына 750 ел» күргәзмәсендә аның әсәре дә экспозицияләнгән. 2015, 2016 елларда Словакиядәге А.Смолак галереясының Халыкара сынлы сәнгать фестиваленә дә үз өлешен керткән. 2013-2016 елларда Баулының туган якны өйрәнү музеенда, 2015 елда Яр Чаллы Халыклар дуслыгы йортында, «Энергетик» мәдәният сараенда шәхси күргәзмәләрен ачкан.

«Хәзерге вакытта ирем Алмаз белән ике кечкенә улыбызны үстерәбез, иҗатка вакыт аз кала дисәм дә була, әмма картиналар язып, график эшләрем дә юк түгел», – ди рәссам ханым.

Аның киндерләрендә – авыл тормышы, күңелләре шатлык белән тулы милли киемле биючеләр, музыкантлар... Портрет жанрындагы матур хезмәтләре дә җитәрлек. 2015 елны ясалган «Сын-Сәидә – Атнашның хәләл җефете» портреты татар тарихына мөрәҗәгать итә. «Мәгълүм булганча, 1552 елда Мәскәү белән Казан патшалыгы арасында дүрт еллык сугыш башлана. 1552 елда Казанны мәскәүлеләр басып ала, ә 1555 елда бу гаскәрләр Кама Тамагына юл сала. Полководец П.Морозов 7 меңлек гаскәр туплап, алга атлыга. Бүлек-башы Белек аларның явыз ниятләрен аңлагач, 3 меңлек гаскәре белән Агыйдел яры буйлап китә. Ул П.Морозов гаскәрләренең каланы чолгап алу өчен лагерьлар урнаштырган вакытларына килеп җитә. Болгарда – 25 мең гади халык һәм Сын-Сәидәнең 2 мең сугышчысы... Сын-Сәидә ир-ат киемендә сугышучы ханым. Сәид-Әмир Хөсәен, муллалар таянычы белән, аны берничә тапкыр идарә итүдән баш тарттырырга җыенса да, гаскәр Сын-Сәидәгә тугры була. Белек П.Морозов белән килешү төзи. Белек, гәрчә бу чынбарлыкка туры килмәсә дә, үз артында тагын 6 мең гаскәр тора, дип белдерә, Морозовның коты алына. Татар халкы каладан тыныч юл белән чыгарыла. Сын-Сәидә халыкны Кече Болгар тауга алып китә, (анда әле Кече Болгар каласы да төзелә). Болгарда нибары 200 кеше кала. Алар каһарманнарча сугыша, аннары йортларны яндырып, үзләре дә шунда һәлак була. Болгар русларга калгач, ул якка 3 мең халык кире әйләнеп кайта, алар Хәсән һәм Хөсәен мәчетләре янындагы җирлекне яңадан төзекләндерә. Әмма XVII гасыр ахырында руслар әлеге кешеләрне тагын куып чыгара. Шуннан соң анда бары тик берничә кыю мулла һәм дәрвишләр генә яши ала, ә менә Болгарны күрергә теләгән мөсафирлар саны көннән-көн арта гына бара... Бу хакта миңа әнием сөйләде. Гомумән, тарихи темадагы хезмәтләремдә хатын-кызлар тарихын сурәтләүгә өстенлек бирәм. Сын-Сәидә тарихы күп кешеләргә мәгълүм дә түгел, әмма без үз тарихыбызга һәрьяклап карый белергә тиешбез», – ди Айгөл.

Рәссамның реалистик авыл пейзажлары, натюрмортлары да татарлык рухы белән сугарылган. Җете төсле картиналарда – татар милли ризыклары, милли чигешле кул эшләнмәләре...

Рәссамның каллиграфия сәнгате өлкәсендәге әлегә бердәнбер хезмәте дә күпләрне сокландырды, кузаклы борчак сурәте эчендә намаз укуга өндәү язылган. Рәссам якын киләчәктә шәмаилләр, каллиграфик әсәрләр һәм китаплар өчен иллюстрацияләр иҗат итсә, тагын да зуррак уңышка ирешер кебек. Чын иҗатчы үзен сәнгатьнең бар жанрларында да сынап карарга сәләтле. Айгөл Мәҗитова – шундый кыю рәссамнарыбызның берсе.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 8.04.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2747

16+